РЕНАТ ХАРИС

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

Избранные произведения
В семи томах

**Том 3**

*Стихи*

# РЕНАТ ХАРИС

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2006

Сайланма әсәрләр
Җиде томда
**3 том**
*Шигырьләр*

# РЕНАТ
# ХАРИС

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Х33

Җыентыкны төзүче, текстларны хәзерләүче, кереш сүз авторы — филология фәннәре кандидаты, ТДГПУ доценты
*Фәридә Хәсәнова*

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Харисов Р.М.**

Х33 Сайланма әсәрләр: 7 томда / РенатХарис;Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Хәсәнова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5-298-03912-X

3 т.: Шигырьләр (1995–2005). — 2006. — 511 б.

ISBN 5-298-03915-4

«Сайланма әсәрләр»нең чираттагы бу китабына шагыйрьнең нигездә 1995–2005 елларда язылган шигырьләре, сонетлары, багышламалары тупланды.

ISBN 5-298-03915-4 (3 т.)
ISBN 5-298-03912-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Харисов Р.М., 2006



# *Төзүчедән*

Ренат Харис — 1995–2005 елларда иң актив иҗат иткән шагыйрьләрнең берсе. Аның соңгы биш ел эчендә генә дә биш китабы дөнья күргән. Алар арасында кече яшьтәге балалар өчен ике китап, шигъри роман, лирик шигырь һәм поэмалар тупланмасы, Татарстан символлары турындагы китаплар бар. Шагыйрь соңгы еллардагы эшчәнлеген күләмле әсәрләр язуга юнәлтә башлады. Дөрес, аның иҗатында бу өр-яңа күренеш түгел. Шулай да татар әдәбияты шигъри романнары күплеге белән мактана алмый. Әдәбиятта сан түгел, сыйфат мәсьәләсе әйдәп барса, уңышлырак була. Ләкин «Исемсезләр» (шагыйрь аны «шигырь роман» дип атаган) — татар әдәбиятында уникаль күренеш.

Соңгы елларда Ренат Харис иҗатында шигырь дә үзгә сыйфатларга байый бара. Чираттагы бу китапта аның шигырьләре белән бергә сонетлары, күренекле шәхесләргә багышламалары да тупланды. Соңгыларына аеруча игътибар итәсе килә. Әсәрне кемгә дә булса конкрет адреслап махсус багышламалар язу — дөнья әдәбиятында киң таралган типологик күренеш. Бу алымга Гораций, Низами, Сәгъди, Сервантес, Мольер кебек әдипләр дә мөрәҗәгать иткән. Хәзерге поэзиядә гомумән олы язмышлы тарихи шәхесләргә игътибар нык артты. Шагыйрь үз багышламаларында безнең арадан киткән һәм бүген дә иҗат итүче язучыларга җыр-музыка, сәнгать әһелләренә сүздән һәйкәл куя. Әлеге шигырьләр барысы да, тантаналы пафоска корылып, уникеле үлчәм белән язылганнар, алтышар юллык строфалардан төзелгәннәр, теге яки бу затка «исеңдәдер» дип эндәшү белән башланып киткәннәр. Р.Харис багышламалары эчтәлеге һәм стиле буенча повестьларны хәтерләтәләр, ә повестьлар поэма жанрына бик якын. Алар җитди, тантаналы, социаль һәм иҗтимагый характерда. Шагыйрь бу шәхесләрнең тормыш юлы турында төкми-чәчми сөйләп бирүне, иҗатларын тулы яктыртуны максат итеп куймый, бәлки мәшһүр шәхесләр эшчәнлегенә үз бәясен бирә, шәхси кичерешләрен генә ача.

Р.Харисның соңгы елларда язылган шигырьләренә юмор һәм көчле ирония хас. Мондый шигырьләрдә чорыбызның тулы бер җыелма сурәте күренә. Халык мәкальләрен куллану, кинаяле әйтемнәр еш очрый. Шигырьләрдәге хискә килгәндә, фикер әйтү өстенрәк чыгуын танырга кирәк. Илдәге үзгәрешләргә актив мөнәсәбәт сизелеп тора, халык язмышы, үткәнгә

һәм киләчәккә мөнәсәбәт чагылыш таба. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Тормыш белән сугыштым, үлемгә каршы — әзер. Хәзер инде җәннәт ямена дә чыдый алам», — дип яшь аралаш көлү сизелә.

Шагыйрьнең соңгы еллардагы иҗатында Бөек Ватан сугышы темасын чагылдырган әсәрләр ишәйде. Шундыйлардан «Җиңүче», «Шөкер», «Җиңү күргәзмәсе» поэмалары, «Ветеран» кебек шигырьләр бар. Исемнәре телгә алынган әсәрләрнең яңалыгы шунда: алар Бөек Ватан сугышы елларының каршылыкларын, фаҗигале вакыйгаларын яңа заман биеклегеннән карап бәялиләр. Әлеге хәрби-патриотик теманы үзәккә алган поэмаларда беренче планда батырлыкка соклану түгел, бәлки аның чыганакларын эзләү, сугышның ачы фаҗигасен реалистик сурәтләү өстен чыкканлыгын танырга кирәк.

Шагыйрьнең фәлсәфи рухтагы шигырьләре дә күп. Ул аларда бүгенге тормышны, кешеләрне әйбәт белүен сиздерә, шул ук вакытта кайбер күренешләрнең әхлакый мәгънә бирердәйләренә аеруча игътибар итә («Тәүбәсез мәхәббәт», «Карлыган сатучы кыз» һ.б.).

Шагыйрь безнең заман героен эзли...

*Фәридә Хәсәнова*

*Шигырьләр*

*1995–2005*

# *Мәңгелек мөһер*

*Лилиягә*

Булды синең яшь чагың да,
бик яшь түгел чагың да.
Ә мин синең һәр чагыңны
кабатланмас сагынам,
чөнки син һәр дәвереңә
хас чәчәк ата бирдең,
кырыс хисле гомеремә
тәмле хуш ис бөркедең.

Булды күңелле чагың да,
күңелсез чакларың да —
һәрвакыт уңай булмый шул
гомернең чаптарына...
Дулый да ул, өшәнә дә...
Ә өмет алга дәшә...
Нәрсәләр генә булса да,
шөкер, без гел янәшә.

Булды акыллы чагың да,
булды исәр чагың да.
Һәрбер чагың йөрәгемдә
нидер булып чагылган
һәм калдырган үз мөһерен —
ул мөһерләр мәңгелек...
Ләкин минем гомеремдә
син яшисең ямь булып!

* * *

Барысы да сиңа бәйле:
җилнең кая исүе,
кар астында чәчәк булып,
шәмәхә нур үсүе,
гөрләвекне кабул итү,
җыр диеп йә зар диеп,
бөрегә кергән язны да
юк диеп йә бар диеп...
Барыбыз да орбитада
сиңа бәйләнгән көе...
Чиксез кодрәтнең исеме —
СӨЮ!

* * *

Дөнья сүрәнләнеп китеп,
җанга төшсә салкыны,
җыр өстик әле йөрәккә —
җылытсын моң ялкыны.

Дөнья төссезләнгән мәлдә,
сорылыкка әйләнеп,
шигырь өстик без йөрәккә —
бизәсен сүз сәйләне.

## *Адюк Сыркыдысы*

Караңгы, кар-буран.
Карлы тауларга күмелгән киң урам
Таң көтә...
Җил тишек тапкан да
Шуннан сызгыра,
Төнге Җилләр уртасында
Сыркыды авылы тора!..

*Һ.Такташ*

Сыркыдыда җәй булмыйдыр кебек —
кышлар гына, карлы бураннар...
Һәм бүген дә һәрбер баганаНЫ,
уймакланып, көртләр ураган...

Хәтердә дә буран... Шигырь, шигырь
күктә оча, эздә шыгырдый...
Усакларга тотынмакчы булам —
хис давылы бәреп егар дим!..

«Урман кызы», «Мокамай»лар оча,
«Зәңгәр күзләр» куна иренгә.
Җаным һәрчак тамыр ялгап куя
шагыйрьләрнең туган җиренә.

Һәм беразга әверелеп алам
шагыйренә шушы җирнең мин:
Аның сүзе белән сөйли башлыйм,
Аның хисе белән чирлимен.

Бу юлы да кабатланды шул хәл,
уйларыма чумып торганда...
Шагыйрь булып килдем Сыркыдыга,
Адюк* булып калдым урамда.

Замананың усал ач күз җиле
шигырь багларына кар ташый...
Сыркыдыда мәңге җәй булмастыр,
кояш итәлмаса Такташын!

* Адюк — Һадиның мишәрчә исеме.

## *Яшермә*

Үтмәс пычак белән кисәләр...
Неужели үтерүдән курыкмыйлар?!

*Һ.Такташ*

Такташ, Такташ! Яр турысын,
тарих теленнән яшермә —
сине кем, нәрсә үтерде
алтындай утыз яшеңдә?

Сәяси гөрзи очыннан
сиңа тамган кыямәтме?
Әллә җан сөйгәннәреңнең
астыртын хыянәтеме?

Әллә сынган өметеңнең
хәнҗәрдәй кыйпылчыклары
йөрәгеңә күк керде дә
кайнар каныңны чыгарды?

Атаңның сайлау хокукын
тартып алган сельсоветның
агулы рәнҗетү тулы
сыйнфый кара савытымы?

Әллә ачлы-туклы тормыш,
коммунистик акчасызлык
яшәү һәм үлем балансын
йөрәгеңдә синең бозды?

Син романтик булып тудың,
ә менден сәяси атка —
Иблисең белән Фәрештәң
йолыктылар төрле якка!..

Бәлки, үз-үзеңә каршы
көрәшүләрдер?..
Кыскасы —
мин аңладым:
сүз үстерә,
сүз үтерә сүз остасын...

## *Без калабыз*

Мәңгегә хуш, чынбарлык ел! —
тыелгысыз китәсең,
һәм син безне шактый моңлы
озатучы итәсең.

Син башландың буп-буш һәм саф
сизелмәс мизгел булып.
Бакчы, бүген син нинди бай,
нинди саллы һәм тулы!

Һәр исән кеше җанында
син гомер булып актың.
Без таптык та, югалттык та,
син генә фәкать таптың.

Без еладык та, көлдек тә,
башыбыз түнә-түнә,
кимедек тә, ишәйдек тә,
ә син кимедең генә.

Өч йөз алтмыш биш көн идең!
Хәзер алдыңа кара:
Ходай биргән вакытыңнан
сәгатьләр калып бара.

Шатланабыз! Үпкәләмә
туйганнар миннән диеп...
Синең белән
гомер
китә...
Моңны басабыз биеп.

Ә без синнән бәхетлерәк
(дип уйлыйбыз һәрхәлдә) —
син китәсең, без калабыз,
без калабыз гамәлдә!

* * *

Яңа елга катгый теләгем —
миңа алтмыш тулсын!
Шушы теләк, мине җырлатып,
шиксез кабул булсын.

Картайыймчы тагын бер яшькә,
биеп, көлә-көлә,
ләкин дә сөйгәнем, нәселем,
туган илем белән!

Өр-яңа ел, өр-яңа гасыр,
өр-яңа меңьеллык,
яшик әле озак-озаклап
иңдәш-тиңдәш булып!

## Терек суы

Һади Такташ туган йортның
өйсез нигезенә
тезләндек без көрткә чумып...*
Тордык сүзсез генә...

Башыбызда әңгер болыт,
авыр-авыр уйлар...
Артыклары ташып чыкты
күзьяшь юлы буйлап...

Шигырьләре — йөрәкләрдә,
ә исеме телдә!
Нигезендә тигәнәкләр
кыштырдыйлар җилдә.

Әй татарым! Сөям дисең...
Нигә мондый чүп сүз?
Бүген ничә бөегеңнең
йорт-нигезе үксез!..

Яңгырады кинәт дога —
басты салкын көртне,
сүнеп барган өметләргә
кабат ялкын төртте.

Җиргә җитте кайнар яшьләр
изге догадан соң...
Алар Такташ нигезенә
терек суы булсын!

* 2000 елның 24 декабрендә без, Ф.Галимуллин, Г.Зәйнашева, Э.Кудрецкая, Ш.Мостафин, А.Хәлим һәм шагыйрьнең бер төркем якташлары, Сыркыды авылында булдык. Такташ туган нигездә Ф.Галимуллин дога укыды.

## *Югары дөнья*

Менә идек һәрбер кыя
өчен талаша-талаша.
Кәеф күтәренке иде,
адым максатка тоташкан.
Атлаган саен офыклар
киңәя, яктыра барды,
җанда коргаксый башлаган
гүзәл гөлләр яфрак ярды.
Дөньяның сайрар кошлары
оя кордылар гөлләргә...
Ошамады безнең мондый
матурлык әллә кемнәргә...
...һәм төшәбез... Баскыч-баскыч...
Кыядан басып кыяга.
Күзләр җирне капшаса да,
күңел югары дөньяда.
Кереп сеңгән яктылыкны
мөмкин түгел җаннан сөрү.
Гөлдәге оялар таза,
сайрар кошлар мәңге тере.

## *Үзем турында*

Күпләргә — җайсыз, уңайсыз,
ә күпләргә кызык мин.
Беркемнән дә көнләшмимен,
беркемгә дә кызыкмыйм.

Үз-үземә төгәл сыям.
Бозмыйм күрше чикләрен.
Ачык ишекләргә керәм,
үземнекен бикләмим.

Теләгән ягыма барам...
Теләмәгән чакларда —
барам, әгәр кирәк булса
акны таптан якларга.

Менә шулай яшәп ятам —
җайсыз, уңайсыз, кызык —
кемнең яшәешен рәтләп,
кемнең кәефен бозып.

## *Нигә?*

Көз...
Агачлар
исерек хатын-кыз кебек ямьсез.
Итәкләрендә юеш таплар.
Тузгыган чәчләренә
күгәргән яфраклар кунган.
Алар туңган...
Суынган...
Ачып керттем берсен
якты, ап-ак шигырь дәфтәремә.
Бармакларым белән тарадым
юеш чәчләрен.
Кочагыма алып,
аның моңын тыңладым...
Әй, Каен! Нигә кеше булмадың?! —
нинди гүзәл икән
синең җил-яңгырлы җаның!
Мин дә Каен булырга соңладым...
Соңладыммы?

## *Кутузовтай...*

Чигенәбез канун кабул итә-итә,
фронттагы кебек — туптан ата-ата.
Артта түгел микән барлык хата безнең?!
Алда көтә микән әллә олы хата?

Чигенәбез уңга-сулга бага-бага,
Кутузовтай — биналарны яга-яга.
Күзебездән әллә канлы кайгы ага,
әллә инде канлы шатлык яше ага?..

Чигенәбез кануннарга бата-бата,
горурлыкны куркаклыкка сата-сата.
Чигенәбез алга таба... Алга таба
барган юлга чуер булып ята-ята...

## *Чиксез ышаныч*

Мин сине инде көнләмим...
Ләкин үлеп яратам!
Каным рәхмәт булып тәндә ага
сиңа карата.

Нигә мин сине көнләмим,
колак салмыйм чүп сүзгә?
Ахры, җаның саф булганга
ышанычым чиксезгә!

## Тагын юллар

Тагын юллар...
Тагын юллар —
йомшаклары, ташлары...
Һәрчак нидер эзләп-күзләп
йөри адәм башлары.

Тагын юллар...
Тагын юллар —
манзаралар үзгәрә:
таң да ата, төн дә ята,
көн дә балкый күзләрдә.

Тагын юллар...
Тагын юллар —
айлар һәм еллар аша.
Һәм аларның бөтенесе
керфегеңә тоташкан.

Тагын юллар...
Тагын юллар —
яңгырлар һәм бураннар...
Илләр — юлга, юллар — җилгә,
син — шәлеңә уранган.

## *Яшьләрчә, картларча*

Яшьләр акылы — яшьләрчә:
кыю, катгый, яңа!
Яна чартлап, кызу, якты...
ләкин өстән яна.

Картлар акылы — картларча:
акрын, озак, сызлап.
Яна тавышсыз, күгәреп,
яна төшеп кузга.

Яшьләр кызуы — яшьләрчә:
тимер эри сызып...
Картлар кызуы — картларча:
эри йөрәк бозы...

## *Беренче көндә уйлану*

*(2001 елның 1 гыйнвары)*

Үткәнгә карыйм текәлеп...
Күзаллыймын киләчәкне:
теге гасырда туганмын,
бу гасырда үләчәкмен.

Теге гасырдан балачак
карап тора еллар аша,
ләкин аңарга күренми
гомер дигән бер тамаша.

Бу гасырда картлык көтә...
Бәхетлеме? Бәхетсезме?
Үткәнем һәм киләчәгем,
бертөсле үк сөям сезне!

## *Калсаң иде...*

Каһарманлык — хәтәр,
ләкин данлы-шанлы!
Акыллылык — бәла, әйтер кем дә...
Каһарманы түгел,
акыллысы булып
калсаң иде халкың хәтерендә...

## *Туган йорт капкасы*

## *(Кәшә )*

Өйнең тәрәзләре утсыз...
Бер әз дә юк капкасына.
Ботак күзе карап тора
иске койма тактасыннан.

Монда тамган кендек каным.
Һәм шушы өйнең һавасы,
күкрәгемне ертып кереп,
кычкырткан тәүге авазны!

Тора-бара шушы аваз
әйләнгән туган телемә,
фикеремә, шигыремә,
тармы, киңме күңелемә.

Ботак күзе күрә микән
минем иелгән башымны,
хисләремнең күзләремнән
кайнар яшь булып ташуын?!

Шушы өйдә мине тапкан
әнинең дә җаны очты...
Әни кулын хәтерләгән
капка баганасын кочтым,

ләкин капка ачылмады —
гыйнварның җепшек көртләре
мине сабый чакларыма,
бик тырышсам да, кертмәде.

Әй, туган өем капкасы!—
бикләме син, биксезме син —
һәр көн синең аша чыгам
киң дөньяга! Син сизмисең...

## Туган җир

Аштан олы булып булмагандай,
олы булып булмый туган җирдән.
Шатлыкларда кайттык, кайгыларда —
очып, җәяү, туңып, батып тиргә.

Туйларында күпме биетте ул!
Кайнар яшьне йотты җеназада,
канат бирә алды егылганга,
тышау була белде җан азганда.

Үпкәләргә мөмкин туганнарга,
дус-ишләрне атып була тиргәп...
Тик бер генә авыр, салкын сүз дә
төшермикче кадерлебез туган җиргә!

## Җаны тәнгә сыймаганда

Ярларга сыймаган елга
аның хисләрен кузгата,
кайнар кояш һәм салкын Ай
күзләренә кереп бата.
Урамга сыймаган буран,
йөрәгенә сеңеп, тына,
диңгезнең тынмас дулкыны
кан тамырларына тула.
Кош сайрау, ялкын дөрләве,
шаулавы урман-кырларның,
теленә ятып, сүз була —
сүзнең дәвалый торганы.
Таулар чөя горурлыгын,
җилләр акылын җилгәрә,
көтмәгәндә бәхет таба,
йә куыла хак мөнбәрдән.
Тәхет — яный, халык — назлый,
мәшәкатьләр ашый башын...
Ул зурая, тирәнәя...
Җаны тәнгә сыймый башлый.
Аңа авыр... Аңа җиңел!
Ул бер туңа. Ул бер яна.
Җаны тәнгә сыймаганда,
кеше — Шагыйрь!
Каләм — аңа!

## *Хәбәр эзләп...*

Йөрәгемнең күкрәгемдә
икәнлеген инде тоям.
Чәчләремә инде сеңде
кәфен төсендәге буяу.

Акылым да кайвакытта
чыгымчылаган ат кебек —
заман йөген өстерәми,
ә тәртәне вата тибеп

һәм хыяллар канатында
томырыла чиксезлеккә,
йөрәкне җилкендерерлек
хәбәр эзләп...

## *Назыңда эреп*

Мин каныңа синең сеңдем —
мин һәр күзәнәгеңдә:
эшләгән чагыңда, ялда,
төнеңдә, көндезеңдә.

Арый да торгансыңдыр син
мине җаныңда йөртеп.
Ник тилергән җырларымны
иреннәреңә керттең?

Ник татып карарга булдың?
Ник төшермәдең өреп?
Мин каныңа синең сеңдем,
кайнар назыңда эреп...

## *Ун кадак*

Бик иске өйгә дә,
өр-яңа йортка да
кагарга тиешле
ел саен ун кадак.
Ун кадак кагылмый
башласа, эш харап —
кадакның киресен
җил һәм су башкара.
Көн саен йөз тапкыр
ачылган ишек тә
бераздан әйләнә
тупсалы тишеккә.
Тәрәзләр кыйшая,
түбәләр каерыла,
иң төпке ниргәләр
нигездән аерыла.
Тиешле урынга
тиешле вакытта
какмасаң ун кадак,
гомерең ватыла.

## *Кече тирән күлдә*

Кояшсыз, әмма эссе көн.
Бетеп бара июль ае.
Коргаксыган түтәлләрдә
шалканның да кайный мае.

Җил юк, әллә кая киткән
берочтан һаваны алып.
Кислородны судан аер —
болгат әле күлне, балык!

Тузбашның сары таплары
күл көзгесен вата сыман...
Ике бәләкәй акчарлак
күлдә тамак вахтасында.

Аргы ярда сигез үрдәк.
Ана үрдәк муенын сузган.
Алар кай төштә йөзсәләр,
шунда күчеп куна козгын.

Канечкеч кигәвеннәр дә
сиздермичә сала яра...
Кече күл кече булса да,
хәтәре зур тормыш бара...

## *Сабантуй байрагы*

Биектән,
биектән,
биектән
нурландыр мәйданның бар ягын!
Син матур,
син көләч,
син зирәк,
Сабантуй байрагы!

Җилфердә,
җилфердә,
җилфердә —
җыелган халыкка бир ямен!
Син — ярыш,
син — уен,
син — табын,
Сабантуй бәйрәме!

## Югалтмый

Акча үзен үзе югалта.
Корал югалта үзен үзе.
Төсләр уңа һәм югала.
Югала мәгънәсе сүзнең.
Суык җылына.
Җылы суына.
Кәкре турая.
Туры сына...
Вакыт кына,
Вакыт кына
югалтмый үзен...

## *Күрмичә калган*

*(А.С.Пушкин Казанда. 1833 ел)*

Казанны күргәч, Тукайның
сокланып әйткән сүзе,
«И Казан! Нурлы Казан!..» дип,
һаман җырлата безне.

Син, Пушкин, көзге эңгердә
серле нурга төренгән
Казанны күргәч, нинди сүз
очырдың тел түреңнән?

Сентябрьнең төн карасы
әфсен-төфсен өрдеме —
төгәл сүз тапмадың мәллә?
Әллә күрми кердеңме

минем моңлы Казаныма,
ул дөрләткән учакка?..
Татар да күрмичә калган
сине, Пушкин, ул чакта...

Ә хәзер түрендә тота
горурлыгы иттереп.
Син, Пушкин, татар утына
урыс җиле китердең...

## Ухсай кабере

Тау билендә ялгыз кабер...
Йөгереп, тау башыннан
аңа сары сукмак төшә.
Сукмакта — мин, ашыгам,

таелып-таелып китәм
ноябрьнең дымыннан...
Чүгәлим дә, егылмаска,
тайгак тауга тотынам.

Абау! Ә тау салкын түгел —
җылысы учка керә!
Тау эчендә тибә кебек
җирдә тукталган йөрәк.

Тын калып тыңлап торамын —
Ухсай өне: «Тав сана!»*
Шул көннән бирле яшимен
бу тауны тере санап.

Ухсай пичче исән чакта
күземә тылсым өргән —
уйлансам, тауны терелткән
чуваш йөрәген күрәм...

---

* Т а в с а н а ! *(чув.)* — бәхетле бул!

## *Шагыйрьнең йөрәге кайда?*

*Кадим Аралбаевка*

Шагыйрьнең йөрәге кайда?
Күкрәктә дип уйлыйсыздыр...
Аның йөрәге — Җирдәге
һәр егеттә, һәрбер кызда.
Аларның көнләшүләре,
сусаулары утлы назга
Җирдә дәвам итә икән —
шагыйрь яши, шагыйрь яза.

Шагыйрьнең йөрәге эчтә —
калкан артында, диярсез...
Бар калканны тишеп үтә
хәтәр хәбәр һәм яман сүз.
Тормышыбыз һай тынычсыз!..
Сугыш, суеш, талау, янау
талкый шагыйрьнең йөрәген...
Шагыйрь исән, шагыйрь яна!..

Шагыйрьнең йөрәге сүнә
диеп уйлыйсыздыр кайчак.
Инде тончыгам дигәндә,
күк гөмбәзе төнлек ача —
исә саф җил, кайта өмет,
яңа шатлык һәм күз яше,
яңа сөю, яңа каргыш!..
Шагыйрь яза — шагыйрь яши!

## *Казан буйлап*

Казан буйлап барамын
Кабан-күлгә карап мин.

Ярларда базар эзе.
Базар дәүләтне бизи.

Казан буйлап барамын
хан-кальгага карап мин.

Ташларда ядрә эзе.
Ядрә — батырлык сүзе.

Казан буйлап барамын
Елантауга карап мин.

Тауларда дастан эзе.
Дастан халыкны бизи.

Казан буйлап барамын
Казансуга карап мин.

Суларда агым эзе.
Агым — киләчәк сүзе.

## *Сабантуйлы татар халкы*

Сабантуйлар зураялар —
киңәйтәләр мәйданнарын.
«Җир йөзенә бу бизәкне
кем чиккән?» — дип, кояш карый.

Кем чиксен соң?! Татар чиккән!
Чиккән рухында булганны:
хезмәт ямен, табын тәмен,
каһарманнарының данын.

Сабантуйлар ишәяләр,
чәчеләләр Җир буйлата,
халыкларның бәгырендә
шатлык уйната-уйната.

Сабантуйлар уза гөрләп
Төркиядә, фин җирендә,
уза Балтыйк буйларында,
Мәскәүдә, Ташкент, Пермьдә...

Бернәрсә дә тоткарламый
сабантуйларның ташкынын,
чөнки татар сабантуе —
рух бәйрәменә ашкыну,
гадел көрәш, шаян җырлар,
хак табыннарга ашкыну!

Кояш карый бу бизәккә,
сокланудан балкый-балкый...
Җир йөзендә үзе бизәк —
сабантуйлы татар халкы!

* * *

Мәхәббәтсез
беркем яши алмый...
Мәхәббәтсез
һәркем бәхетсез!..
Йөзеп китсәң дә син,
очып китсәң дә син,
йөгереп китсәң дә син,
сөйгән ярым,
мәхәббәттән кала
якты эз.

* * *

Мәхәббәт, мәхәббәт!
Син — кояш.
Мин синең нурыңда балкыймын.
Аерылу салкынын юк итә
мәңгелек мәхәббәт ялкыны!
Дөньяның бозларын эретә
мәңгелек мәхәббәт ялкыны.

* * *

Убылып төшеп имәннәр,
ишелгәч Идел яры,
өстә калган үләннәрнең
үбәләр тамырларын...

## *Сембер*

Сембер, Сембер!
Казаннан кала
яраткан калам
синдер!

Әби-бабам туфрагының
җылы дымы
һәрвакыт та иркенәйтә
тынны.

Биек ярдан карап торам
Идел көзгесенә —
баеган кояшның аңа
нуры сеңә...

Хыялымның мин
җитездән дә җитез көймәсендә!
Абау,
күз тимәсен лә

Иделгә дә, ярларга да,
миңа да.
Мин Сембердә яңа дөньяда.

Сембер, Сембер!
Сагыну утын яндыр,
үкенеч утын сүндер...

## *Кычкырырбыз әле...*

Кемнәр белән генә сыйлашмадык!
Кемнәр белән генә эчмәдем!
Әмма ләкин миңа берсеннән дә
ихласлык һәм акыл күчмәде.
Президентлар, спикерлар салды,
премьерлар да салды тутырып...
Бәллүр сабаларны чәкештереп,
төрле мәзәк сөйләп утырдык.
Министрлар, депутатлар койды,
район башлыклары, мөдирләр...
Йотып куярга да өлгермисең,
рюмка тора тагын мөлдерәп.
Язучылар, галим-голәмәләр,
рәссамнар һәм композиторлар,
кайсы мактап, кайсы җырлап-моңлап,
кайсы майлап, рюмка тоттыра...
«Юл аягы», «Чул күрки»ләр эчтек,
«Посошоклар» күпме тотылды!
Күпме вәгъдә, күпме алтын сүзләр,
аракыга батып, юк булды...
Ә шулай да нигә матур булып
искә төшә шундый табыннар?
Нигә бик еш хәтер аяклары
табын эзләренә абына?
Кайчакларда сорау җанга тия:
булгандыр бит берәр файдасы?..
Килер бер көн, кычкырырбыз әле:
«Шул файдасыз көннәр, кайда сез?»

## *Тагын бер «Мин»*

Черем итә миндә тагын бер «Мин».
Үземә ул бик үк охшамаган...
Тел-тулпарның канатлары азат,
аяклары менә тышауланган —
тибә алмый ул намусын җуйган,
калтасына җыйган җайдагына.
Ул тәбәнәк очмый, ләкин оча
заман җиле искән җайга гына.

Черем итә миндә тагын бер «Мин».
Ул икенче, характеры бүтән.
Тел-ак барсым, Җир намусын тырнап,
кан чәчрәтер күзен йомган Күккә —
күрсен Ходай һәм җибәрсен Җиргә
чын ревизор мәләкләрен күпләп,
чөнки тормыштагы бозыкларны
бар Җир халкы бетергесез чүпләп...

## Яньчелгәнгә

Җилсез дә алма коела...
Әллә артык өлгергәнме?
Әллә, тишеп, үзәгенә
берәр явыз корт кергәнме?

Төште туфракка гөрселдәп...
Тиз-тиз барып алдым. Карыйм —
шундый алма! Дөньякүләм
базарга куярга ярый —

зур һәм шома, алтын-сары!
Әйтерсең лә юкә балы
тутырылган җәннәт шары,
алма кыяфәте алып,

фани алмагачта үскән,
безнең кояшта, яңгырда...
Ләкин бакча горурлыгы
никтер учымны яндыра.

Мөгаен, яньчелгәнгәдер...
Шул төшендә каны кара...
Учымдагы алма хәле
йөрәгемә керә бара...

## *Көтәм намус кушканны*

Мин әүлия түгел... Ләкин
уй белән галәм сөрәм,
илләрне Җирдән кубарам,
капшыймын берәм-берәм,
сизгер куллы табиб сыман...
Һәм көтелмәгән төштә
бармакларым кагылалар,
йа Ходай, яман шешкә...
Сакларгамы табиб серен?
Әллә сакламаскамы?
Җавап тапмый аптыраудан
кайнарга җитә каным.
Ачмасам — илгә хыянәт!
Ачсам — «Татар дошманы»!
Мин әүлия түгел, дәшмим,
көтәм намус кушканны...

## *Мактаулы исем турында*

Әй, илем! Сине илле ел
күккә чөеп мактадым,
һәр уңышың хөрмәтенә
җанда кордым ак табын.

Сиңа орденнар тактылар:
әйтерсең лә син — кеше.
Кем алдында дан казандың
хыялдан аркан ишеп?

Нәрсәне бәйләп ныгыттың
ишкән арканың белән?
Ишетәмсең, Җирдә-Күктә,
каһкаһәләп кем көлә?..

Кайтавазы йөрәгемдә.
Шул кайтавазны күрәм...
Әй, илем! Мин сиңа бүген
мактаусыз исем бирәм.

* * *

Озын гомердән курыкмыйм —
мәшәкать тулса тулсын,
йөрәгемдә хисләр янса,
сүземдә булыр тылсым.

Картаеп сүнү язмасын —
яктысы ни, җылысы...
Җырлап янып көлгә калу —
бәхетнең иң олысы!

* * *

Таба алмыйм көннәр мазасын,
юкса алар бәла-казасыз

таңда туып кичен үләләр...
Җанда кала төссез күләгә —

тозсыз узган көннең шәүләсе...
Димәк, үзем бүген мәгънәсез!

Димәк, үзем бүген мәгънәсез —
таба алмаганмын әгъла сүз,

синең өчен бүген кирәген,
күз карасы кебек тирәнен,

бикле куен кебек җылысын,
шатлык яше кебек олысын.

* * *

Кояш күрде һәм Ай алды
        тагын бер көнне.
Миндә калды минутларның
        матур төркеме,
гомер булса, оныкларга
        бер сөйләр өчен.

Ай күрде дә Кояш алды
        тагын бер төнне —
күңелемә тулып калды
        татлы төтене,
сагынганда хушбуй итеп
        бер иснәр өчен.

## *Тажҗ*

Вакытлыча,
тик бер генә
киеп салган тажҗның үзе,
маңгайны ямьсезләтсә дә,
мәңгелеккә
җанны
бизи!..

## *Хәнҗәр*

Сокланып тотып карадым...
Тоткасында учым эзе калды.
Уйланганда киләчәк турында,
шул хафага салды...

## *Камчы*

Томырылып чабуга әйләнә
ат сыртында камчы көче...
Җайдак дөнья куып чаба инде!
Ә ат көчәнә кем өчен?

## *Кышның матур көннәре*

Их, кышның матур көннәре —
бәллүр нурлар бәйрәме!
Һәр агач үзенә гашыйк
бер рәссамга әйләнде —
алсу карга шәмәхәдән
яза автосурәтен.
Кояш, Җиргә якынаеп,
тора аны өйрәтеп.
Кар әверелде җырчыга —
шыгыр да шыгыр итә,
һәр кешенең һәр адымын
җырына шигырь итә.
Үзе үк көен чыгара —
бөекләргә тиңләрлек!
Их, салкын нурлар бәйрәме,
их, карлы җырлар бәйрәме,
кышның матур көннәре!

## Зәвык бүлмәсе

Бәсле тәрәзәнең җәннәт сыман
гүзәл багларына карап, мин
күңелемнең зәвык бүлмәсенә
күплэп алдым кирәк-яракны.

Бер рәссам да, мәңге тырышса да,
кәгазь, металл, мәрмәр, киндергә
ясый алмый торган сурәтләрне
күңел көзгесенә сеңдерәм.

Куркып калдым кинәт: бу сурәтләр
суытмасмы диеп йөрәкне...
Хәзер әйтәм: алар мине боздан
ялкын чыгарырга өйрәтте.

Җәннәт эрер бәсле тәрәзәдә...
Күңелемнең зәвык бүлмәсе
бөекләрне каршыларга әзер!
Түбәннәргә — элә келәсен...

## *Халык урынбасары*

Җитәкчеләр! Уегызны
каршылыксыз-карусыз
һәйбәтләп эшкә ашыра
урынбасарларыгыз.

Ял итәргә киткән чакта
авыр эштән арып сез,
дилбегәне алып кала
урынбасарларыгыз.

Кайчак шартларга җитәсез,
артып китсә парыгыз.
Шартламыйсыз — шартлаучы бар —
урынбасарларыгыз.

Ә шагыйрьнең юк һәм булмас
ярдәмчесе-мазары,
чөнки шагыйрь, яралмыштан, —
халык урынбасары!

* * *

Усаллык артты кешедә,
арткандай һавада сөрем...
Һәм кеше тилереп йөри,
усаллыгыннан исереп...
Һәр туасы баланы мин
йөрәгем әрнеп кызганам...
Җир карныннан махмыр исе
булып аңкый ахырзаман...

## Кыйммәтлерәк!

Мәхәббәттән дә олырак,
аңардан да кадерлерәк
бернәрсә дә була алмый,
язны тойган чакта йөрәк.

Җәйләр үтә, көзләр китә...
Йөрәккә яз һаман кирәк...
Һәм аңлыйсың: син, хатын-кыз,
мәхәббәттән кыйммәтлерәк!

## *Яз тәме*

Мартның кары көязләнә,
алтын нурга буянып —
көләч кояш аны һәр көн
җил-теле белән ялый,
шаян песи ялагандай
каймаклы тәлинкәне...
Кояш ялый, ә мин татыйм
язның илаһи тәмен.

## *Күтәрердәй кеше юк*

Җир шарыдай авыр башымны
учларына кемнең саласы?
Бармы икән минем тирәмдә
моңа чыдар адәм баласы?

Әнием юк инде... Әтинең
учларында андый көч беткән...
Җир шарыдай авыр башымны
күтәрердәй кеше юк бүтән.

## *Хәтәр хатирә*

Күргәнем бар атом калаларын...
Ә бүген мин Висагинаста.
Кисәтүле һәйкәл карап торам,
якты хисләремне моң баса...
Бер хикәят искә килеп төште,
шашкан айгыр кебек тасырдап.
Онык белән бабай сөйләшәләр:
— Деда, деда, сезнең гасырда
булган диләр шәһәр... Чернобыльмы,
Припятьме — хәзер оныттым...
— Үскәч, белерсең, — дип, дедулясы
кисеп куйган сүзен оныкның,
һәм җай гына сыйпап алган аның
сул башыннан, аннан — уңыннан...
Бу сүзләрне язып утырганда
төшеп китте каләм кулымнан.
Авыр каләмемне күтәрдем дә
мин янадым Висагинастан:
— Монда минем ватандашлар яши, —
не сметь, Атом, аңны җуймаска!

## *Шундый чагы күңелнең*

Томан кебек таркау,
бәстәй сәер,
ләкин һич тә исәр түгел мин —
бер сүз төшсә,
шигырь үсеп чыгар!
Шундый чагы әле күңелнең.

Яз кояшы
күңел кырларында,
җирән аттай, ятып аунады —
эределәр барлык борчуларым,
җылынмаган төшем калмады.

Җылындым да
мамыкланып киттем,
үз җылыма үзем күмелеп...
Яшь кагылса,
хисем дәрья булыр —
шундый чагы әле күңелнең.

Язның якты,
көләч нурлы дымы
кояш яше булып түгелде.
Наз кагылса,
сөю чәчәк атар!
Шундый чагы әле күңелнең.

Ул сүз төшәр,
ул яшь тамар, беләм,
ул наз миңа, шиксез, кагылыр —
үз-үземне язгы туфрак итеп
тоясым бар әле тагы бер.

## *Иблис кары*

Әллә чынлап Иблис干бармы?
Җиргә кем теш кайрады —
ал чәчәкле алмагачка
кар яуды да кар яуды,
керфекләренә сыланды
ни гүзәл чәчәкләрнең.
Әллә мин гөнаһлы микән —
йөрәгем шундый әрни.
Төклетура булып кунып,
җилпеп канатларымны,
кире күккә куар идем
Җирдән Иблис карын мин.
Төклетуралар кайдадыр...
Шәт, каннары каткандыр...
Тарал, болыт, һәм чык, кояш,
алмагачны шатландыр.

*21 май, 2002*

## *Имә башың*

*(Эпитафия)*

Минем алда имә башың —
югалтырсың кояшны.
Элек шагыйрь идем! Хәзер —
мин бары кабер ташы...

## *Зират тузаны*

Барып башымны идем мин
әнием каберенә...
Адым саен тузан купты
буыннар хәтереннән.

Утырам эссе мунчада,
ләүкәсендә кызамын.
Тирли-тирли, пешә-пешә
юам зират тузанын.

Зират өсте үләннәре,
җирдән сут имә-имә,
тамырлары белән җитеп,
туганнарыма тигән,

һәм рухларын кузгатканнар...
Ә җәсәдләре — тузан...
Мин шул тузаннан арынам,
ләүкәдә кыза-кыза.

Ләкин юган саен, никтер,
ул тузан сеңә генә.
Зират тузаны әйләнә
умыртка сөягенә.

## *Гөлләргә су сибеп кайттым*

Гөлләргә су сибеп кайттым —
куандырдым гөлләрне.
Гөлләргә дә килер шатлык
өләшәчәк көннәре...
Көннәрнең берендә алар
керерләр учларыма,
аннары сак кагылырлар
иренем очларына.
Әкрен генә пышылдарлар
әллә нинди серләрен.
Кешедән откан сүзләре
гөлләрнең дә үзгәрми.
Ул көн килде. Кочагымда
шул гөлләр бәйләм булды,
хисләремне кузгатырлык
хуш исле бәйрәм булды.
Гөлләр битемә кагылды
һәм үптеләр күзләрне.
Ишеттем кебек гөлләрнең
пышылдаган сүзләрен.
Тагын тыңладым төбәлеп,
шәйләдем сүзнең төсен —
ап-ак нурдан һәм хуш истән
хасил сүз — синең исем,
          ә н и е м!

## *Эпитафия*

Сез күрерсез минем җансыз тәнне...
Сезнекен дә, шиксез, күрерләр.
Күрә торган күзне, аннан — шушы сүзне
еш күрсәгез иде, тереләр!

## *Иң көзге ай*

Октябрь төште...
Көзнең ул
иң дә иң көзге аедыр...
Безнең якта көз аеның
күрке-бизәге — каендыр.
Шәрә калган урман инде —
аркан, баудан хасил челтәр.
Каен үз яфрагын бирми,
таласа да комсыз җилләр.
Кайнаган салкын болыттан
кояш нуры чәчрәгәндә,
каен гына әверелә
көзнең көләч чәчәгенә.
Һәм көз аны суза безгә...
Алучы юк ләкин гөлне,
чөнки ни эшебез өчен
икәнлеген беркем белми...

## *Файдасыз*

Олының кечесе була,
ә кеченең — олысы.
Һәр елаганга — көләсе,
һәр көлгәнгә — елыйсы.
Һәр үскәннең чүгәсе бар,
һәр чүккәннең — үсәсе,
һәр өзгәннең — өзеләсе,
өзелгәннең — өзәсе...
Һәр кайтканның китәсе бар,
һәр киткәннең — кайтасы...
Ләкин
моны
белү
генә
үлмәү өчен файдасыз...

## *Никахлы төс*

Ак дөньяга чыктым тәрәз аша
бүген иртән торып карагач —
ак һавада ап-ак яфрак ярган
кичтән кара калган һәр агач.

Җир белән Күк тоташ бер буяуга
бер пумала белән буялган...
Һәм Кыш дигән бөек рәссам кергән
минем тышкы, эчке дөньяма.

Шушы рәссам белән сөйләштем мин,
яратасың, дидем, ник акны?
Һәм ул әйтте: — Бары ак төс кенә
Җир пакьлеге белән никахлы.

## *Кышкы бакчада*

Тып-тын төнге кышкы бакча...
Агачлар аягүрә
йоклый, җәпле ботакларын
кап-кара күккә терәп...

Тамыр җир җылысын эчә...
Ботаклар — йолдыз нурын...
Күрәсең, агач буладыр
шулар тоташкан урын...

* * *

*Л.Х-га*

Кайчак йолдызлар күренми
чиксез Галәм ярыннан...
Үлеп калу хәерледер
күмүчеләр барында.

Бу сүзләрдән мин курыкмыйм,
сине күргәч — арынам...
Яшәп калырга кирәктер
сөючеләр барында!

## *Яз шәле*

Язгы карны тишкәләде
яңгырның бишинәсе...
Язның яңа ефәк шәлен
килде минем эләсем
Җир белән Ай арасына —
җилләр килеп күрсеннәр,
бизәкләрен, өлге итеп,
кышка илтеп бирсеннәр.
Күз нурларымнан иштем мин
озын-озын кер бавы...
Бөтен эшне харап итте
Айның күктә булмавы.

## *Нилектән?*

Песнәкләр, хәтта чыпчыклар
сайрамыйлар чүплектә...
Ә кайбер шагыйрьләр сайрый!
Аңлатыгыз — нилектән?

## *Китлар сыман*

Озак җәбердән соң теткәләнеп
беткән сөю хисе төсле болытлардан
куркып Казансуның дулкыннары,
китлар сыман, ташланалар комлы ярга.

Теткәләгән саен йомшармый шул,
киезләнә генә хисләр безнең...
Күңел кебек дулкынланган елга
япан комда ышыкланыр урын эзли.

## *Сан булгач*

Алмагачның сынык ботагына
кунып сайрый сандугач...
Дерелдәшә таза ботаклары
үлесенә сан булгач.

## *Чкенеч*

Төнлә нинди рәхәт иде!..
Иртән — йөрәге әрни...
Чәчәк бәйләме белән ул
себерде идәннәрен.

## *Шаян әңгәмә*

— Чирдән арыну өчен, дим,
кирәк ныклап тирләргә...
— Хатыннар хәлен алмыйча
хәл керми шул ирләргә...

## *Тәрҗемәчеләр*

Бөек тәрҗемәчеләрне беләм...
Кайберләре яһүд халкыннан.
Алар золотой шигырьләр алып,
әверелдерәләр алтынга.

## *Киек уйлар*

Алтын каләм язган сүзләр
борчуларны басмады...
Казма* казы каурыеннан
асыл каләм ясадым.

Каурый каләм ак кәгазьгә
кагылган гына итте,
күңелемдә киек уйлар
купты да очты-китте.

Кайсы якка очканнардыр —
ерак иде күзләргә...
Күңелемә кереп чумдым
киек уйлар эзләргә —

мине иркен чиксезлеккә
алып чыгардайларын...
Йорт казыдай симермәгән
икән әле уйларым...

* Казма — Буа районындагы авыл.

## *Тынлык чоңгылында*

Күзем йомып яткан чакларымда,
чумам бөек тынлык чоңгылына...
Ышана ук башлыйм бу җиһанның
хуҗасы мин булу чынлыгына.

Керфекләрем ачып, чиксезлекне
күз күреме кыршавына биклим.
Һәм күрәмен: бер генә җисем дә
үтеп чыга алмый минем чикне.

Мин яңадан күзем йомам... Хыял
киерелеп тула җиһан кабыгына...
Үзгәрә ышаныч!.. Мин — хыялның
бер гомергә матдәләшкән чагы гына...

## *Эстрада йолдызлары*

Татар эстрадасында
һәр көн «йолдыз» кабына,
ә сәнгать күге яктырмый,
караңгылана гына!..

## *Кыпрыста*

*Зыя Йылмазерга*

Бу атауның кай ягында
туган икән Афродита?
...Юк, булмыйм Юнан алласы,
ир-егет булу да җитә
Кыпрысның берәр сылуын
Афродита итәр өчен.
Татар акылы җитмәсә,
төрек ире бирер көчен,
гагауз — темпераментын,
чыдамлыгын — казах, кыргыз,
җыр кирәксә, ансы да бар —
башкорт йөрми гүзәл җырсыз.
Барысын да туплый алсам —
түзалмас атауның кызы,
елмаер...
Афродитаны
сөйкемлектә китәр узып...

Нинди матур, бөек теләк
монда мине биләп алды...
Әмма төркиләр аеры...
Хыялым ярдәмсез калды...

## *Шәүлә*

Күрәсем килде шәүләмне —
күләгә сурәтемне...
Аяк астымнан эзләдем —
артымнан сөйрәлмиме?
Уңыма-сулыма бактым —
шәүләм качкан үземнән!
Хәзер дусларга карармын
ничек, нинди күз белән?!
Барысының бар шәүләсе —
җирдәге кара табы!
Үзебез таплы булгач та
таплыны яратабыз,
фәрештәләрне сөймибез —
үкенүсез, җәлләүсез
утка ташлар идек күрсәк,
чөнки алар шәүләсез.
Ходаем! Зинһар, табып бир,
зинһар, гөнаһка кермә,
кояшымнан аерсаң да,
шәүләмнән аера күрмә...

## *Вакыт җитте...*

Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла.

*Ф.Кәрим*

Исерек илнең башына
аек ирне куйсак та,
җилләр уйный кесәләрдә,
бүре улый корсакта.

Бәхетсез чагыдыр илнең...
Ирнең нинди чагыдыр?
Вакыт җитте: ил турында
уйлыйк әле тагы бер!

## *Бригантина*

Әй, билгесез гүзәл! Син янымнан
әллә кая үтеп барасың.
Ни өчендер бик беләсем килә:
якты микән төнең карасы,
җайлы микән яткан мендәрләрең,
җылы микән япкан юрганың?
Тораташтай катып, ни өчендер
мин сораулы уйлар корамын.
Югыйсә мин күптән яктысы бар,
җылысы юк йолдыз шикелле!..
Ләкин кинәт «Мин әле дә — кояш
микән әллә?» дигән шик иңде.
Әй, билгесез гүзәл! Үтеп киттең
җилең белән мине этәреп...
Күңел диңгезендә бригантина
янә ап-ак җилкән күтәрде.

## *Киләчәкне тотып кара*

Киләчәкне тотып карап булмый, диләр...
Тотып кара әле үзеңне,
һәм аңларсың: синдә үткән заман
Киләчәккә бара, өзелми!

## *Тоям кебек*

Күңелләргә керермен дә, чыгып та торырмын.
Янә дә керермен...
Аннары...
Инде бүген кайчакларда тоям кебек: мине
кайбер Заманалар аңларын.

## *Татар татар инде...*

Татар татар инде һәрчак —
гаҗәеп эшләр майтара:
дошманы итеп куа да
патшасы итеп кайтара!..

## *Каурый калəм үлгəн*

*Җ.Сөлəймановка*

Әй, Дəфтəрем! Бар биклəрен ватып,
күңелемə шомлы шик керде:
соңгы тапкыр сиңа яза, ахры,
тере калəм тере шигырьне...

Хəреф белəн хəреф бəйлəнеше
хасил иткəн сүзлəр сурəте
шəкерт күңелемне гомер буе
акыл сəнгатенə өйрəтте.

Калəмемнəн ап-ак битлəреңə
кайчакларда, тамып, кан кипте...
Каурый калəм кичə үлгəн... Бүген —
сау бул, корыч! Саумы, компьютер!

## *Давыллану*

Гитара кылларын кайчак
чиртәсе килә —
ярсу чыңнарын йөрәккә
кертәсе килә,
җанны биетәсе килә
чегән көенә,
киендереп өермәләр
кигән киемгә...
Һәм, арып, авасы килә
йомшак куенга,
һәм татыйсы килә анда
тынлык сыен да —
йолдызлы күк музыкасын,
нурлар чыңлавын...
Гүзәл тынлыкка әйләнә
фәкать чын давыл!

Гитарада уйный белмим...
Мин гармун алам.
Чын татарча — уйда гына —
мин давылланам...
Менә шулай!..

## *Рамазан аеның Ае*

Рамазан аеның Ае
офыкка тигән иде...
Гөнаһларга тарткан җаным
пакь тәнен кигән иде...
Кыйбла тарафын эзләдем
догада тезләнергә...
Сызылган Ай гына керде
эзләнгән күзләремә.

Рамазан аеның Ае
офыктан аерылды,
гөмбәз буйлап йөзеп киткән
бер көмеш каек булды,
төяде күз нурларымны,
уйларымны төяде...
Мин, ахры, бүген Ходайның
иң сөйкемле сөяге!

Рамазан аеның Ае
югалды таңда эреп.
Уйларым нурланып кайтты
әллә кайларда йөреп.
Пакьләнде күз карашларым!
Пакьләнделәр сүзләрем —
җанымны кыйнаганнары
дога булып үзгәрде...

## Үзем исән чакта

Бөек хатын түгел иде әни...
Бөек түгел бугай әти дә...
Мин үзем дә Сәнгать буйлап барам,
тулпар атта түгел, тәпиләп.

Тырышудан башым түнгән чакта
беркем тотмый, беркем терәми...
Офыкны да мин иелеп түгел,
мин чөелеп кенә күрәмен.

Йолдызлар да, үзлегеннән төшеп,
ник кенә бер тапкыр бизәсен
бәхетемнең бер уч чикләвектән
тула белгән сап-сай кесәсен!

Бар нәрсәне — үз кулларым белән!
Бернәрсә дә бушлай алмадым!..
Үзем исән чакта
үз акылым
даһи түгеллеген аңлады...

## *Бетәсең*

Үзеңнең төкерегеңне
үз тарихың күзеннән
сөртергә өйрәнерсеңме,
Россия, үзлегеңнән?
Әллә сиңа үз тарихың
төкергәнне күтәмсең?
Күтсәң — бетәсең...
Бетәсең!..

## Кылыч

Ул дөрес сүз кебек үткер...
Килми хәтта сынуйсы!
Кылычның кынысы була,
сүзнең кайда кынысы?

## Күңел

Шатлыктан да арый кеше —
күңелнең бар, димәк, чиге...
Язмыш бизмәнен селкетә
эшебезнең һәр мәкчеге.

## «Горурлык»

Горурлыгыммы? Бар ул —
килә күккә чөясем —
«Болгар-татар
чыгышлы
биш йөз
рус фамилиясе»н...*

* А.Х.Халиков. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе.—Казан, 1992. «...(Чыгышлары ягыннан ... мишәр-татар булган яки руслашкан 500 фамилиянең аңлатмасы...»)

## *Ишетү*

Минем сүзләремне балам,
рәхмәт, колагына элә...
Мин баламның хәтта тынын
ишетәм йөрәгем белән.

## *Биш йөз еллык куркаклык*

Меҗ-меҗ килеп сөйли татар,
булса да сүзе хаклы —
ана сөте аша килә
биш йөз еллык куркаклык...

## *Сәерсену*

Кышкы урман мине янә сәерсетә —
туңган каен миннән җылы яфрак көтә,

белә, белә җанда үлмәс язлар барын,
күзләремә соранучы булып карый.

Әй, Каеным! Нәрсә әйтим, ни дип языйм?!
Үзем туңган килеш кагылырга базмыйм —

һәлакәткә дучар итәрмен бөреңне...
Миндә Тукай уты көле һәм сөреме...

## *Яманрак*

Авыр чирдән дә яманрак
ике нәрсә бар тагын:
китә белмәгән кунак һәм
бетә белмәгән табын.

## *Кунак һәм табын*

Килсә кунак нур булып,
корыла табын зур булып.
Корылмаса зур булып,
утырасың хур булып...

## Сый

Сыйларның иң тәмлесе —
якты чырай, тәмле сүз!

* * *

Көзен
көзге
язгы уйларымны өзде...
Язын
көзге
кышлы уйларымны сизде.
Карамыйча
чәчем тарыйм, сакал кырам —
йөземдәге фасыллардан
күңел бизде...

## *Сандык*

Еврофатир чоланында
әбиләрдән калган сандык...
Картаймасын! дип, яшьлекне
сандыкка салдык.

## *Күзләр кычкыра*

Кайчакта сүз вата алмый
күңелдәге тозакны...
Шул чакта күзләр кычкыра,
ә тел, авыз — йозаклы...

## *Көнләшәм*

Чыпчыклар белән сөйләшәм...
Песнәк белән серләшәм...
Сандугач белән сөйләшмим —
чын җырчыдан ... көнләшәм!

## *Романс*

Йөрәк типсә, тын булса —
хәтта тавыш кирәкми...
Ул уйлата, сулкылдата
һәм җырлата йөрәкне.

## *Шигърият*

Сызыкларны — рәсем, буяуларны — бизәк,
хәрәкәтне — бию, уй-хыялны — ният,
тавышларны — көй-моң, сүзне дога иткән
илаһи тылсым бар — Шигърият! Шигърият!

## *Иртәгә!*

Иртәгә мин бәхеткә тиенәм! —
җитә генә күрсен «иртәгә»...
Һәм ул, җитеп, гади «бүген» булды,
«иртәгә»гә ымлап, үртәргә.

## Корбән

Акыл гына аны аңлый алмый...
Йөрәк сөйли белми алганын...
Чиксезлектән хасил божраның Ул —
ике очы миндә ялгану!..

## Көчлерәк

Әкрен йөри, куркып сулый,
тыйнак кына төчкерә.
Үзе бездән бер инфарктка,
бер инсультка көчлерәк...

## *Татарлык тамгасы*

Тукай — татарның җыр-моңы,
Җәлил — батыр агасы!..
Кем икән безнең татарда
чын татарлык тамгасы?

## *Югалттым... Таптым...*

Мин югалттым авылымны,
таптым шәһәремне...
Мин югалттым бер илемне,
димәк — яшәремне...

## *Тәмсезләнмә!*

— Татар күзсезләнә,
татар телсезләнә...
— Тезләнми бит!.. Харис,
алай тәмсезләнмә!

## *Влач**

Ә влачның холкы шундый:
намуслыга юл ачмый,
ә куркытсаң, уйга кала...
Уйландырыйк влачны!

---

* В л а ч — халык телендә «власть, хакимият».

## *Китам!*

Сәясәттән тәмам китәм инде...
Йотылмадым, шөкер, йотмадым...
Туры карыйм һәркем күзенә мин —
күз карама хәшәп йокмады.

Күп серләрен беләм сәясәтнең...
Кулланмадым ләкин аларны.
Кемдер кулы алтынланган чакта,
көмешләнеп, башым агарды.

Алтынланган куллар авырлыгын
башым татыр, ахры, тагы бер...
Сәясәт ул — кеше акылының
иң мәкерле, көчсез чагыдыр...

## *Мәкерлек*

Явыз дусны үземнән этәрсәм,
үрелдерәм аны пычакка...
Ә болай ул — читлектәге ерткыч,
читлек минем җылы кочакта...

## *Сәясәт*

Юк, сәясәт һич тә уен түгел!
Минем өчен хәзер бу ачык.
Халык — чиләк, ә сәясәт — капкач!
Чиләгенә күрә капкачы...

## *Бәхет*

«Бәхет нәрсә ул?» дисәгез,
җавап бар, ләкин шартлы:
бәхет ул — сизелми торган,
озын дәвамлы шатлык.

## Әгерҗегә барганда

Көньякның мин төн ягына
күчкәнен машинадан
еш күзәттем, Әгерҗегә
Казаннан ашыкканда.

Сирәгәя төшкән саен
җылы кәүсәле нарат,
күккә сөңгедәй кадалган
чыршы ешая бара.

Иж үзәне үзен үзе,
җиткәндә Әгерҗегә,
чыршы энәсенә саплап,
күксел җеп белән чигә.

Монда туфрак, кыр, чык салкын —
җәен куллар күшегә,
ләкин серле бер җылылык
арта бара кешедә.

Табигать мәрхәмәтле шул,
кеше хәленә керә,
берне алса, рәхмәт итеп,
берәгәйлесен бирә!

## *Ватан*

Белэм яттан —
әйтте атам:
туган илдә
булсын Ватан!

## *Тукай бэза*

Бакыр Тукайга шигырьләр
укыйбыз без кызып-кызып...
Бер тәнкыйть сүзе әйтмичә
бетерә ул безне бозып...

## *Юл сайлаганда*

Ялтыравык вәгъдәләрдән
чын эшләр туа сирәк...
Бәхеткә юл сайлаганда
йөрәкне тыңлау кирәк!

## *Казан кунаклары*

Кунаклар килә Казанга
төрле яклардан:
күршеләрдән, каршылардан,
җиде ятлардан.
Каршылыйбыз кунакларны
ачык йөз белән,
йөрәкләребез җылыткан
изге сүз белән:
Хуш киләсез, хуш киләсез!
Узыгыз түрдән,
аркадашлар булып калыйк
гомер-гомергә!

Учакларда утлар инде
күптән кабынган.
Чакырабыз кунакларны
әзер табынга,
һәм сыйлыйбыз кунакларны
ачык йөз белән,
йөрәкләребез җылыткан
изге сүз белән:
Сихәт булсын, сихәт булсын
аш-суларыбыз,
табындаш булып яшәсен
кыз-улларыбыз!

Кунаклар китә Казаннан
төрле илләргә,
хатирәләр сөйли-сөйли
төрле телләрдә.
Озатабыз кунакларны
ачык йөз белән,
йөрәкләребез җылыткан
изге сүз белән:
Хуш килдегез, шат тордыгыз,
уңсын юлыгыз!
Көтеп кала сезне Казан,
имин булыгыз!

## *Ижминсу*

Бүген миңа бик тә моңсу —
ерак кала «Ижминсу»,
Чулманның биек ярлары,
урманлысы, комлысы...

Шагыйрь маңгаедай сырлы
текә ярга басып, мин
аңлагандай булган идем
бер көрәшнең асылын —

Чулман дулкыннары белән
болытлар орышканны.
Хәтердә — араларына
керергә тырышканым.

Җир белән Күк сугыша дип,
йөрәгем яргаланды...
Кинәт салават күпере
аларны аралады.

Күрәм, Күкнең гүзәллеге,
төс булып, Җиргә күчә!..
Табигатьтә сугышу юк,
аңлашу бар төрлечә!

Сизәмен шул манзараның
исләремә төшәсен,
өстәлләргә куйган саен
«Шифалы су» шешәсен.

## *Юнәлеш*

Бәхеткә юл эзләгәндә
йөрәкне тыңлау кирәк —
иң акыллы кешегә дә
юнәлеш бирә йөрәк...

## *Гарьлек*

Үгез, борылып карагач,
гарьлегеннән киткән туңып —
ике сөңге йөрткән башны
койрык йөртә икән куып!..

## *Хыянәт*

Әллә мактау, әллә хурлау —
белмим, мине нәрсә көтә:
һәр мәхәббәт шигыремдә
мин илгә хыянәт итәм...

## *Каргыш итеп*

Без — сүзләрбез! Син безне тез,
әверелдер фикергә,
ләкин утлы каргыш итеп,
олы гөнаһка кермә!

## *Алдану*

Гомер сөрдем... Санда йөрдем...
Комсызландым... Аңладым —
тизәккә батудан яман
бер конфетка алдану...

## *Казан манаралары*

Казан манаралары!
Казан манаралары!
Кем санаган аларны да
кем күтәргән аларны?!
Алар биектән биек —
һәйкәлдәй басып торалар,
күк гөмбәзенә тиеп!
Манаралар төн серенә төренгәндә,
йолдызларга очар булып күренгәндә,
матур-матур хыял биләп ала мине —
канатланып мин йолдызлар илен иңлим.

Казан манаралары!
Казан манаралары!
Кем санаган аларны да
кем күтәргән аларны!
Алар биектән биек —
һәйкәлдәй басып торалар,
күк гөмбәзенә тиеп!
Манаралар көн нурына киенгәндә,
болытларга нидер сөйләп сөенгәндә,
мин дә тыныч кына карап тора алмыйм,
Казанымның горурлыгын чөнки аңлыйм.

Казан манаралары!
Казан манаралары!
Кем санаган аларны да
кем күтәргән аларны?!
Алар биектән биек —
һәйкәлдәй басып торалар
күк гөмбәзенә тиеп!

## *Казанга әманәт*

Казан өстендә йолдызлар
балкыйлар мине күреп,
керфекләремне саныйлар,
көмеш нурларга төреп.
Йолдызлар, йолдызлар,
нурыгыз сирпелсен,
мин җырым итәрмен
аларның серлесен.

Казан өстендә йөзә Ай.
Ай сылуын мин беләм —
ул, хыялыма ияреп,
төн саен миңа килә.
Айсылу, Айсылу,
син минем сердәшем.
Мин кайсы йолдызга
бәхетем дип дәшим?

Казан өстендә таң ата,
кояшын күккә чөеп.
Алтын кояш миңа әйтә:
бәхетең — Казан, диеп.
Казаным, Казаным,
син минем йолдызым,
әманәт итеп ал
бу җырын кызыңның.

## *Казан хәзинәсе*

Без Казанның һәрбер урамында
хәзинә таба алабыз —
Казан бит ул тарих дәвамында
күпне күргән башкалабыз.

Алтын-көмеш, энҗе-мәрҗәннәр дә,
алмазлы йөзек кашы да,
тиң булалмас меңьяшәр Казанның
диварлары хак ташына.

Бөек кешеләрнең үлмәс эзен
саклый урам катламнары.
Йөрәгебез белән ишетәбез
без аларның атлауларын.

Без Казанның һәрбер урамында
горурлык таба алабыз.
Горурлыгын зур хәзинә итеп
саклый олпат башкалабыз.

## *Яфракка шигырь язганмын*

Яфракка шигырь язганмын!..
Ник яфракка? Белмим үзем дә.
Әллә шунда сурәте ошады,
әллә гашыйк булдым төсенә?!
Әллә инде аның үтә кыю,
матур хыялына ис китте —
очкан кошны күргән саен, яфрак
канат итеп үзен хис итте.
Агачын ул, тамырлары белән
шушы түбән җирдән кубарып,
әллә кая очып китмәк иде,
әллә кая шунда — югары.
Талпынуы шундый көчле булган!
Чыдамаган сабы — өзелгән.
Яфрак итеп тойдым булса кирәк
бер мизгелгә бүген үземне...
Яфракка шигырь язганмын...
Ник яфракка? Белмим үзем дә...
Гашыйктырмын, ахры, гомеремнең
тыныч килгән алтын көзенә!

## *Язгы мәдхия*

Хатын-кыз, Матурлык, Мәхәббәт —
күңелнең иң зур өч өлеше!
Шулар сау һәм бергә булганда,
мин — Егет, мин — Ир-ат, мин — Кеше,
мин дәртле, мин җылы, мин якты,
Җирдә дә, Күктә дә мин һәйбәт...
Яшәсен Хатын-кыз, Матурлык,
назлы Яз, илаһи Мәхәббәт!

Хатын-кыз, Матурлык, Мәхәббәт —
яшәүнең иң көчле тылсымы!
Бәхеткә илтәчәк юл башы —
тылсымга акыллы буйсыну!

# *Сонетлар*

## 1. Җавап эзләү сонеты

Тән туа да үлә... Ә җан кала...
Ул үлемсез рухтыр, күрәсең.
Димәк, җанны нидер тартып ала!
Нәрсә икән? Ничек беләсе?

Чиксез Галәм микән? Йә йолдызмы?
Берәр көмәндәге баламы?
Аллаһ каршында, аһ, әхлак боздым —
сорауларны кире аламын...

Кире алып буламы соң аны?
Сорау бит ул уебызның җаны...
Җавабы юк сорау — үлемсез.

Җан һәм Сорау әллә тиңдәшләрме?
Гареш нигезендәге эшләрне
аңлый калсак, булыр... күңелсез.

## 2. Реформаларга карышу сонеты

Яз түгелдер... Язга әле ерак.
Җылы гына килде кайдандыр...
Могҗизаңны күптән көтеп торам —
Җирне, Аллаһ, тизрәк әйләндер,

ил күкрәген кояш җылысына
тизрәк ура, озак чыгарма...
Кала яздык утсыз учак сыман,
куәт тә юк артык чыдарга.

Могҗизаңның үзәгенә керт тә,
аччы тыныч күчеш серләрен —
реформалар канын сөртә-сөртә,
ничә буын инде керләнде...

Юа алмый канны ташулар,
су ташулар — бәхет башына!..

### 3. Чиксезлеккә ышану сонеты

Чиксезлек һәм Хыял гына чиксез.
Хисләр чикле, чикле уйлар да...
Хыял гына, ярый, тышау-биксез,
чиксезлекне аңа буйларга.

Аны олы шартлау итәмен дә,
чиксезлеккә чәчрим, таралам...
Һәм сизәмен: балкып, аң-тәнемдә
Галәм зурлык Ана ярала,

күкрәк бирә, сораганны көтми...
Бу акылдан шашкан, димәгез —
без, шагыйрьләр, шулай, Җирдән китми,
чиксезлекнең сөтен имәбез.

Телебездә кайчак чит сүзлек —
җаныбызда чөнки чиксезлек.

### 4. Йөрәк фасылы сонеты

Үзгәрешләр генә, үзгәрешләр
сиздерәләр вакыт агышларын.
Ә кешедә мәңге бетмәс эшләр:
югалтуын барлый, табышларын...

Кышның язга авышканын күрә
безның елап үлүенә карап.
Җәйләр уза... Сары җилләр өрә,
Җирнең миндә үскән чәчен тарап...

Ә йөрәктә елның фасыллары
юкка чыга, эреп кайнар канда...
Һәм күрәләр шагыйрь асыллары:
сөю дигән фасыл гына анда!

Шул фасылда асыл шагыйрь эри —
үз канында үзе агып йөри...

### 5. Хата эзләү сонеты

Кем ясады Җирдә иң зур хатаны?
Кайсы илдә, нинди телдә, гасырда?
Җавап эзләп, әле дә баш ватамын...
Һәм бөекләр күз алдыма бастылар.

Мөхәммәтме? Иисусмы? Буддамы?
Адәм?.. Ленин?.. Чыңгыз ханмы?.. Әле дә
бар кешелек, ниятендә буталып,
бәхетенә юл табалмый һәр илдә!..

Ә кем кылды Җирдә иң зур игелек?
Шул ук затлар искә төшә иң элек,
чөнки алар — планетар аң үзәге!

Бу сорауны күп буыннар кабатлар.
Нигә кирәк сорауларга җаваплар?!
Әллә дөнья берәр фетнә сизәме?..

## 6. Тулган ай сонеты

Ай тулышты төн нурыннан, өрелеп...
Качыштылар вак йолдызлар аңардан...
Ярканатлар канат җәйде иренеп
һәм киттеләр күктән азык ауларга.

Лунатиклар, буйсынып нур-әмергә,
уяу төшләр дөньясына чыктылар.
Һәм алар да очышларга әзерләр —
фәрештәләр чөнки һаман йоклыйлар...

Үзе шомлы, үзе серле яктылык
гаҗәеп үз һәм котычкыч ят булып,
үле күздәй карап тора күшегеп,

шул яктылык сеңә башлый сүзләргә,
аларның да җылылыгын үзгәртә...
Кеше тизрәк яба йөрәк ишеген...

## 7. Тиңләү сонеты

Лаләгөлгә тиңли сине кемдер...
Лаләгөлләр көнгә ачыла.
Кояш нурларына әнә сеңде
төн серләрен җыйган тамчылар.

Син ачыла торган вакыт — төндер.
Төндә — тышаусызлык тылсымы!
Бәлки, җәннәт назларына тиңдер
шул тылсымга бергә буйсыну?!

Каршымыни мондый тиңләүгә мин?
Бу тиңләүдә — минем теләгәнем:
дәрт ялкыны дигән ут аша

синең көнең минем төнем белән,
минем көнем синең төнең белән,
һич югында, уйда тоташа...

**8. Язгы көн-төн тигезлеге сонеты**

Күкрәген Җир яктыгарак бора...
Таңнан төнгә шәүләм сузам да
кояш сәгатедәй басып торам
көн белән төн тигез ызанда.

Бүген Җиргә инде язгы хаклык —
ак нур белән кара балансы!
«Гадел» кояш ләкин көннәр яклы —
куш минутлар көнгә ялгансын!

Ә көз көне көзге хаклык килә.
Ул чакта да кояш эшне белә —
көн аклыгын төнгә имезә!..

Күңел тынычлыгы бизмәнемнең
берәр кылын, ахры, өзгәнмендер —
ике «мин»не булмый тигезләп...

## *Тирән яктылык*

Мөхәммәт галәйһиссәлам ник көлмәгән,
елмаюдан ник узмаган беркайчан да?
Яшен яшьнәгәндәй чатнап, һаман-һаман
шушы сорау тынгы бирми минем җанга.

Галәм гөрелтесен җыйган яктылыктан
миңа таба юл сузыла, балкый башлый...
Бәллүр юлда бер алмаз нур миннән сорый:
Ә кем күргән шаркылдап көлгән кояшны?..

## *Сискәндеримче*

Сикереп-сикереп агадыр кар суы,
Ник басылмый йөрәгем ярсуы?

*Татар халык җыры*

Су белән сискәндеримче үземне —
язгы юлга чыгыйм, йомып күземне.

Күлдәвеккә китереп басыйм күрмичә,
мин сискәнмәм су балтырдан кермичә.

Ваемсызлык җылысына күмелдем,
кычкыртып талыйлар юкса күңелне.

Риза булып яшәп ятам барсына...
Бәлки, җенемне ярсытыр кар суы...

## *Кояшлы буран*

Әллә кыра, әллә сөртә,
әллә юк итә ышкып —
кояшны томалап, буран
озынайтмакчы кышны.

Тынды буран. Түбәләрдә
кар инде эри башлый...
Язгы буран, ышкый-ышкый,
ялтыраткан кояшны...

## *Кунак — хуҗасына күрә*

Кем булмас минем кунагым?!
Кунак — хуҗасына күрә!
Шәп пар атка урам эте
икеләтә каты өрә...

## *Алып йоклый...*

Алып йоклый онытылып... Җир әйләнә...
Шыгыр-шыгыр, келтер-келтер Вакыт ага,
һәр халыкның һәр кешесе йөрәгенең
ишекләрен Заман булып кага-кага.

Алып йоклый кырда, департаментларда,
мәктәпләрдә, фиркаләрдә, коттеджларда...
Кәвешеннән тау-тау туфрак кагып йөреп,
ул талчыккан, ул йончыган, үлеп арган.

Алып йоклый баһадирдай — берни сизми.
Аңламыйдыр: йокы озын, гомер кыска...
Йокла, Алып, йокла, бәгърем, рәхәтләнеп —
йоклый әле дустың Илья Муромец та...

## *Нефтькә ике сүз*

Уенчылар сатып алып чит җирләрдән,
дан яулыйсың, кара алтын, бигрәк ансат.
Син татардан эстәт белем чит илләрдә,
китап яздырт, җыр чыгарттыр, рәсем ясат!
Син күп чыкма!
Син посып ят җир астында,
киләчәккә якты, җылы мая булып...
Син, күп чыгып, сәясәткә әйләнәсең,
сәясәтнең эче-тышы хәтәр тулы.

## *Кызганма*

Яз көткәнгә язны Ходай бирер —
кышны эретәм дип, куз алма!
Җир йөзендә үз эшеңне эшлә —
наз көткәнгә назың кызганма...

## *Юкмы әллә?*

Яңагыңа сугып уятыймчы,
гарьләндерим әле кимсетеп:
телең — сүзсез, күзең, аңың — томан,
ә эчкәнең — һаман җен сөте...

Бер типтертим тәртәләргә диеп,
гомер буе күпме янадым...

Авыл, авыл!
Күзләреңне күрмим,
таба алмыйм никтер яңагың...
Әллә алары да юкмы?

## *Исән картлар*

Киләчәгемә мин карап тордым
гаҗәпсенеп... Юк, юк — аптырап...
Минем алда уйга батырырлык
кызганычлы сукмак яктыра.

Ул сукмактан, белмим, нәрсәнедер
кәкре таяк белән кармалап,
җилкәсенә тормыш йөге өйгән,
күпне күргән-белгән карт бара.

Аның йөген үзем җәһәт кенә
үз җилкәмә кила аласым,
ул сукмакны узып тормый гына!..
Һай, бозык шул адәм баласы!..

Киләчәгемә мин карап торам —
э т и е м ә! Тиздән чүгәчәк...
Киләчәк ул — яшьләр, яшьләр, диләр...
Исән картлар безгә — Киләчәк!

## *Баден-Баденда*

Җиңүче ил мәхшәреннән
җиңелгән ил оҗмахына
килеп кергәч ачу купты
күңелнең түр почмагында.

Алар җитеш яшәгәнгә
куанды җаным, куанды.
Без, без җайлана алмаудан,
тешләрем кысып, кыйналдым.

Ник без, көнләшә белеп тә,
ясамыйбыз көнчел адым?
Юк, соравымны ишетми,
җавап бирми Баден-Баден...

Бәлки, аңламыйбыздыр без,
тәмуглылар, оҗмах телен.
Баденның кыйгач яңгыры
җанны телә телем-телем...

## *Башка сукты*

Болытларга ябышмадым,
җирдән аерылса да аяк...
Җир белән күк арасында
очып барам әллә кая.

Һичкем кайгысы кагылмый...
Шатлыгы да кирәк түгел...
Мин фәрештә булып кына
яшәп карыйм әле бүген!

Очып барам... Таптым бугай
мин гарешкә юнәлешне.
Башка сукты! Кеше булып
кабат Җиргә килеп төштем...

## *Гади дөнья җимерелде*

Гади дөнья күптән җимерелде —
картлык килгән, димәк, күзләргә...
Тик бер катлы булган бөтен нәрсә
күп катламлы булып үзгәргән.

Аңлап булмау инде хәттин ашты...
Мондый хәлдә авыр яшәргә.
Киңәш сорыйм хәзер бу дөньяны
тик бер катлы күргән яшьләрдән.

* * *

Күкләр тетрәп, баш түбәмә
коелган мәлдә йолдыз,
һич көтмәгәндә калганда
ни маяксыз, ни юлсыз,
«Яшәргәме, чикләргәме?..»
дигән уйлар җәтмәсен
өзәргәме, әллә ...ме дип,
икеләнгән чакта
Син,
Син
җанның елдырымына
өстисең тере ялкын,
канда батмас, утта янмас,
туң алмас татар халкым...

* * *

Гел яктыда озак йөрелдеме,
куанычлар күмеп киттеме —

күләгәдә күзләр берни күрми,
моң-зарларны колак ишетми.

Йөрәкнең дә учагы сүрелә —
җылытасы килми һичкемне...

Син яңадан кеше — болытлы көн,
давыллы төн аша кичтеңме!

* * *

Тәрәзәдән кулны сузып,
тартып алдым бер болыт.
Язу өстәлемдә болыт
тора ап-ак үр булып.
Кар тавы күк...
Юк, мәрмәр күк!
Үземне рәссам итеп
тойдым да, алмакчы булдым
мәрмәрнең читен китеп —
сыныңны синең ясарга
иде татлы исәбем,
онытканмын хәрәкәттән
җил чыгасын-исәсен...
Булачак сының таркалды,
таралды томан сыман...
Шул томанны гына хәзер
утырам инде сулап.

* * *

Начармыни патша булу?!
Начармы түрә булсаң?!
Дөньяда бик күп яхшылык
шулардан, күрә белсәң!..

Шагыйрь патша булмый, имеш...
Бик буласы... Бик тели...
Алла буласы килгәнгә,
патша буласы килми...

## *Ясак*

Кайчагында кылын чиртәм гитараның...
Чың чыгармы, көй чыгармы — битараф мин.

Чиртәм, чиртәм... Читкә куям уйнамыйча,
инде миңа моң кергәнен уйламыйча.

Һәм шул төндә миндә бер Көй яңгырый башлый...
Ул матур Көй ап-ак йөзле, кыйгач кашлы.

Күкрәгемә куя да Көй җылы кулын,
ала туңган йөрәгемнең авыртуын.

Шундый итеп Көй иркәли мине, назлый —
уянырга, күз ачарга хәтта базмыйм!

Уянамын... Күзем ачам теләмичә...
Гитараны кая куйдым соң мин кичә?..

Аны табам... Ә төш кайтмый... Инде беләм —
төше өчен түли кеше өне белән...

## *Тормыш-сыер*

Без дигәнчә бармый тормыш-сыер:
алга кусаң — артка борыла...

Йөрәгемдә туган якты сүзләр
буялалар телдә корымга.
Нидер пыскый, пыскый җан түрендә...
Һәм башыма тотен тулганга,
гел елмайган йөзем бик еш чытык,
ә күземнән утлы яшь ага.
Өмет пыскый...
Башка бер утның да
мондый булмый төтен-сөреме...
Корымланган күзләремә минем
хәтта кояш якты күренми...

Без дигәнчә бармый тормыш-сыер...
Иртә язның якты кырына
куган саен,
печән исе сеңгән
тынчу абзарына борыла.

* * *

Теләсә генә ничек яшерсә дә,
һәрбер кеше мохтаҗ мактауга —
түмгәк зурлык горурлыгы аның
әверелә биек ак тауга...
Шуннан торып ул карашын ташлый
вак-төякләр тулы дөньяга.
Йодрык хәтле йөрәгендә шулчак
галәм зурлык кеше уяна.
Бәдәненә тула искиткеч көч,
ә аңына даһи хыяллар,
һәрбер хыял балачактан килгән
гүзәл буяуларга буянган!
Шулар аша ул дөньяга бага:
— Җәннәт багы ич бу, Ходаем!..
Җанда
күпме
җәннәт үтерделәр
хурлап-хурлап безне һәрдаим...

* * *

Газаплар-газапланулар
урап үтми беркемне,
үтмәгәндәй Җир шарында
читләтеп төннәр көнне.

Ләкин шуны белә торып,
бернишли алмый күңел —
ул шатлыкка һәрчак әзер,
газапка әзер түгел.

* * *

Хыялымда якты беткәч,
ябыштым да күз нурыма,
барып чыктым гаҗәп тауга...
Юк, тау килде хозурыма...
Мендем...
Якты...
Җирдә михнәт...
Ә күк — шәфкатьсез алдакчы —
бәхетне
тик вәгъдә итеп,
илаһи булып калмакчы.
Өстә ничек — аста шулай!..
Уй куера...
Кан да ката...
Ничек аңлыйм — килде тавыш:
үлем — дөрес, туу — хата...

## *Авыз ерып килеше*

Һәр кешенең үз эше,
үзәгендә үз шеше,
үз елавы, көлеше,
хәсрәттә үз өлеше,
бәхеттә үз көмеше,
табынында үз ише,
үз ишенең үз бише...

«Бар» ноктасыннан «юк»ка
авыз ерып килеше...
И кеше, бөек кеше!

* * *

«Замана җиле җанымда.
Күзләремдә куе томан.
Үзем сукыр юлчы сыман —
куркып атлыйм...
Туктыйм... Туңам...
Шәмәхә күк. Картайган Ай.
Йолдызлары күренми ник?
Бер тау каплый. Башы якты...
— Урап үтик...
— Туры меник...
Кайдан бу өн?
Кем киңәше?
Кайсы дөрес?
Кайсы ялган?..»

Бүген дә күпме Обломов
шулай уйга батып ята...

## Аңлап өлгермичә

Куера да Вакыт кеше була.
Яшәп китә фани дөньяда...
Һәм яшәүнең бөтен хасияте
йога, куна, сеңә аңа да.

Эшли, җырлый, сөя һәм сөелә,
гаҗәпләнә, елый, шатлана!
Әллә тормыш аны чыбыркылый,
әллә кеше аңа атланган?!

Кеше яши.
Аңа каргыш, рәхмәт,
аңа хурлау, мактау,
аңа — дан...
Ник туганын аңлап өлгермичә,
Вакыт була кеше яңадан...

* * *

Яхшысы да китә...
Яманы да китә...
Җүләрне дә көтә...
Даһины да көтә...
Коткармый акча да,
коткармый табиб та—
кемнәре кәфендә,
кемнәре табутта...
Йөрәге типкәннең,
күзләре күргәннең
дөньяны актарсын
тутыкмас төрәне.

## *Иң авыр йөк*

Нинди авыр йөк соң рухны аска тарта?
Уйлыйм, уйлыйм — ни икәнен булмый табып.

Мин — дусларның хыянәтен белгән кеше,
йөрткән кеше иңнәремдә бозлы табут.

Бу дөньяның оҗмах бакчаларыннан чыгып,
төшкәндә дә тәмуглагы утлы чанга,

бу кадәрле сызлый-сызлый уфтанмадым,
болай авыр булмый иде һичкайчан да.

Нинди авыр йөк соң рухны аска тарта —
үзәннәрдән мин үрләргә менәм көчкә?!

Һәм аңладым: әйтелмәгән күпме рәхмәт,
әйталмаган күпме каргыш йөртәм эчтә.

## *Ике башлы...*

Уйлыйм-уйлыйм... Буйлый алмыйм... Уйны ташлыйм...
Һәр нәрсә дә бу дөньяда ике башлы,
ике очлы, ике катлы, ике яклы.
Әйтик менә, мисал өчен, ал таякны,
йә елганы, йә сукмакны, йә гомерне —
бер үк нәрсә ике очта ике төрле.
Сугыш башы — олы кайгы, соңы — бәйрәм,
күккә оча төрле төсләр бәйләм-бәйләм...
Гомер соңы — исәннәрне кайгы өтә,
гомер башын нәсел-нәсәп бәйрәм иткән...
Ә уйларым? Уйларым да ике башлы —
берсе җанны тукландыра, берсе — ашый...

## Атмый калган сүз

Мәйданнарга чыгып кычкырмадым —
вакламадым йөрәк сүзләрен.
Атылмаган уклар кала торды,
ә замана яман үзгәрде.
Әйтелмәгән сүзләр сөрседеләр.
Агулары канга саркыды.
Һәрбер үзгәрешкә карыйм хәзер
шик-шөбһәле томан аркылы.
Кайчак төнлә йөрәк ишегемне
үкенечләр килеп шакыйлар...
Атмый калган уктан мәргән үлә,
әйтми калган сүздән — шагыйрьләр.

* * *

Җыр агышы өзелә дә,
колакта кала чыңы.
Өзелгән җырның чыңында
яшидер моңның чыны —
яралы хатирәләргә
бер дәва булырдае;
бала чакның якты көне;
гыйшыкның җылы Ае;
иң беренче үбешүнең
буылып калган тыны;
әнинең, кул изи-изи,
һәйкәлгә күчкән сыны...
Шушы мизгел өзелештә
әллә нинди тылсым бар...
Җыр, өзлексез агып торса,
әйләнер иде суга.

* * *

Көн бик сүрән булды —
мәхәббәтсез үткән гомер сыман.

Кич җиткәндә генә кояш чыкты —
нурлары сынган,
үзе
күлдә көйрәгән күмер сыман.

## *Дилбегә*

Туры юлга чыккач кына
җибәрәләр дилбегәне.
Җибәрдем дә уйга калдым:
мин белгәнне Ил beләме?

* * *

...Әйе, каләм кулдан төшәчәк,
яза-яза кызган очы белән
бер лыгырдык телне тишәчәк —

җилгә, нурга бикле куыштан
ыслап чыгып, корбан әзли-әзли
шуышкан еландай шуышкан,

күсәк, хәнҗәр, тәмле табак та
була белгән сәләтле бер телне
куячак ул җиргә кадаклап...

Нинди тел ул, кайсы авызда? —
диеп баш ватмагыз. Әйтәм — ул тел
Гайбәт дигән бөек явызда.

## *Кипр утравында*

Афродита туган култык
диңгезнең гүзәл җире...
Алиһә куптарган дулкын
биредә мәңге тере,
ул һаман наз таләп итә,
ул ялвара, илерә...
Әллә наз бирүче булып
килдемме мин бирегә?
Мин чишендем... Чумдым... Килә
үзәгенә батасым —
мин, мөгаен, булачак бер
алиһәнең атасы...

* * *

Әллә кая
кояш байый...
Аның белән минем ара —
өй кыегы, моржа, нарат...
Күк урынында алтын балкыш
дисәм — канат җәйгән ал кош...
Ул канатлар әкрен генә
әйләнәләр зәңгәр төнгә.
Тын тынычлык иңә җанга,
шашып-шашып сагынсам да...
Аңлашылмый бу ниятең,
бу ниятең — хасиятең,
бөек Тәңре!..

## *Кеше булыйк*

1

Кәүсә буйлап авыр яшел сутын
Җир кояшка таба куа ник?
Күзне ачып якты күргән саен,
кеше булыйк әле —
куаныйк!

2

Былбыл булып җырлый җәйнең җаны —
Һуштан яза гөлле купшылык.
Безнең күкрәктә дә моңнар яши
кеше булыйк әле —
кушылыйк!

3

Тамырларын яфраклары белән
Һәрбер агач, үлән каплый ник?
Иң борынгы изге гадәт — шушы,
кеше булыйк әле —
кабатлыйк!

4

Тагын Җиргә болыт балалары
коелалар актан киенеп...
Кемгә — кәфен, кемгә — туй күлмәге...
Ә без кеше булыйк —
сөеник!

## Нигә кеше күзен йома

...Ачтымы — күзенә дөнья керә...
Нигә бик еш йома кеше күзен? —
чөнки һәр нәрсәдә үзен күрә...

## Авызлык

Туйдым, туйдым, туйдым авызлыктан.
Тешне кыскан саен — авызым кан,
чөнки тешләр сына явызлыктан...
Явызлык — авызлыктан!

* * *

Карурманнар уртасында,
черек наратка сөялеп,
мин гомер турында уйлыйм...
Уйларым инде сөялле.

Яшәгәнмен!.. Яшәгәнмен...
Үкенечләр юк та сыман,
ләкин нидер күзгә кереп,
арчый суган, арчый суган...

Килер мизгел, һәм миндә дә
вакыт агышы тукталыр...
Исемемә арка сөяп
оныкларым уйга талыр.

* * *

— Өйдә ничек?
— Йөрәктәге кебек...
— Ә йөрәктә ничек?
— Искечә —
Кояш чыкмый болыт таралмыйча,
ул таралмый җилләр исмичә...

— Җилләр ничек?
— Җилләр... өйдәгечә...
— Өйдә ничек?
— Өйдә... яңача —
Җил кертергә диеп тәрәз ачтым,
ишек әле ябык калачак...

## *Дулкын*

Зәңгәр юеш ялкын
бии, чайкала, кыздыра күкне.
Тары коймагыдай пешә кояш
кырыйлары тәмле кетердәп —
сыйлан, туфрак,
сыйлан, кеше,
җанвар, кош-корт, үлән!..

Мин бөтен барлыгым белән
зәңгәр салкын ялкын
ирегенә ташланам —
суына тәнем,
суына башым,
куера акыл,
дәрман кайта арган йөрәккә.

Мәҗүсиләр,
ялкын аша сикергәләп,
пакьләгәннәр җаннарын.
Әкиятләрдә
бөкере картлар, утка кереп,
яшь баһадир булып чыкканнар.

Юеш, салкын зәңгәр ялкын!
Бие, чайкал, чәчрә, айкал —
бер гайрәтле тамчың,
бер тылсымлы тамчың
каләмемә тамсын!

* * *

Җил исеп куйды да кисеп,
һавада ялт-йолт алтын...
Иренеп кенә сузылып,
мин берсен тотып алдым,
каен яфрагы кебеген...
Баксам — алтыны тутык.
Без алтын да тутыгырлык
нинди заманда тудык? —
дигән фикер — салкын ялкын —
бер кабынды, бер сүнде...
Китегезче, сары уйлар,
шөбһәләнү, көрсенү —
һаваларда ялт-йолт алтын,
кояшның юмарт чагы.
Сүнү алдыннан кабыну...
Күңелдә көз чуагы.

## *Канәгатьсезлек*

Тамыр очы якты җиргә чыкты килеп.
«Ә бу нәрсә?» — диде, үз алмасын күреп,
«Яшәвеңнең мәгънәсе ул», — дигән идем,
тамыр тизрәк кара җиргә китте кереп...

## *Кышкы курорт*

Кышкы курорт. Дүртенче кат. Балконыма
айның нуры килеп кунды. Салкын гына,

эре генә тәрәз аша миңа бакты,
күзем аша эчкә үтте көмеш якты,

әйтерсең лә фонарь башлы кабель йоттым...
Һәм җаныма минем шулчак нидер йокты.

Юк, чир түгел. Һәм сагыш та... Ут сүндердем,
һәм тәрәзә экранында нәрсә күрдем —

мин фәрештә кебек үтә күренмәле —
үзем аша йолдызларның җемелдәвен,

айны болытлар юганны карап торам,
пәйгамбәрдәй горур гына тамак кырам —

фани Җирнең берние дә миңа чиртми...
Ләкин... тере, дәртле, елак җылы җитми

кышкы курорт, дүртенче кат балконында,
ай бакканда күзләремә салкын гына...

* * *

Барганда чаптардай атылып,
абынып егылды өметем.
Һушына китердем мин аны,
чәбәкләп, яңаклап, чеметеп.
Каршыма утырттым әйбәтләп,
бәйләдем яралы маңгаен.
Ихластан юатып карадым —
өметем мине һич аңламый.
Кан көеп ябышкан ирненә
яшемнең тамыздым авырын...
Кан аша саркытты өметем:
— Тамырым...

* * *

Ак теплоход...
Көзге салкын Идел...
Җылы салон төнге моң тулы...
Пианистка уйный...
Йөрәгемне
учлап тоткан ләкин бер кулы...
Кайвакытта шундый кысып ала —
туктап кала каным агышы.
Шул вакытта җаным буйлап ага
музыканың серле сагышы...
Саркып чыга Идел өстенә ул
һәм кушыла төннең серенә...
Дөнья шулчак фәкать минем моңга,
сагышыма минем төренә...

Гомер елгасында
ак теплоход...
Ярга чаба ярсу дулкыны...
Пианистка уйный...
Йөрәгемне
кысып тоткан аның бер кулы...

## *Су төбе*

1

Су төбендә ята уйларым...
Су төбендә ята хисләрем...
Уйларымда Идел буйламый,
хисләремдә дулкын төсләре...

Су төбеннән инде аларны
күтәрәсе килә яктыга...
Уй-хисләрем, артык авырга,
йөзә алмадылар, баттылар.

2

Су астында ята уйларым,
су астында ята хисләрем.
Җайсыз, ахры, анда аларга,
тыныч түгел Идел өсләре.

Шадраланып кайчак карала,
әйтерсең лә ачы сызлана.
Кайчагында килә бөрешеп,
әйтерсең лә уйлар кузгала,

бөердәге кырлы таш сыман
тырнап, тишеп, ертып, канатып...
Кайчагында соры һәм боек —
акчарлакның сынык канаты...

3

Биралмады Идел тынычлык,
басалмады җанның ярсуын...
Диңгез дулкыныдай ымсыну...
Шлюздагы кебек тарсыну...

* * *

Җир кабат әйләнеп чыкты
Кояш тирәли...
Ә күзләрнең нурлылыгы
шул ук, күр әле!

Ә сүзләрнең җылылыгы
бераз арткан күк,
һәрбер авазына назлы
ялкын тарткан күк.

Күңел шундый тирәнәйгән —
табылмый төбе,
хәтта чиксез җиһан белән
ул тоташ кебек.

Галәмдә бер ел эчендә
бихисап йолдыз
үлгәндер дә, тугандыр да —
булмый ул шунсыз.

Ә күңелем җиһанында
яктылык шул ук —
мине назлы балкыш итә
җаныма тулып.

Тик йөрәкнең кайнарлыгы,
бәлки, кимрәктер —
вакытка буйсынмый янган
йөрәк сирәктер...

* * *

Фикер ул — бар... Тик күренми генә
ак кәгазьгә төзек сүзләр булып тезелмичә.
Һәм син дә бар... Ләкин сизелмисең,
җанга кием теккән кояш нуры өзелмичә...

## *Кипр эскизлары*

1

Килеп төштем дә Кипрга,
төрендем акка —
онмы икән, көлме икән
бу ак туфракта?

Иләп карарга булмады
кирәкле иләк...
Ә күңелдә тамыр җәйде
тынгысыз теләк.

2

Мунча ләүкәсендәге күк
урамда эссе.
Кояш, яндырып, һаваның
ашаган төсен.
Ак болытлар ак гөмбәздә
чак-чак беленә.
Һәм сүзләр дә килер-килмәс
тора телемә.

3

Җилсез вакытын дөньяның
күрдем Кипрда —
чайкалу юк диңгезендә,
агачта, кырда,
дәүләтләрнең әләмнәре
чүпрәктәй гамьсез...
Гел дулкынланган күңелгә
мондый көн тәмсез.

4

Йа борыннар! — тукмак, төймә,
чөгендер, кылыч...
Ләкин ямьсез кешеләр юк —
бары да тыныч.

Юк тән төсе, дин һәм милләт,
карты һәм яше.
Һәр кеше ихлас елмая —
һәр кеше яши!

5

Елгасыз ил!.. Гөлләре аз...
Агачлар карсак.
Җигелеп эшләр җире юк,
ял итеп арсаң.

Яңгыры да елда ун көн
санап ява, ди...
Күп илләр кесәсен юып
елга ага, ди...

6

Ят кешеләр... Ят ил... Тел дә
чак ипи-тозлык.
Җанга якын беркем дә юк...
Һәм юк ялгызлык.

Ә күңел көр. Йөрәк юмарт...
Төште авызлык.
Кесәдәгене диңгезгә
теләп тамыздык.

7

Диңгездә сентябрь — күктә
Ай да, кояш та
бер-беренә якты нурлар
сузып тоташкан.

Мин дә нур эзлим, йолдызга
күз ата-ата.
Күз алдыма илем килеп,
үксеп елата.

* * *

Кичерегез, зинһар, кичерегез,
авырга алсагыз да.
Дошман түгел миңа һичберегез,
утларга салсагыз да.

Мин, дусларым, кайчак сездән арыйм,
сездән дә түгел — сүздән.
Далаларга чыгып җилләр тарыйм,
күкне күчерәм күзгә.

Агачларның кайрысында сырлар —
бөек гыйбрәт ызаны.
Үләннәрдә яши сүзсез җырлар,
җыр җылысын кызганмый.

Таштан, судан, болыт сәнамыннан
илһам иңә, тутыра...
Шигырь язарга дип каләм алам —
рәсем ясап утырам.

Мин сүзләрнең сурәтләрен ясыйм —
аңлашамын һәр телдә.
Һәм йөрәкне били рәхәт басым...
Кайта яшәү дәрте дә...

* * *

Өндәме бу, төштәме —
яшерен очкан бер йолдызның
керфегемә төшкәне?..

Мин мәрттәме, уяумы —
шул йолдыздан аккан нурны
эчәм-эчәм, туялмыйм.

Мин җанлымы, җансызмы —
тәнем эреп юкка чыкты,
шәрә калган аң сызлый...

* * *

Нишләтим мин сине, нишләтим?
Дәрьялар иркенә салыйммы?
«Коткар!» — дип ялварып кул сузсаң,
ботаксыз тал булып калыйммы?

Өермә эчендә бөтереп,
яшенле болытта өтимме?
Син аска очканда яныңнан
мин сукыр бөркеттәй үтимме?

Нишләтим мин сине, нишләтим?
Зиндандай кысыймчы кочакта —
янып бет көнләшү утыннан
кабынган аяусыз учакта.

## *Ләкин назлап*

Бик авырдыр, сизәм, сиңа минем белән —
мин бит һәр көн бәгыреңне ертып бүләм

һәм иң матур өлешен үземә алам.
Һич рөхсәтсез... Елата-елата... Талап...

Әйтерсең мин ач юлбасар, кансыз карак!..
Ләкин назлап, моңлы күзләреңә карап,

бармагыңа бармакларым үрә-үрә,
чәчләреңә чәчем белән керә-керә...

Бик авырдыр — үзеңә калган өлешне
саклап яшәү минем белән дә бүлешми...

* * *

Шатлыкның соңгы тамчысы кипкән мәлдә,
күз төбенә утырганда гел тоз, гел тоз,
көтмәгәндә күкләр күкрәп, өстебезгә
яуды йолдыз, яуды йолдыз, яуды йолдыз,

дигән идем... Ныклап баксам тирә-юньгә —
боз борчаклар тәгәрәшә юлсыз, сансыз...
Табигатьне гадел диләр иде һәрчак —
ялгышканбыз, ялгышканбыз, ялгышканбыз,

дигән идем... Калтыранып, җыерылып,
кочагыма сыендың да калдың тынсыз...
Баш түбәмдә боз ядрәләр сикереште,
күңелемдә яуды йолдыз, яуды йолдыз.

## *Узгынчымы, ярмы?..*

Алтын балдак сул кулымның
исемсез бармагына
күчкәч ничек эләкмәдем
комсызлар кармагына?!

Ә син башкача уйлыйсың —
шул хакта сөйли күзең...
Йөрәгемне капшый-капшый
эзлисең кармак эзен...

Кемнәр алар бәхетлеләр —
артымнан йөрүчеләр,
ләззәттән аккан яшемдә
шашып су керүчеләр?

Аңлыймын сине, аңлыймын...
Ләкин хакың бармы соң?
Үзеңә үзең җавап бир:
узгынчымы, ярмы син?..

## *Син барында*

Бу дөньяда син барына
чиксез шатмын —
сине белгәч, мин үземне
үзем таптым,
каш астыма куйдым синең
күзләреңне.
Үземнеке иттем синең
сүзләреңне,
дөньяны да тыңлыйм синең
моңың аша,
тормышка да мин синең
аша тоташам,
син барында мин кояш кебек
тырышмын,
судай юмарт, туфрак кебек
уңдырышлы.

* * *

Кем идек без?
Һәм кем булдык?
Әйдә, җаваптан качыйк...
Маңгай күзләрен йомыйк та
күңел күзләрен ачыйк.
Калыйк кара шар эчендә...
Яктырыр ул бераздан.
Яшел балкышта шәйләнер
безгә дип Ходай язган.
...Хәрефсез сүзләр бураны
тынар, килер тәртипкә...
Теләсәк, «ят» дип укырбыз,
ә теләсәк, «яр» дип тә...

* * *

Булдылар кояшларым да,
булды йолдызларым да...
Аларның нурлары сүнде
чәчемнең ак карында.

Булды минем тулган аем...
Булдылар метеорлар...
Аларның якты нурларын
еллар калдылар урлап.

Яктырткычларым сүнсә дә,
суга төшкән чаткыдай,
сөюгә мәдхия язам!
Язам нинди яктыда?

* * *

Ничә йолдыз яктысында
үсте икән бу чәчәк —
һәр яфрагы төрле төсле
кайнар, салкын нур чәчә...

Ят йолдызлар салкынлыгы
канымны боз иттерә.
Кайда йолдыз? Кайда соң таш —
чәлпәрәмә китерәм!

* * *

Язылысы язылган...
Бик күп нәрсә сызылган...
Ак кәгазь дөньясында
мең чакрым узылган,
хәрефкә хәреф ялгап,
сүзләрдән җөмлә тезеп,
шатлык тауларын кичеп,
кайгы диңгезен гизеп...
Шаккатырырлык нәрсә
бу дөньяда калмады —
хәтта үлемнең зарур
икәнлеген аңладым,
моның белән килештем...
Ләкин шуны аңламыйм:
ник кеше, «Сөю — бәхет!»
диеп, үзен алдалый...

* * *

Шәм таягын ут табага
китереп төрткән чакта
ул ничек эри? Нәкъ шулай
күз нурым минем чартлап,
чатнап, кайнап, күбекләнеп
эри күзеңә тисә...
Ә дөньяда вакыт булып
җәннәт җилләре исә.
Суыта кайнар ташкынны...
Йөрәк түренә җитеп,
ташкын туктый...
Шул чакта да
күз йомарга көч җитми...

## *Киеренке сөйләшү*

— Күп чикләр үтелгән...
күп офыклар артта калган.
Ачыкланды: хисләр — чын,
тойгылар — ялган...
Мин дә күптән яңа түгел —
йөрәгемдә юшкын
катып инде гранит булган,
ә тойгылар, ышкып,
аны шактый шомартканнар...
Ә хисләрем, тырнап,
гранитка шигырь яза.
Йөрәкне шул авырттыра...

— Син дә инде яңа түгел...
Иске мәхәббәтне генә
төшерәсең искә,
әйтерсең лә алтын энә
кирәкле нерв ноктасын
бер керүдә эзләп таба да җәберли —
җанны суга рәхәт яшен.
Бер сүз дәшмим, йомам күзем
һәм күрәмен үткәнемнең
йөрәгемне үпкәнен...
Иреннәре сутлы... Кагылышы утлы...
Тулып таша яшем...
Таты — сиңа.
Тозы — миңа.
Мин шундый яшь йотып яшим...

## *Кем чыдар?*

Бер уянып китәрмен дә,
гөл булмас иснәр өчен,
кул җитмәслек буш ераклык
тутырыр күзем эчен.

Һәм дөньяның яме калмас,
калыр җилләре генә...
Әйләнермен кешелекнең
мин бер күгәрегенә...

Бәхет кочакта чагында —
йөрәгемдә борчулар...
Моңа бары гашыйк кына
акылдан язмый чыдар...

* * *

Җиде кат күк...
Иң биек тау...
Әллә ничә катлы син...
Кайсы катламнар эченнән
ага тылсым яктысы,
таулардагы шарлавыктай,
төньяк күктә балкыштай —
күзләрем эчеп туймыйлар,
ә күңелем — алкышта.
Кайда соң тылсымлы баскыч?
Ник яшереп саклыйсың?
Килә нур чишмәңне табып,
иренем белән каплыйсым...

* * *

Күз төбеңдәге сызыклар
җәрәхәтме, язумы?
Аларны ләззәт уямы,
әллә хәсрәт казыймы?

Бер сызыкка күзем нуры
кергән иде — өшеде.
Бу эз вакыт эше түгел,
бу эз — кеше эшедер.

Тагын берсенә кагылды...
Ул — шигырь башы икән.
Аны ниндидер бер шагыйрь
башлаган, ташлап киткән.

Пиктограммаларның серен
шундый ачасы килә!
Юк ла!.. Иң тирән сызыкка
кереп качасы килә...

## *Сукмак*

Язмышыма буйсындым да,
мин атладым зур адым...
Миннән башка бу сукмакта
кем йөри хозурланып?

Мин тезләнеп, башым иеп
иснәгән бу гөлләрне
кемнәр исни? Гүзәл гөлләр
исертәләр кемнәрне?

Кем татый бу җиләкләрнең
терек суыдай сутын,
минекедәй, шартлап кипкән,
ирене белән сытып?

Кем коена бу күлләрдә,
сыйпый камыш башларын?
Кем тыңлый ул камышларның
татлы ыңгырашларын?

Бу сукмакның кайсы очы
бәхеткә илтә икән?
Бәхеткә илткән сукмакта
без капма-каршы икәү?..

* * *

Үсмер чакның
ләззәт эчеп
туймый калган хисләре
йөрәкнең эчке ягыннан
шакыдылар, искәртеп
күңелгә кырау төшмәвен,
Җирдә Көз туй итсә дә,
сары иреннәре белән
авызымнан үпсә дә...

Кырыгымны узып киткәч,
мин кереп чыккан идем
яшьлектән калган хисләргә —
йөрәккә кызу тиде...
Чак айныдым,
исле мунча
исерткәндәге кебек...
Чыккан эземне таптым да
еладым үбеп-үбеп...

Тешләп өзеп авызлыгын,
салып атып тышавын,
яңадан дулады йөрәк...
Болыт өргән кыш аны
бераз гына да куркытмый...
Оныттым илле яшьне...
Кемдер үпте дә корытты
күземә тулган яшьне...

## *Фәрештәне чалкан егып*

Җаным коргаксыган чакта,
ярылганда чартлап-чартлап,
ишелгәндә күңел ярым,
ачылганда тамырларым,
аларга кояш тигәндә,
үләм йә калам дигәндә,
мин бер могҗизага тардым,
шул гына мине коткарды:
җаныма фәрештә керде,
күзеннән яшь сыгып бирде,
һәм яшьне эчтем йотлыгып,
фәрештәне чалкан егып
ак болытлар арасына,
чумып күзе карасына,
ә анда яңа бер галәм,
ул галәмдә тик мин — Адәм...

* * *

Күзем йомып сузылсам да,
чәчәккә тия идем...
Гөлнең дымлы керфекләре
кулымны сөя иде...

Күзем ачып эзлим хәзер —
сөрелгән кара кырлар!
Йомам күзем — кантарлары
күземнең нурын тырнар.

## *Чәчәк*

Сине ералдырган чакта
туфрак дымы, кояш нуры
татыганнардыр ләззәтнең
бернинди дә җәннәт хуры
беркайчан да бирмәгәнен
иң сөйгән әрвахына да!..
Син яралгансың кешене
матурлык белән сынарга.

Син яралгансың күзләрне
сыйларга тере төс белән,
күкрәгемне тутырырга
дәртләндергеч хуш ис белән,
кулларымны, кашларымны
яфрагың белән сыйпарга,
йөрәгемдә әверелергә
хатын-кыздан өстен ярга!..

Күбәләк булып кундым да,
татыдым мин таҗың сутын —
белми идем тәме барын
сут эчендә йөргән утның.
Мин аңа тынымны өрдем —
кабынды янгынның зуры...
Ян!.. Сүн... Дымлы туфрак бул син,
мин булырмын кояш нуры...

* * *

Сүзләреңнән сизәм кәефең,
тавышыңнан аңлыйм җаныңны.
Суга ташланыйммы?
Калыйммы?
Утка ташланыйммы?
Яныйммы?
Сүзләреңдә ярым-йортылык,
Тавышыңда кайнар корылык...
Йотсын мине шигем
упкыны,
күмсен мине
сөю корымы...
Ерагая бара тавышың...
Яшертенлек синең сүзеңдә.
Кирәкмәсәм сиңа —
түзешле...
Мин кирәкмим, ахры,
үземә...

## Нишләттең?

Мин дә җирдә бер күбәләк кенә...
Нишлисең бит, язмыш ертылды
аерыларның ястыклары кебек...
Мамык белән гомер-кыр тулды,

өем тулды, юлым, җырым тулды...
Бурадылар авыр бураннар...
Үзем кебек юлдаш очрады
кая барыйм диеп торганда...

Бозлы көннәремне эретте ул...
Һәм мин аңа мәңге рәхмәтле...
Әмма бары синең белән генә
мин сөюнең бөек рәхәтен,

татлы газаплысын, ут гөллесен,
чылбырсызын татып карадым...
Нишләттең син мине, пәйгамбәрем,
таҗлы колым, изге карагым?!

Бураннарым инде тынган иде
җилсез җирдә ястык мамыгы
тынган кебек... Язмышымда кабат
каурыйланган хисләр агымы...

* * *

Нинди озын көн булды бу!
Кояш нуры кыскарактыр!
Күзне йомгач та өзелми...
Ходаем, тизрәк тараттыр
көнгә булган ачу хисен —
минем алда ул гөнаһсыз...
Гаеп миндә: карурманнар
арасында калдым ялгыз —
якты уйлар ташлап китте
тәмам арыган башымны,
кая куярга да белмим
шөбһәмнең кызган ташын мин.
Көйдерә ул йөрәгемне —
бөтен җаным тулы төтен.
Шигырьгә генә карагыз —
сүзләре ысланып бетте.
Корымланган уйларымда
мин беттем инде буялып...
Төннең кашалот карнында
тетрәнеп, киттем уянып —
тәрәзәмә йолдыз кунган,
циклоп кебек тора карап...
Йа Ходаем, көнгә чыгар,
тизрәк, тизрәк төнне тарат...

* * *

Йокысызлык төнгә әйләндерде
мине тәмам... Һәм мин йокламыйм —
йокы даруының төймәсе дип,
ахрысы, мин кояш йотканмын.

Күз эчләрем көннән яктырактыр...
Алка-алка төсләр уены...
Ә уйларым инде алҗып бетте,
куе яктылыкта коенып.

«Минем уйлар аны туйдыргандыр...
Арыткандыр аны назларым...»
Нишлисең бит — кышның башларына
туры килгәч йөрәк язлары!..

Бөтен хисләр икегә һәм өчкә
тапкырлана икән ул чакта...
Учларына бармак кагылса да
хис итәсең: «Мин бит кочакта».

Йә булмаса: «Бәлки, минем назым
ул көткәнчә түгел, үшәндер?..
Мин күкләргә диеп уйлап чөям,
ә ул аңа бары түшәмдер!..

Ә мин аңа куанычлы гомер
вәгъдә иткән идем кайчандыр...
Якты вәгъдәләрем минем, бәлки,
күзләремә кереп качкандыр —

күз эчләрем көннән яктырактыр...
Чәрдәкләнгән төсләр бәйләме...
Йокысызлык мине тәмам изде,
һәм мин инде төнгә әйләндем...

* * *

Соңгысы алдындагысы
булды бу озатуың...
Беренче сызыгы булды
мине сызып атуның...

Кул изәдең вагонымның
каршысына бастың да...
Рельстагы Ай яктысы
калды поезд астында.

Ай яктысы ул чагында
җанымның нуры иде.
Мең көпчәк астында калып
ул сытылды, ул көйде.

Ышанмавыңны сездердең...
Күрсәттең шигең барын...
Син йөрәгемә төшерттең
чигәмә кунган карны.

Ә соңгы сызыгы булыр
мине сызып атуның —
табутымны кара гүргә
кайгыда озатуың...

* * *

Әгәр китә калсам якты көннән,
мин сине дә алып китәрмен...
Шушы уем кара төннәр буе
җанны ашый, аңны битәрли.

Җир өстендә калыр безнең юллар...
Зәңгәр күктә болыт алланыр...
Әгәр сине мин калдырып китсәм,
рухым сыкрар, җаным алданыр...

Минем алда син тууың белән
гафу ителмәслек гаепле:
сөюемне шундый олы иттең,
чак күтәрәм хәзер бу йөкне...

Беркемгә дә сине калдыралмам...
Китә калсам, алып китәрмен...
Утка бирмәм... Сират күпереннән
мин үтәрмен сине күтәреп!

* * *

Күз яшең океанында
давыл һаман котыра...
Дулкыннары — котлар очкыч!
Сыенасы яр ерак.

Җан тынычлыгым көймәсе
капланды... Агып китте...
Мине шашынган давылга
ыргытты, корбан итте.

Әмма мин батмыймын, үлмим —
океан шундый куе!..
Күз яшендә тоз белән бал
эрегән гомер буе...

* * *

Мин кояштан һәм чәчәктән
бизә алмам,
әллә ни
биздерергә теләсә дә
әфсеннәрен җәлләми!

Ипи, су һәм һава белән
тередер бары тәнем.
Тән түгел бит, фәкать күңел
татый ич бәхет тәмен.

Йөземне кояшка куйсам,
җанымда чәчәк үсә...
Мин бәхетле — шул чәчәккә
хыялым белән тисәм...

* * *

Мине сагыну сусынын
әгәр башка бирәү белән
басарга уйласаң, сизеп,
мин йөрәгем көеп үләм.

Мине сагыну утында
җылытсаң әгәр башканы,
йөрәгемнән җылы качар —
һәм әйләнермен ташка мин.

Мине сагыну газабын
күтәрергә бетсә хәлең,
сал үземнең йөрәгемә,
ләззәткә әйләнсен әле...

* * *

Мин табибың була алам,
җаның авырткан чакта.
Тәңрегә хәтле җитәрмен,
сине яклап һәм аклап.

Иблискә әшнә булырмын —
күрмәскә күндерермен,
сиңа кунасы очкынны
яшемдә сүндерермен.

Башкача да баса алам
җаныңның авыртуын —
савыгырсың, керфегеңә
кагылса кайнар тыным...

* * *

Бер исеңә төшерерсең әле мине...
Чал чәчеңнең бер бөртеге кубып җилдә
үз күзеңә кереп чәнчер, яшь чыгартыр...
Мин булырмын ул чакта бер ерак илдә

йә дөньяда... Кояш нуры үтми торган...
Һәм күрмәмен күзләреңә чәч кергәнен...
Шул чагында үз төшенә чишелеп китәр
хатирәләреңнең тыгыз бер төргәге...

Чал чәчләрең тузгыгандай тузгып китәр
безнең ачы-төче-татлы вакыйгалар...
Күзләреңә түгел инде, йөрәгеңә
кадар алар, кадар алар, кадар алар.

Сызланырсың үкенечтән... Чарасызлык
үкенечне дә тапкырлар йөзгә, меңгә...
Бер исеңә төшерерсең әле мине
бүгенгедән мильон тапкыр авыр көндә...

## *Бәхет күлмәге*

Син — чәчемне чалартучым,
язмышны агартучым,
иске хисләргә ут төртеп,
җанымны яңартучым.

Минем күнче күбәләгем,
минем кыю карчыгам,
сез — бербөтен!.. Миннән бүтән
кем сезнең көчкә чыдар?!

Син — хуш исле лалә гөлем,
минем төз кычытканым,
ачыңны да, татыңны да
гомергә онытмамын.

Син — чиргә сабыштыручым,
муендагы элмәгем!
Син — үлемнән йолучым да,
минем бәхет күлмәгем.

* * *

Җанымны алып киттеләр...
Калды аңым һәм тәнем.
Мин тере, ләкин табалмыйм
яшәү мәгънәсен, тәмен.

Җанымны башка бәдәнгә
кертәләр — сизеп торам...
Ул чарасыз... Ул теләми...
Ул — шымып калган буран.

Бәлки, аңа рәхәт булыр —
миндәгедәй дуамал
аң аны, шәт, газапламас
хисләр буйлап куалап.

Ләкин ул минем тәнемне
онытмас, кайтыр кире.
Чөнки ул мине эзләгән
җир яралганнан бирле.

* * *

Мин моңа озак түзмәмен,
мин башка чыдый алмам:
болай яшәү — яшәү түгел,
бары яшәүне алдау...

Очасы килгәндә очмау,
җырлыйсы килгән мәлдә
тешне кысып уфтанулар
кешечә яшәү мәллә?!

Күзләреңә бер тилмерү
булып баккан күзләргә
чума алмау яшәүмени?
Җавап өчен сүз әрәм...

Сине иркәлисе җилләр
җанга япканда кырау,
үкенеч суыкларыннан
ярала шулай сорау...

Һәм җавабы да ярала
сорауның чоңгылында...
Шул чакта мин чоңгыл аша
атлыйм язмыш кылыннан...

* * *

Син көчлерәк көнлисеңме?
Көнләшәмме мин көчлерәк?
Әгәр гаеп эзләшмәсәк,
бу сораулар нигә кирәк!..

Көнчелек күгәрченнәрен
кемнәр, кайчан сугыштырып
караганын күргәнең бар?
Башкалардан, әйдә, сорыйк...

Сылу ана күгәрчен һәм
батыр ата күгәрченнең
сугышканын күргәне бар
бу дөньяда, әйтче, кемнең?

Син көчлерәк сөясеңме?..
Минем гыйшык көчлерәкме?..
Аптыратмыйк әле башны,
канатмыйк әле йөрәкне...

* * *

Маңгаеңны учларыңа салма...
Барлык авырлыгы уеңның
мине иркәлисе кулларыңа
киртләч яра булып уелыр.

Юк, курыкмыйм тырналырмын диеп...
Канатырмын диеп куркамын...
Язмышым да янгын чыгарыр күк
уйларыңнан утлы нур тамып...

## *Кагыл... Кагылма...*

1

Кагылмачы керфекләрең белән —
кытыклама минем канымны.
Күз нурларың гына орынгач та
җуя яза идем аңымны.
Кагылмачы керфекләрең белән.

Кагылмачы миңа тының белән,
исертмәче хисләр сакчысын —
Чигәләргә көзләр кагылганда
язга кабат кайтыр чакмы соң?..
Кагылмачы миңа тының белән.

2

Кагыл, кагыл миңа тының белән —
исеримче тагын, исерим.
Еллар уза, йөрәк туза икән,
ә хисләр саф кала, искерми...
Кагыл, кагыл миңа тының белән.

Кагыл, кагыл керфекләрең белән —
котырынсын каным, дуласын,
килә минем синең сүзләреңә
назлы ташкын булып туласым...
Кагыл, кагыл керфекләрең белән.

## Төнге күбәләкләр

Синнән берни яшерәсем килми инде...
Ачыласым килә тәмам, ахыргача...
Миндә ләкин төнге күбәләкләр дә бар,
кояш чыкса, алар әллә кая кача.

Бөркетләрем, лачыннарым, аккошларым,
тургайларым билгеле ич сиңа күптән —
күз нурыңны алтын балкышка маналар
алып менеп китәләр дә якты күккә...

Ләкин миңа күбәләкләр кадерлерәк —
чөнки алар үземнән дә минем кача...
йөрәгемнең көне мәгълүм һәркемгә дә,
аның төнен бары сиңа гына ачам...

* * *

Иске елның яңа шигыре син —
яңа тынлык, яңа ярсулар,
яңа аһлар, яңа ярлыкаулар...
Миңа җандаш алар барсы да!

Хәреф-хәреф сине беркеткәндә
ак кыр төсле ап-ак кәгазьгә,
һәр сүзеңә сеңеп кала килде
минем кайнар җаным әз-әзләп...

Җылылыгым, яктылыгым — синдә.
Дулый аңым, хисем — бигрәк тә.
Яңа елда иске шигырь булып
яшә әле тагын йөрәктә.

* * *

Мине чиргә сабыштырдың,
сагыну белән сынам...
Күз йомып алган чакта да
мин сызланып юксынам,
котым очып күзем ачам
тизрәк күрергә теләп —
син бит миңа бу дөньяда
бирелгән сихри бүләк!
Күрәмен дә — онытамын
гомер чорын, сәгатьне...
Син бит минем яшьлегемнең
үлемсезлек сәләте...

* * *

Мин сиңа ашкынып кайтам...
Син соң мине көтәсеңме?
Күрәсеңдер, мин — сөюнең
сагыну дигән рәсеме
булып бетәм инде тәмам,
тик бер генә хис сурәте...
Ләкин синнән килгән тылсым...
күзеңдәге нурлар дәрте
миңа кеше кыяфәте
һәм җан кертә, яшә, диеп...
Һәм мин яшим сагынудан
каным кайнап... Яшим сөеп...
Яшим сызлап... Кайчакларда
сөюемнән шаша-шаша...
Тәмуг әллә җәннәттәме —
ник мин ут белән тоташам?

* * *

Хисләрнең барлык болыты
күземә минем тулган...
Түгеләм хәзер өстеңә
булам да кайнар туфан.

Кагам, сугам, тончыктырам...
Һәм коткарам аннан соң.
Син гөнаһлы минем алда,
аңлый алсаң, аңларсың —

яшьлегемдә очрамадың,
була алмадың ярым!..
Хәер, мин дә белмәдем шул
бу дөньяда син барын...

Ләкин мин сине эзләдем,
таба гына алмадым...
Күзләремдә минем болыт...
Алар сөйләр калганын...

* * *

Ник үзеңнән этәрәсең?
Яратасың лабаса.
Һәрбер сүзең боз-тау булып
йөрәкне минем баса.

Сине ураган томанны
үзең чыгардың уйлап.
Мин аязда, син томанда —
йөрмик качышлы уйнап.

Син бит мине таптың инде,
мин дә бит сине таптым...
Синең күз яшеңне эчеп,
мин җырлы чәчәк аттым...

Аны күреп син куансын,
горурлансын өченгә...
Балы элеккечә татлы
калсын чәчәк эчендә.

Ник үзеңнән этәрәсең?
Яратасың лабаса!
Кайнар сүзең боз-тау булып
йөрәкне минем баса...

Аңа бөтен галәм тулган,
үзе кушучка сыя,
үзе синең сандугачлар
бала чыгарган оя...

* * *

Синең язмыш — миңа яңа дөнья...
Үзгә җилләр, үзгә яңгырлар...
Ләкин анда яшьлек серләреңнең
кайтавазы яши яңгырап.

Бу дөньяда миңа җиңел түгел...
Кайтавазның кайнар дулкыны
йөрәгемә бәреп керә... Хисләр
җил-давыллар белән туп-тулы.

Монда синең үткән сукмакларың,
еллар күмми торган күпме эз!..
Шул эзләргә баскан саен телдә
туа беркем белми торган сүз...

Аңлап булмый, әйтеп булмый аны,
кертеп булмый һичбер җөмләгә.
Бу дөньяда һәм рәхәт тә, чөнки
шушы сүздән җаным җимләнә.

## *Өченче дөнья*

Теге дөнья...
Һәм бу дөнья...
Ә син — өченче дөньям...
Ике дөнья хасиятен
Мин синең белән тоям.

Җәннәтләрдә рәхәтләнәм,
тәмугта көн-төн янам —
ләкин һич качасым килми
мондый «теге дөньядан».

Сәясәт өермәләре,
мәшәкатьләр гел яңа!..
Алар синнән аералар
җанлы-тәнле дөньямда.

Иң хыялый төшемнән дә
ниндидер көч өн ясый...
Җирдәге иң зур могҗиза —
син, Мәхәббәт дөньясы!

## *Синле-синсез...*

Кулда сәгать авырая,
туйдыра кигән күлмәк...
Шундый чакта синең хакта
туа газаплы теләк:
югалырга күз алдыңнан
сөртеп алган яшь кебек —
синле-синсез булып яшәп
мин бетәм инде кибеп...
Югалырга...
Тукталырга
туктаган сәгать сыман...
Акылымны томан баса,
йөрәктә нидер сына,
сәгатьләр озынаялар,
авырая минутлар...
Шундый чаклар бик еш була
бары, бары син юкта.

* * *

Салкын буранда мин ничә тапкыр
адашып йөрдем, ә калдым исән.
Ләкин белеп тор — мин сукыраям,
күзең суыгы күземә тисә...

Ә дөнья салкын... хәтта җәй көне,
дөнья күңелсез хәтта кунакта.
Җаныңда буран улаганда да
оныта күрмә, җаным, шул хакта.

* * *

Күпме елау елгаларым
агылмады — калдым чыдап...
Эчкә йотылган яшьләрем
хәзер сүзләр булып чыга.

Үпкәләмә, колагыңнан
йөрәгеңә акса ялкын —
еллар буе сагынудан
янартаулар булып яндым.

Сәерсенмә, ишетелсә
томан кебек таркаулары —
синсез узган көннәремнең
мәгънәсезлеге болары.

Үпкәләрем, үкенечләр
чыксалар — җирне төрерлек,
алары — йозак астында,
ачкычын янып эреттем.

Ә каргышлар килмәделәр
иң авыр мизгелләрдә дә —
тоткарлады син җаныма
кертеп корган изге пәрдә.

Син кабат минем янымда.
Нигә торыйм инде чыдап?! —
Мин сөюемә сокланам
иңнәреңә ятып елап...

* * *

Минем дөньям сиңа тылсымлыдыр...
Минем дөньям сиңа кызыктыр...
Һавалары ачык — бер оч әле,
диңгезләре ачык — йөзеп йөр...

Юлларында аның замананың
мәшәкатьләр тулы ташкыны.
Аяк бассаң, теләгеңә сеңәр
аңлаталмый торган ашкыну.

Һәм бар анда... юк, юк, сукмак түгел,
тирән, ләкин ялгыз эз генә —
сине минем йөрәгемә кerткән...
Һәм күрәбез аны без генә...

Шуннан гайре башка могҗизалар,
шаккатыргыч серләр юк анда.
Тик шунысы — дөньям минем матур,
анда синең нурың булганда...

* * *

Аh, ул көнне вакыт тасмасыннан
кисеп ташлар идем...
Әмма мин
гомер агышымның өзеклеген
берничек тә ялгый алмамын.
Сикереп чыгып булмас ул араны,
очып чыгып булмас...
Йөзеп тә...
Берни күпер була алмас иде
Мин ул көнне,
җылы кертәм диеп,
гүр тирәнлек утлы өзеккә...
йөрәгеңнең ачтым ишеген,
салкын давыл тулы уйларымнан
бер көрт төште аңа ишелеп...
Суык тиде күзең нурларына,
бизгәк тотты тәмле телеңне.
Ул көн, агу сөрткән хәнҗәр булып,
бавырымны кисә, телемли...
Вакыт оча...
Ә көн артка калмый,
Һаман килә — тәмам ябышкан.
Ул көрт эрер, беләм, сөям диеп
пышылдаган җылы тавыштан.

* * *

Кар сырдырып йөргән көннәр онытылмый...
Онытылмый яңгыр сеңдергән көннәр дә...
Күз ачкысыз, баш тыккысыз ул көннәрдә
бармый кала алмадым соң мин кемнәргә?

Бернигә дә карамыйча, кешеләргә
бөек дога илтә торган пәйгамбәр күк,
әни белән әти янына ашыктым
кара төндә, хәтәр көндә, кичен, иртүк...

Иблис уйнап, Алла каргаган көндә дә,
җан чыгарга торганда да, авырый-авырый,
тау-таш ишеп, диңгез дулкыннарын ертып,
итәгеңә килеп аудым, сөйгән ярым.

Кар сырдырып килдем әле кашларыма...
Керфекләрем — боз сөңгеләр... Күрәсеңме?
Йөрәгемдә күз ачкысыз каты буран...
Ишек ачык... Курыкмыймсың?.. Керәсеңме?

## *Язмыш*

## *(Тапкырлаучы һәм Бүлүче)*

1

Мин арыдым инде болай яшәп —
бүлгәләнеп бетеп йөзгә, меңгә.
Күккә чәчрәп янган чаткылардан,
күмер түгел, калмый хәтта көл дә...
Чәчрәп-чәчрәп очкан тамчылардан
дымланалмый хәтта сыек тузан.
Мин шул чаткы... Мин шул тамчы... Әй лә,
гомер уза, гомер уза... Уза...

2

Мин арыдым инде бар җылымны
меңгә түгел, миллионнарга бүлеп.
Миллионнарның кайберләре хәзер
мескенәйтеп карый миңа, көлеп,
янәсе, мин күптән артка калдым
акча куып чапкан заманадан...
Акчаны да бүлә генә беләм,
кушу-тапкырлауда мин — чи надан.

3

Мин арыдым инде... болай яшәп —
үз-үземне тотып тар кысада...
Ләкин һаман бүлгәләнә бирәм,
бүлгәләнгән саен ярсысам да.
Тамчы булып чәчрәүләр кадерле,
чаткы булып очулары рәхәт.
Тапкырлаучы һәм Бүлүче бер үк —
Аңа рәхмәт инде, Аңа рәхмәт...

* * *

Беләсеңме, һәрбер кеше — Җирдер.
Мәхәббәте аның — Кояштыр.
Гомер буе аеры булсалар да,
тарту көче аша тоташтыр.

Ничә кышлар туңып яшәдем мин,
сирәк язлар эреп актым мин...
Башканыкы булып яшәсәм дә,
һәрчак тойдым синең яктыңны.

Җылылыгың гына кагылмады —
арабызда тонык Ай торды...
Салкын нурда күз яшем кайнады —
язмыш миңа шуны йоттырды...

* * *

Тамырымда каным агар-акмас
хәлгә килгән авыр бер көндә
син аңарга язгы дәрман бирдең,
араладың кәфен көртеннән.

Ә мин сине яраладым гына,
бозларымны ташлап ярыңа...
Менә тагын каным агар-акмас,
йөрәгемдә бозлар ярыла.

Мин күкләргә карап сөрән салам.
Тавышларым ләкин карлыккан.
Ә син ишетәсең... Тәңре бул да
мине, гөнаһлыны, ярлыка.

* * *

Хөкем ит син мине...
Хакың бар...
Җәзаның бир иң дә катысын.
Җаным кайный горур газапта,
хурлык суыгын да татысын.

Үтерүче булдым шактыйдан —
туам диеп җанны кыйнаган
шигырьләрне атам терәп мин
акылдагы кирпеч коймага.

Туса алар,
аваз салсалар,
болганыр күк язмыш елгасы,
сикерермен кебек чоңгылга,
муеныма капчык ком асып.

Карар чыгар —
ас, кис, утка сал,
албастыдан таптат, диюдән...
Җырламый да яши алырмын,
мәхрүм генә итмә сөюдән...

* * *

Исерттең син мине шәрабсыз...
Күз карашың шундый хәмерле —
биләп алды мине тулаем
шул хәмернең назлы әмере:

күлдер инде минем күзләрем,
камышларын гына сыйпа бер,
курыкмасаң чоңгыл йотудан,
уртасына күлнең йөзеп кер;

иреннәрем — инде чәчәктер,
кипшенгәндер утлы сусаудан.
Курыкмасаң ялкын кабудан,
алсу болыт булып аңа там...

Ә кочагым... белмим, нәрсәдер...
Вәгъдә итә нидер... Чакыра...
Ул әйләнә ике теләкне
бер италган изге чатырга.

Исерттең син мине шәрабсыз...
Күз карашың шундый хәмерле —
сизенәм дә, аңламыйм да мин
шул хәмернең шашкын әмерен.

* * *

Синең ихлас теләкләрең
тормышка ашалар миндә:
якты көн уртасында да
әвереләм кайчак төнгә,

җылы караңгылык булып
сине дәртле назга төрәм,
керфекләреңне барлыймын
тыным белән берәм-берәм.

Кайберләреннән яшь бөртек
иреннәргә минем күчә...
Аптырыймын — әллә ширбәт,
әллә инде ачы эчәм?!

«Нилектән?» диеп сорыймын.
Җавап урынына — тынлык...
Бер карасаң — ул шатлыклы,
бер карасаң — бераз моңлы.

Кисәк-кисәк тын аласың...
Тының әверелә сүзгә...
Һәм моңның шомын ишетәм:
«Көнгә әйләнәсең тиздән...»

* * *

Мин төн кичтем...
Өйдә түгел...
Җирдә дә түгел хәтта...
Сөюнең гарше көрсие
урнашкан бөек катта.

Ләкин берни хәтерләмим,
чөнки берни күрмәдем,
беркем белән сөйләшмәдем,
чыкмадым һәм кермәдем.

Мин эредем һәм таралдым
галәм чиксезлегенә —
җирдәшләрем гаҗиз булып
беткәндер мине эзләп.

Ләкин үзем яши бирдем
бөтен бер аң, җан булып,
дөньяның барлык ләззәте
бер миңа гына тулды...

Тамырларым, һәр күзәнәк
бәлзәмләнде ләззәттә...
Көнләшмә, Тәңре, бит мин дә
әйләндем үлмәс затка!

* * *

Тәрәзәңә көне буе
болыт булып тордым карап...
Сине урлап китәргә дип
килгән идем бит мин — карак...

Көне буе күренмәдең,
ә мин көттем, көттем, көттем,
шәүлә булып тәрәзәңнең
пыяласын ничә сөрттем...

Түзалмадым, иңрәп тамдым,
күзле авыр тамчы булып...
Сине күрдем дә шартладым,
яшен ташлы камчы булып.

Тәрәзәгә карадың да,
көн аяза, якты, дидең...
Җаныма тиде сүзләрең,
каным янды, аңым көйде...

* * *

Яңгыр булыр, ахры, —
кибә учым...
Хыялым да никтер
биек очмый.

Уйларымны нидер
сөйри аска...
Чәчләренә уйның
кемдер баскан,

каерттырып күккә
ияк очын,
әйтерсең лә уйны
суяр өчен...

Авызына уйның
коя тузан...
Һәм авызы уйның
буйга узган.

Һәм телендә уйның
ярала сүз:
«Син сөясең икән —
газапка түз!..»

Яңгыр булыр, ахры, —
учым яна...
Менә аңа күздән
яңгыр тама...

* * *

Күреп булганда күрмичә
калсам, күзләрем сызлый —
тамырларын тартыштыра
үкенечемнең тозы.

Күрергә җай булмаганда
күземне йомам... Талам...
Һәм сине ят тынычлыктан
елатып йолып алам.

Күзләремә син — куаныч,
йөрәгемә — юаныч...
Сине күргән һәр мизгелдә
мин яңадан туам ич!

* * *

Мин сине бикләп калдырдым,
югалмасын белсәм дә.
Ачкычны ерак яшердем —
ачкыч йөрәк кесәмдә.

Беркем кулын тыга алмый,
ул тишелми, киселми...
Шулай кагылгысыз иттем
сине сөю хисемне...

Сиңа, шәт, авыр булгандыр
минем хөкем карарым...
Мин дә аның үтәлешен
сулыш белән санадым...

* * *

Уйларыңнан киткәчтен дә
йөрәк түреңдә калырмын.
Сиздермичә көч бирермен,
кайчак — хәлеңне алырмын.

Онытылып оеганда,
хатирәләргә чумарсың,
әкияти казанда кайнап,
шактый үзгәреп чыгарсың.

Тирәдәгеләрең сорар,
хәлең китте мәллә, диеп...
Һәм син аларга карарсың
сәерсенеп, бераз көеп...

Җавабың да аңлашылмас —
калдырыр тик аптырашта...
Шулай синең уйларыңа
кайтачакмын яңабаштан.

Кайтачакмын, кайтачакмын...
Фараз кылмыйм, яхшы беләм —
тирәлегеңә карарсың
минем зәп-зәңгәр күз белән,

һәм эзләрсең анда мине,
табалмассың ләкин һич тә...
чөнки әйләнгән булырмын
мәңге бетмәс үкенечкә...

* * *

Качам болыт артларына...
Югалам чыгып кырга...
Күнегәм күрми торырга
һәм ишетми торырга.
Күнегәм синсезлеккә мин
минутлап һәм сәгатьләп —
бар бит, бар бит, бар бит, бар бит
моңа җитди сәбәпләр.
Безне беркем каргамады,
һич аермады юк-бар...
Без — бер-берен күрә торган,
ишетә торган Сак-Соклар...

* * *

Йомык күз белән яшәүчем,
әй хыялый кешем син,
күзеңне ач, кара миңа —
аңың-җаның төшенсен
уеңдагыдан чистарак,
ишеткәнеңнән сафрак
бер табигать баласы мин:
көз төсе иңгән яфрак,
тозлы чыкларда юылып,
тоз тәме алган чәчәк...
Әгәр син кызганмас булсаң,
мине кем җәлләячәк?!
Ач күзеңне, кара миңа,
кара зәңгәр күземә —
юкса давылга буйсынам,
сынып төшәм, өзеләм...

## *Оялаган...*

Камыл баскан яңакларда
тырналулар назмыни?!
Йөрәгеңә оялаган
назлануның азгыны.

Күзләреңә оялаган
тилмерүнең матуры —
мине акылдан яздыра
матурлыкның ят нуры.

Учларыңа оялаган
җан өрерлек җылылык —
җылылыкның моңардан да
сихерлесе, чыны юк.

Иреңеңә оялаган
чакырулы дөм тынлык...
Иреннәрем шул тынлыкның
йөрәк тибешен тыңлый.

Гомерләр аша кичтек без
яңакка-яңак килеш...
Кырынмаган яңагымның
камыллары юпь-юеш...

* * *

Өзелмәсен,
киселмәсен,
сүнмәсен-сүрелмәсен,
дошманга да беленмәсен,
дуска да күренмәсен.

Тирәнәйсен,
кайнарлансын,
биләсен, богауласын,
гайбәтләрдән курыкмасын,
бөтенләйгә яуласын.

Матурайтсын,
батырайтсын,
нечкәртсен, назлылатсын,
таш бәгырьле кемсәләрне
сабый кебек елатсын.

Килсен генә,
булсын гына,
ел-яшькә карамасын,
җөп итә үк алмаса да,
таклыктан араласын...

* * *

Синең терәгең бар... Минеке юк...
Ятып елар күкрәк эзләдем.
Йөрәгемә таба агызам мин
күз яшемнең утлы кизләвен.

Татлы сүзләр миннән өмет итмә.
Ачылары чыкса, аңлачы...
Ачылары сүзнең ихлас була,
татлылары күп чак — ялганчы.

Иркәләнер иңнәр күп лә алар!..
Эретерлек кочак кайда соң?
Буламыни алмый калган назның,
акмый калган яшьнең файдасы?..

* * *

Күз алдыма китертә күрмә, китертә күрмә
аның башка бер учакта җылынганын —
мин бит шундый, ходам, хәтта уйласам да,
төшенкелек баткагына егыламын.

Күз алдыма китертә күрмә... Кызган мине...
Күрәсеңдер, ялварудан да оялмыйм.
Нәрсә эшлим — чынбарлыктан мильон тапкыр
көчле булгач аны чолгаган хыялым.

Күз алдыма китертә күрмә... Юк, юк, китерт—
мин лаеклы баткаклыкның дуенына.
Күз алдыма китерт — шулай мине үтерт...
Шушы шигырь калсын җансыз куенымда.

* * *

«...Яңа яр белән бәхетле
булырмын дип уйлыйсыңдыр.
Бәлки, дөрес уйлыйсыңдыр...
Бәлки, инде артык соңдыр.

Йөрәгеңдәге давылны
нигә бераз тыймыйсыңдыр —
хисләреңнең адашканын
тоймыйсыңдыр! Тоймыйсыңдыр.

Үткән — ачык, ә киләчәк —
серле! Аны тыңлыйсыңдыр...
Минем үткәнем хакына
киләчәгеңне буйсындыр...

Үз хәлеңне сизәсеңдер,
тик танырга кыймыйсыңдыр.
Мин җаныңа бәхет өрдем,
син тәнеңә сыймыйсыңдыр...»

Авыр сүзләр язды каләм...
Күңелеңне айкасын бер...
йөрәгеңне авырттырса,
каләмемне ал да сындыр...

* * *

Бөтен дөнья корым гына...
ә сулаганым—төтен.
Син киттең, хыялларымның
үзәгенә ут төртеп...

Турайсам — башым бәрелә
күмерләнгән күкләргә,
бөгелсәм — билләрем чатный,
мөмкин сынып китәргә,

чөнки син шуларга өстәп,
ут капкан барлыгыма
биек тау бастырып киттең...
Шул тауның кары гына

эреп сүндерсә янгынны?!
Юкса юк чыдар чамам,
үлем янаган чаяндай,
үземне үзем чагам...

...Мин хуҗасы бар йөрәкнең
какканмын ич капкасын...
Нигә керттең?.. Нигә чактың
син мәхәббәт чакмасын?..

Нигә ачтың? Ник кумадың
мине шундый чакта син?..

Бөтен дөньям корым гына...
Ә сулаганым — төтен.
Син миңа иң утлы хәбәр
әйттең дә... янып беттең...

## *Шулай да*

Үткән шатлыкларны чагыштырмыйм
бүгенгесе белән... Шулай да —
кайберләре йолдызларга охшаш,
кайберләре охшаш ак Айга...

Йолдызларда мәңгелек җемелдәү...
Юк йолдызның тәгәл сурәте...
Һәм йолдызлар мине сокланырга,
ышанмаска ләкин өйрәтте.

Ә Ай исә бик аз тулы тора...
Озак туа, озак үлә ул...
Һәрчак китек... Төннәремә кереп,
күзгә карап миннән көлә ул...

Бүгенгесе — Кояш!.. Чыкса — тулы
һәм түгәрәк, җылы, якты ул...
Ә баеса — дөньям кап-караңгы...
Җем-җем йолдыз... һәм Ай аклыгы...

* * *

Нигә авыз иттем бу чишмәдән?
Нигә суладым бу һаваны?
Алар бары озайттылар гына
сусавымның авыр дәвамын.

Нигә авыз иттем бу чишмәдән,
эчеп бетермәгәч бар суын? —
дулкыннары кереп авырайтты
йөрәгемнең татлы ярсуын.

Нигә суладым мин бу һаваны,
күрә торып куе болытын?..
Моңа кадәр минем йөрәгемдә
нинди туйлар булган — оныттым.

Нигә авыз иттем бу чишмәдән,
нигә суладым бу һаваны,
дарулардан шифа табалмагач,
агулардан эзләп дәваны?..

* * *

Бер тамчы авырлык сиңа
тамызсам да мин ялгыш,
әй, намусымның сөлеге,
җаныма минем ябыш,
суыр аның яшәү көчен,
тамырын өзеп ташла,
аны рәнҗеткәнем өчен
киптер, әйләндер ташка,
им җанымның барлык сутын,
үс, әверел еланга,
Ул кочаклаган муенны
урап-урап буганда,
күзләремә ләкин кара —
һәм күрерсең тамчылар.
Тамчылар — язмыш авырлык.
Аларга бары чыдар
сөюдән шашкан адәмнәр,
көнләүне җиңгән затлар...
Эч әле шул тамчыларны —
мине үлемнән сакла,
әй, намусымның еланы,
чак, ләкин исән калыйм,
утлы авырлык тамчысын
гомерем буе ялыйм...

* * *

Ул баһадирның исемен
ишеттем ялгыш кына...
Аның көбәсенә тиеп,
бик күп сөңгеләр сынган,
бик күп кылычлар кыршылган,
күп уклар очкан читкә...
Аны уйлап күп гүзәлләр
татлы газаплар чиккән...
Һәм аны бары син генә
үзеңә караткансың,
чөнки син аны чынлап та
өзелеп яраткансың...

Менә хәзер күзеңә мин
якты нур булып керәм
һәм алтын тәрәнем белән
күңелең кырын сөрәм,
чәчәм аңа шигырь булып
өлгерәчәк орлык мин...
Яман ел, йә яу килер дип,
һич курыкмыйм, курыкмыйм...
Яу башында миңа мәгълүм
баһадир чыга икән,
мин аны шигырьгә кертеп
адаштырам, юк итәм...

* * *

Пакьләндем мин...
Чистарындым...
Зур газаптан арындым.
Хәзер адәм яры түгел,
фәрештәләр яры мин.
Хәзер гөнаһ дип әйтерлек
бернәрсә дә кылмамын
(элек шаулы агач булсам,
хәзер шома колга мин...).
Сандугачлар кунмасыннар...
Кошлар оя кормасын...
Тырный алса, бәгыремне
җилләр генә тырнасын.
Сүзләр миңа тәэсир итмәс,
күзләр сихерли алмас,
назлар мине исертмәсләр,
күз яшьләре чылатмас...
Хәзер адәм яры түгел,
фәрештәләр яры мин,
дип уйларга өлгермәдем,
йөрәкләрем ярылды...

## *Парикмахерскаяда*

Чәчен аның җансыз тарак тарый,
җансыз кайчы ала умырып...
Күзләрендә — татлы йокымсырау
ә күңеле — хыял тутырук...

Тарак түгел, ә җылы бармаклар.
Кайчы түгел — Ходай ирегe
чәчне түгел, ә вакыт агышын
тарый, кисә, бора кирегә...

Ачар күзен һәм көзгегә карар...
Күрер үзен:
әле яшь ласа!
Соң түгел ич, әгәр язмышында
ул өр-яңа сукмак башласа —

яңа кырлар, яңа урман аша
җылы, җайлы яңа бер өйгә
алып бара торган матур сукмак!
Яшәр иде шунда бер көйгә,

үзе теләгәнгә ләззәт биреп,
үзе теләгәннән сөелеп...
Янсын иде бөтен үткәннәре,
киселгән чәч кебек өелеп...

Күзен ачты...
Чәче җыйнакланган,
Чал юллар да инде шәйләнми.
Ул елмайды...
Елмаюы ләкин
керфегенә никтер бәйләнми...

* * *

Кама өсте — куе болыт...
Болыт артында — төндер...
Томан булып су өстенә
җәелә җылы эңгер —
сихер тулы, хыял тулы
вакытыдыр җиһанның...
Суладым җылы эңгерне —
җанга җылы җыйнадым.
Кама өсте — куе болыт...
Болыт артында — төндер...
Төн эченнән, бер җыр көйләп,
мине чакыра кемдер.
Сихер тулы, өмет тулы
вакытыдыр җиһанның...
Суладым шул җылы төнне —
җаныма моң җыйнадым.
Кама өсте — куерган төн...
Ә төн артында — ал таң.
Ул ал таң әллә чын нурдан,
ул ал таң әллә алдау?!
Сихер тулы, хыял тулы
вакытыдыр җиһанның...
Суладым таңнар нурын мин
җанга якты җыйнадым.

## *Яшермәм*

Күзләремнән ялган эзләмә син —
тапкан кебек булып тоелыр.
Күз карасы — Күңел һәм Җиһанны
тоташтырган серле коедыр...

Күңел төпкелендә ни генә юк?!
Ни генә юк чиксез Җиһанда?!
Әллә күзләр дөрес күрәләрме
мөлдерәмә күзьяшь җыйганда?!

Күз яшендә бөтен нурлар сына,
чарпаланып читкә сибелә...
Черек утын якты йолдыз белән
бутап куюың бар... Кем белә...

Күзләремнең зәңгәр нурын эч син,
йә авыз ит ачы яшеннән,
ялган гына ләкин эзли күрмә...
Яратуым бетсә — яшермәм...

* * *

Миннән алда үлеп китә күрмә —
салма иңгә яшәү бәласен,
син бит минем соңгы мәхәббәтем,
гомеремнең ахыр мәгънәсе,
күңелемнең соңгы лалә гөле,
күзләремнең соңгы шатлыгы,
иренемә кунган соңгы үбү,
хыялымда соңгы яктылык.
Миннән алда үлеп китә күрмә...
Яшәмә дә миннән калып син...
Икебездә Кояш бергә сүнсен,
икебездә бер Ай калыксын...

* * *

Көннәреңне генә миңа биреп,
бәхет бүләк иттем, диденме?
Синсез төннәр кара дәҗҗал булып
кимерәләр йөрәк итемне.

Көннең яктысында сине күрәм,
җаным туймый ләкин җаныңны,
Күкрәгемдә олы күкрәү тора —
янгын хәбәрчесе чаңмыни!..

Көннәреңә төнне кушып биреп,
дәртле кичен, талгын таңнарын
өстәсәң син, бәлки, бәхетнең мин
нәрсә икәнлеген аңлармын...

* * *

Бары мин генә beләчәк
һәм тибрәтә алачак
кылларың калгандыр әле...
Мин аларны яңача —
язларның да, көзләрнең дә
хисләрен бергә кушкан
моң итеп тибрәтәчәкмен —
үзең язарсың һуштан,
ишетеп гүзәл көйләрне,
«Минме бу?!» дип шаккатып,
үз-үзеңнән гаҗәпләнеп,
ләззәттән тел шартлатып...

Шундый бер көй чыгарам дип,
мин кылларга кагылдым...
Дөнья буйлап уфтанулар,
үкенечләр агылды...
Ләкин алар кайгы түгел,
аларның бар үз сере —
алар синең бәхетеңнең
кабатланмас бер төре.

Мин генә тибрәтә алган,
бары мин генә белгән
кылларыңның яңгырашын
боздыргансың... һәм миннән.

* * *

Мин кайчакта,
кирәкмәгән сорау биреп,
үз башыма гөрзи белән орам.
Чаткы чәчри... Йөрәгемә янгын каба —
әй сызланам! Тешем кысып чыдап торам.
Күзләремнән эчкә таба, күкрәгемә,
ташып ага үкенечнең сыек бозы.
Ялкын сүнә.
Күтәрелә булы төтен —
үзе салкын,
үзе ачы,
үзе тозлы...

Югыйсә бит җавабы да кирәк булмый...
Килә шунда дөньясына кул селтәсем...
Катып калам...
Һәм кычкырам тавыш-тынсыз:
«Ник, йөрәгем, акылымны кимсетәсең?..»

* * *

Тынычлыгың киметсәм дә,
бәхетсезлегең түгел мин...
Яшь булып тулганмын икән,
йом күзеңне, мин түгелим.

Үкенечләр ташы булып
күкрәгеңне кысам икән,
турай, тетрән — мин китәрмен,
һәм кагылмам сиңа бүтән.

Бугазыңда утырсам мин
уфтану төере булып,
ятлар үбүен су итеп,
ул төерне йот та оныт...

Үтенечнең барысын да
үтә әле, үти алсаң,
ләкин уйла: мин нишләрмен
син барында синсез калсам?..

* * *

Битемдәге ерганаклар буйлап
йөрде синең кайсы бармагың?
Күзем сүнде... Җаныма син салган
эзләрне мин кабат барладым.

Тәүге тапкыр кулың кагылган эз...
Күз яшеңнең утлы тамчысы...
Иренеңнән сеңгән дәртле тетрәү...
Сүзләреңнең салкын кайчысы...

Күңел күзем йөрде эзләр буйлап.
Ачылары күпме?! Татлысы!
Кайберләре өтеп алсалар да,
кагыласы килде, саклыйсы...

Битемдәге упкыннарга төште
дерелдәгән җылы бармагың...
Күзем йомып, күңелемне бикләп,
Мин үземдә сине барладым.

## *Мәхәббәт ярасы*

Язларым ялгыз үттеләр,
җәйләрем узып бара.
Бигрәк татлы сызлый икән
мәхәббәт салган яра.
        Мин бит гел сине уйлыйм,
        якынлашырга кыймыйм.
        Күзләребез очрашса да,
        эчемә шатлык сыймый.
Җәйләр юаныч бирмәде,
гөлләрне сары сара...
Һаман тирәнәя генә
мәхәббәт салган яра.
        Мин бит гел сине уйлыйм,
        якынлашырга кыймыйм.
        Күзләребез очрашса да,
        эчемә шатлык сыймый.
Кышыма ялгыз керимме —
син шуны уйлап кара.
Әҗәлдән дә яман икән
мәхәббәт салган яра.

* * *

Югалтасым килми, дисең...
Ә соң мине таптыңмы:
төннәремдә мендәремә
күзьяшь булып актыңмы,
өр-яңа назлы сүз булып
төштеңме соң телемә,
миндә янып, әйләндеңме
хисләреңнең көленә?

Бәлки, мин — кабатланудыр,
мәхәббәтең нөсхәсе,
диңгезе түгел — күледер,
бураны түгел — бәсе...
Мендәремдә тозлы эзләр...
Телемдә назлы сүзләр...
Йөрәгемдә калган көлдән
яшимен алтын эзләп...
Табылырмы, табылмасмы
эзләгән ул алтыным?..
Югалтасың килмидер дә...
Минем бар югалтуым...

* * *

Мин кояштан көнләшмимен —
ул күрә, мин дә күрәм.
Айдан көнлим — ул төнлә дә
синең янына керә.

Айның чыгып яктыртасын
сизәм күңелем белән —
шул төндә минем кап-кара
болыт буласым килә.

Куерамын... Айны каплыйм...
Түзалмыйм — явам, тамам...
Һәм көндезен күзләреңдә
Айның эзләрен табам...

* * *

Давыл тумыйча ук үлде...
Җил кузгаткан иде көлне,
ә көл янган йөрәкнеке,
ә янган йөрәк минеке,
мин инде күптән синеке,
син генә, белмим, кемнеке,
син генә, белмим, кемнеке...

Давыл тумыйча ук үлде...
Зәгыйфьләтте ләкин гөлне,
гөлнең тамыры йөрәктә,
ә йөрәк минем күкрәктә,
күкрәгем — минем кочакта,
кочагым утлы учактай...
Кочагым сүнгән учактай...

* * *

Көтмәгәндә йөрәгемә
карлар яуды беркөнне.
Җылы якка очып китте
төннәремнең төркеме
ияреше аккошларга,
ияреше казларга
чыбылдыклы җәебездән,
ак түшәкле язлардан.
Бары көннәр генә калды
ак карларын уйнатып,
саргаеп беткән яфракта
яшәү хисе уятып.
Бар нәрсә ачык күренә
күзең йомсаң да хәтта...
Көннәрем кар арасында,
төннәрем — җылы якта.
Йөрәк яна — шәт, кар эрер,
ташу китәр беркөнне...
Каңгылдашып язлар кайтыр...
Бәлки... төннәр төркеме...

* * *

Ел агышы миндә туктады...
Үткәнемне әллә сагына?
Сине тапкан серле бер мизгел
гомер булып җанда агыла.

Ул мизгел — көн, якты көн иде...
Болытлары аның — ак мамык...
Җеп эрләдең... Аннан тукыдың
чыбылдыклык һәм ак япмалык.

Ул мизгел — кич! Әйе, кич иде.
Күләгәләр көнне эчтеләр,
бәллүр бокалларга тутырып,
мәхәббәттә безгә көч теләп...

Юк, юк! Ул төн иде, төн иде —
дәртле тәнле, кайнар кочаклы,
сүнгән күзле, тәмле телле төн!
Ул тилертте безне ничаклы!..

Таң иде бит! Озак туган таң...
Күз төбенә яткан күк томан
эчендә без йөрдек адашып,
хәле беткән ике ут сыман...

Көн иде ул мизгел! Төн иде!
Якты таң һәм җылы кич иде...
Туктап калган вакыт, син һәм мин!
Шул нәрсәләр — яшәү ич инде!

* * *

Кояшлы булсаң да салкын
булдың әле никтер син —
сүзләремә җылы бирсен
нурларыңның ник берсе!

Сөйләшәсе килә ләкин...
Әмма бар түзәр хәлем —
күземә карап аңлаучы
кешеләрем бар әле.

Салкын булсаң да кояшлы
булдың әле никтер син —
ә яктыда табып була
җылы җанлы юлдашны.

* * *

Мин кичердем бер авыр төн...
Мин кичердем авыр таң...
Әле булса уем чатный,
бөтен җаным авырта.

Ә ул төнне минем җаным
әллә ничә шомланды,
шомлануның шыксыз шавын
йөрәк туңып тыңлады.

Туңган йөрәгем утыннан
учак яга алмадым!..
Дөнья җылы көткән иде,
мин дөньяны алдадым.

Ыңгырашып беленде таң,
нуры белән чәнечте.
Җанымның сутын агызып,
тавышсыз-тынсыз эчте.

* * *

Син анда... Әйе, син анда...
Мин монда... Әйе, мин монда...
Анда синең кулың онда,
монда минем башым онда...

Анда — кызган майлы таба...
Монда — кызган җайсыз уйлар,
чатыр-чотыр чатный-чатный,
чабышалар җаным буйлап.

Анда син бәйрәмдә кебек...
Монда мин — бәйләмдә кебек —
чыбык-чабык арасында
эчтән көеп ятам кибеп.

Бәйрәмнәрдән, табыннардан
туйса да күңелем күптән,
тәмле ыгы-зыгыларны
җаным һаман өмет итә.

Син анда... Әйе, син анда...
Мин монда... Әйе, мин монда.
Анда синең кулың онда...
Монда минем башым онда...

* * *

Бәйрәм!
Бәйрәм!
Бәйрәм, диеп,
кычкыралар әллә кемнәр...
Миңа бәйрәм кирәк түгел,
миңа кирәк тыныч көннәр.
Әгәр көннең тынычлыгы
билэп алса мине тәмам,
җаныма бәйрәм кертергә
мин мең дә бер ысул табам.
Мең дә бернең бары берсе
булса, миңа шул да җиткән:
синең кайнар кочагыңда
тирли-тирли җәфа чиксәм —
моңарга тиң олы бәйрәм
табылырмы Җирдә тагын?!
...Хәзер мин «амин» дип әйтәм,
син, фәрештә, канат кагын!..

## *Дуамал ялкын*

Күзең кара күмер була
йөрәгең янган чакта,
телеңә килгән сүзләрең
очалар чатнап-чатнап.
Алар колакка керәләр,
коелалар бавырга.
Шундый чакта минем җаным
сулык-сулык авырта.
Юкса синең хисләреңә
үзем, үзем ут төртәм,
юк бит чарам — күкрәгемдә
дуамал ялкын йөртәм...

* * *

Бүген күктә йолдызлар күп.
Үземнекен таба алмыйм...
Һәр яктысы, күзен кысып,
«синеке — мин» диеп алдый...

Һәр яктысы, күзгә кереп,
йөрәгемә үтмәк була,
тик бер нур да агып китми
каным тамырлары буйлап.

Тик бер нур да яктырталмый
күңелемнең төпкелләрен,
тик бер нур да телгә салмый
үз йолдызының телләрен.

Ят йолдызлар... һәм ят нурлар...
Җемелдиләр... Агылалар...
Минем кайнар уйларыма
салкын гына кагылалар...

## *Сыгылмалы сылу*

Бакый Урманче рәсеме:
сыгылмалы сылуның,
нидер күргәч, нидер белгәч,
кысылгандыр сулуы —
менә-менә өзелергә
җитешкән нечкә биле,
озын чәчләрен тузгыткан
кемдер учының җиле.
Күзләрендәге очкыннар
даһимы йә тилеме?..
Күпноктада кайсы нокта
бит очындагы миңе?
Аның сулу кысылуы,
бәлки, мине күргәчтер,
йөрәк ишегемне ачып,
шигыремә кергәчтер?!

* * *

Мин күпме соклandым
кайсының күзенә,
кайсының күңеленә,
кайсының биленә,
буена-сынына,
төз аяк-кулына,
кайсының чәченә!..
Матурлык барысына
нигәдер,
ничектер
бөртекләп чәчелгән.
Син —
минем хыялда
сакланган күзләрнең,
күңелнең, иңнәрнең,
төз аяк-кулларның
бер төшкә тупланышы,
күңелемнең яшәр өчен
урын тапкан тукталышы!

* * *

Мин бәхетле итәр идем сине —
Ярда яткан ялгыз каекны,
Һәр күңелдә зәңгәр җилкән киереп,
Син йөзәргә, җаный, лаеклы.

Мин бәхетле итәр идем сине —
Ләйсән тулы зәңгәр болытны,
Күңелемдә, ахры, җитеп бетми
Яңгыр ясый торган җылылык.

Мин бәхетле итәр идем сине —
Бәхетсездер, ахры, мин үзем...
Сине онытырга көч бир миңа,
Ә үзеңә калдыр мең түзем.

* * *

Күзем аша үтте мең буран.
Меңесе дә һәр кешегә күренә торган.

Күңелем аша үтте йөз давыл.
Күрүчеләр, мин дә Ул.

Йөрәгем аша үтте бер зилзилә.
Аны шушы каләмем генә белә.

## *Ятлар белгәч*

Зәңгәр давыл булып, күзем аша
Йөрәгемә үтеп керде дә,
Көйрәп, пыскып яткан мәхәббәткә
Диңгез җиле булып өрде дә,
Эчкәредән кинәт дөрләп киттем.
Утыз яшьлек битем алмасы,
Унбиш яшьлек малайныкы кебек,
Күптән булмаганча алланды.
Күптән булып үткән төшләр кайтты,
Шул чактагы хисләр, оялу
Күз алдымда — төссез дөнья рәсеме...
Хыялымның барлык буявы...
Мин бизәргә тиеш шул дөньяны —
Һәр бизәге бирсен куаныч!
Һәр ир — кызга, һәр кыз ир-егеткә
Куаныч булыр өчен туган ич!
Яшерен мәхәббәтем җилдән җилгә,
Телдән телгә күчте, таралды...
Ятлар белгәч, гүзәл буяуларым
Карамаслык булып каралды.

## *Тузганак*

Бәхәсләштек бер кыз белән,
Кем уздыра ала дип,
Тузганакны бер өрүдә
Кем туздыра ала дип.
Миңа җәза мондый булды —
Тузмый ничә таҗ кала,
Шуның чаклы чакрым җиргә
Кызны күтәреп барам.
Кызга җәза шундый булды —
Ну, үзем дә үткер, ә? —
Ябышып калган таҗ санынча
Кызый иренен үптерә.
Чын көчемнән өргән идем,
Тузганак башы туздьі.
Мин: «Оттым!» — диеп куандым,
Ә кыз: «И-и-и-х!..» — диеп сузды.
Тузганак туздьі, югалды,
Кызый бер өргән иде.
Оттырып ота белмәдең,
Инде үпмә дә, диде...

* * *

Урам хәлләрен сөйли-сөйли,
Хатыным токмач кисә —
Бармаклары очында
Уйнап тора үткер пычак...
Их егет чак!.. Аның өчен ул чакларда
Йосыф кына идеммени мин югыйсә.
Миңа караган килеш,
Хатыным токмач кисә...

## *Көз инде*

Көз инде.
Җиргә төшеп алма ярыла —
Өз инде.

Көз инде.
Муллыктан өстәл сынарга тора —
Түз инде.

Көз инде.
Өзелергә җитешеп җитлеккән кыз
Үз инде...

Көз инде!

## Өч килендәш, өч баҗа

Бер кешенең җиткән өч улы булган,
Күршесендә бар икән өч кыз туган.
Олы малай тоткан да гадәт бозган —
Олы малай өйләнгән кече кызга.

Уртанчысы өйләнгән уртанчыга,
Кечесенә кызның олысы чыккан.
Өч ир туган җыелганнар беркөнне,
Сөйләшмәктә уздырганнар бер төнне.

Ни сөйләгәннәр — билгесез. Билгеле
Уртанчы — иң бәхетле икәнлеге.
Өч кыз туган да җыелган берзаман,
Төне буе сөйләшкәннәр бик яман.

Ни сөйләгәннәр — билгесез. Билгеле
Уртанчы — иң бәхетле икәнлеге.

## *Гармунчы*

Кардан арынган ярга,
Үлән яшәргән ярга
Җыела язгы парлар.
Гармунчы гармун уйный,
Уйный да үзе уйлый:
«Җырлатам да биетәм,
Өч язым шулай үтә...»
Бер кыз уенга керми,
Аккан бозларны карый:
«Өч язым шулай үтә —
Башкаларны җырлата шул,
Башкаларны биетә...»
Төшә беренче карлар...
Туй табыннары янына
Җыела көзге парлар.
Гармунчы гармун уйный,
Уйный да үзе уйлый:
«Җырлатам да биетәм,
Бу көз дә шулай үтә...»
Бер кыз туйларга керми,
Яуган карларны саный:
«Бу көз дә шулай үтә —
Җырлата да биетә, шул,
Ятлар туен туй итә...»

## *Тамырны саклау*

Яфрак ява...
Яфрак ява...
Бөтерелеп...
Уратып...
Һәрбер яфрак — көздән хәбәр!
Яхшылыкка юрадык.

Көтмәгән хәл,
хәвеф-хәтәр
кагылмады,
какмады.
Һәрбер агач, яфрак ябып,
үз тамырын саклады.

## *Яфрак*

1

Агач — күккә төбәлгән елга.
Агачта бар нәрсә кеше теләгәнчә:
Диңгез елгага,
Елга тармакка,
Тармак чишмәгә ага.
Агачта иң көчле нәрсә —
Иң кечкенә нәрсә.
Ул — яфрак.
Һәм шул яфрак
Инде күптән
Елгаларны үргә генә түгел,
Агыза күккә.

2

Мин — яфрак.
Тормышны мин
Агач итеп күрәм.
Бик күп ботаклы,
Мәһабәт кәүсәле,
Бөек тамырлы агач итеп.
Аның бер генә ноктасын
Үзем белән төрәм,
Бер генә ноктасын
Кояшка тартам.
Без күбәү —
Кәүсә үрелә безнең арттан.

3

Мин — яфрак.
Йолкыймы давыл,
Кимерәме кортлар,
Яндырамы яшен угы —

Күрәм — кәүсә ныгый.
Эш — тамырда. Хак сүз!
Тамыр бит
Җиргә баткан ябалдаш,
Ләкин яфраксыз.
Мин — яфрак.
Мин ябалдашка да охшаган,
Тамырга да!

## *Карама яру*

Орган саен шылт итәр, дип,
Карамага китереп чапты.
Балта ярып кергән турдан
Чәчрәп чыкты юеш чаткы.

Егеттә ачу кабынды —
Нык селтәнеп тагын сукты.
Күзләренә чәчрәп керде
Караманың җавап уты.

Яру-каеру мөмкин түгел —
Ул имгән Идел җиленен
Һәм ашаган бабаларның
Җиргә сеңгән кан җилемен...

Чыраларын җитен итеп
Балта тетә, балта талкый...
(Имән түгел, карамадыр,
Батыр дип атарга хаклы.)

Балта үзенә утырта,
Утырткандай казыкка кол.
Карамага каен карый,
Тирәк карый җуеп акыл...

Ә ул түзә... һаман түзә.
(Аңлашылмый бу минутта:
Әллә балта бүкән яра,
Әллә бүкән балта йота.)

Түтәсенә ята балта,
Һәм ботакка балта бата —
Өрәңге сап сынып чыкты,
Караманы вата-вата!

Ташлап сынык сапны, күзен
Бүкәнгә текәде егет:
Ә ул
Балта чәйнәп ята,
Ярсыган ак бүре кебек.

## *Бакчачы*

Ябалдаш эченә таба
Үскән ботакларны кисә:
— Ялгыш үсә болары,
Ялгыш үсә.

Киңлеккә китәргә тиеш
Адәм рәтле ботак!
Кара, күпме булачак яфрак
Ташланыла ботап...

Дөрес китмәгән ботакларны
Кисеп коймага элә...
Ә шулай да
Дөресен, түгелен
Алмагачмы, бакчачымы
Беләʔ..

* * *

Коела яшел яфрак...
Җәй иртә киткән кышка...
Ялвара өзек яфрак
Төшкәндә
Очкан кошка:
— Элеп куйчы ботакка,
Күрәсеңдер, мин яшел.
Ботагыма ялгансам,
Яшим әле мин, яшим...
Кош җавап бирә — Белмим!
Теләсәң ничек тиргә —
Тотып калып була тик
Өзелгәнче йә... җирдә.
Коела яшел яфрак...
Төшә ул көзге суга:
— Агыз теләсәң кая,
Тик мине, зинһар, сугар!
Су бирә аңа җавап:
— Язгы су түгел ич мин.
Беләсең килсә, җаный,
Мине тамыр да эчми.
Төште, акты, юк булды
Яфрак, ямь-яшел калып...
Тып-тыныч торды ябалдаш —
Күзсез, тавышсыз халык.

* * *

Яфракларың — гәрәбә,
Җирдә ята әрәмгә.
Ник чәчеңнән төшердең
Син аларны, әрәмә?

Ботакларда җил улый,
Җилдә ботаклар моңлый,
Китеп барган сыерчык
Оча моң тыңлый-тыңлый.

Барып җиткәч ни сөйләр?
Ниндиерәк көй көйләр?
Ул кире кайтсын дисәң,
Матур чың тагып җибәр!

Яфракларың — гәрәбә,
Җирдә ята әрәмгә.
Чулпы чыңлатып, кошны
Ник озатмыйсың, әрәмә?

* * *

Буылып үлә агачлар,
кибәләр сөяк булып,
кайры аслары — агулы
гөмбәләр белән тулы,
ә кортлар юк... Әнә тукран,
үпкәләп безгә шактый,
иң биек наратка кунып,
күкнең ишеген шакый —
эмигрант булмакчы була...
Бу — кешеләр модасы!
Күк ачылмый, чөнки анда
шул ук кеше Ходасы...
Арка терәдем наратка.
Белмәдем ялганасын
үле агач кәүсәсе һәм
умыртка баганасы...

* * *

Кыздырма атның аягын,
йөрәген дә кузгатма —
дәртен сүндермичә калса,
бик авыр акбүз атка.
Күзләрендә тынлык күреп,
тынычлык дип ялгышма —
син җибәрерсең ирекә,
ә ул керер чабышка...

## *Ат*

Тояклары сары сөяк,
бәкәлләре бүз кебек ак,
сыйраклары нәфис, озын,
сөлек кебек бу кызыл ат
әкияттән чыккандыр дулап.

Күкрәкләре кызыл калкан...
Сөңге очы булмак булып
тетри калкан елык-елык —
калканга да акыл тамган...

Танаулары киерелгән —
һава җитми аңа, җитми.
Башын чөеп һава тешли,
ертмак булып күкнең читен.

Маңгаендагы ак тасма
җилләр канатын каера.
Ул — давылда һәм кояшта
үз төсен югалткан байрак.

Ике күзе — ике беләү,
тот та булат хәнҗәр кайра!..

Миендә — ашкыну кошы.
Ул кан күргән, ахры, чыкта —
кошның ике канат очы
колак булып бәреп чыккан.

Сары ялы җилкәсеннән
ялкын булып агып тора.
Ул тояклар астындагы
чаткылардан кабынгандыр...

Сырты аның әзер ияр —
озын, хәтәр юллар башы...
Сул кул тезгенгә ябышкач,
уң кул кылыч сорый башлый.

## *Ярсыган ат*

Үрә басса —
якынлашма!
Ватылыр башың.
Юлдан аякка ябышкан корал —
тояк ташы.

Ачудай җитез,
сугыштай авыр
җиңел тояк...
Ат кына түгел
тоягын җирдән
аерган ат!..

Ядрәгә дә,
җилләргә дә
йөрәге ачык —
ярсыгач, ул яши алмый
посып-качып...

Ошый тояк йодрыкка,
аяк — кулга...
Көрәшче атка
кеше аты кушып була!

Һаваны кисә,
җирне тишә
тупа тояк...
Йөрәкне тоткан
кулым өчен
аттан оят...

## *Яткан ат*

Тезләр җирдә...
Тетрәтеп куя тәнен...
Дошманны түгел,
куа бары
чебеннәрне.

Күзләрендә очкын сүнгән —
йокымсырый...
Сугыш кыры түгел алда —
чәчәк кыры.

Селтәп куя койрыгын —
җилләр исми.
Ятып чайкаганда, кыл да
һава кисми.

Тоягына инде сеңгән
җир салкыны,
сыртында ул күптән тоймый
ир ялкынын.

Кылыч тагып, кем атлансын
яткан атка
замананың очкын аты
чапкан чакта?..

Аның аша
кырмыскалар
чыга атлап...
Кем атлансын
тезе җиргә
баткан атка?!

Тезләр җирдә...
Күзләрендә
җир карасы...

Юкка чыккан бу ат белән
җир арасы...

## *Беренче кар*

1

Беренче кар
Кайнар җиргә
Газинурдай ята.
Үзе үлә,
Башкаларга
Җирне салкынлата.

2

Тимер түбә
Җирдән ерак,
Ерак җирнең җылысыннан.
Кар, озаграк түзгәч анда,
Бәхетеннән елый сыман.

3

Тарихта да,
Йөрәктә дә
Беренчеләр — корбан...
Карларны җиргә озатып,
Мин балконда торам...

* * *

Еллар хәзер никтер ак кар кебек —
салмак бөтерелә,
бик тиз тына...
Биткә түгел,
янган иреннәргә түгел,
чәчкә куна.

Ява... эри... ява... эри...
Карлы башымны чөеп, мин
болытлардан эзләр санап йөрим.
Карлы башымны иеп, мин
юлдан эзләр санап йөрим.

Эзне вакыт күри...
Күрәгәне эри,
җиргә, күккә сеңә,
ташкын булып кушыла елгаларга.
Зәңгәр болыт безнең эзләр,
көмеш балык, кызыл алма,
яшел кына...

Ак кар түгел,
ап-ак килеш безнең башка
тормыш яме куна.

## *Шомырт суыклары*

Шомырт чәчәге кар кебек...
Әллә суык шуңарданмы?
Әллә агач тамырыннан
кыш китәргә соңарганмы?
Йорт казына гашыйк аккош,
аерылгандай төркеменнән,
ишетмичә-тыңламыйча
киңәшләрен беркемнең дә
тамыр төбендә калган кыш...
Арыганмы давыллардан?..
Ел фасылын тоткарларлык
ни хикмәт бар тамырларда?
Кыш кинәт исенә килгән...
Чәчәк булып күккә аша...
Чәчәктә, фәкать чәчәктә
тамыр күк белән тоташа.

## *Яшел марш*

Агачлар ага һавада
искән җилләргә каршы.
Җилферди, җилферди дөрләп
җәйнең ямь-яшел маршы.

Яфракның кайсы сызгыра,
кайсы алкышлап тора,
чырылдый сынык ботакта
тырпаеп калган чыра.

Каерыла башлаган кайры
барабан булып бәрә...
Җәйнең маршына күңелдә
әүвәл бер кыл иярә,

беравыктан — тагын берсе,
тагын берсе — аннары,
бераздан җаен китереп
кушыла калганнары.

Һәм гөрли күмәк оркестр —
ябалдаш белән кеше!
Һәр ботак — Страдивари,
һәр кеше — Сәйдәш ише...

## *Яратам сине, яңгыр*

Яратам мин сине, яңгыр, яратам —
карлы-бозлы булсаң да, —
маңгай тире кебек тозлы булсаң да,
көтмәгәндә килергә яратсаң да,
дөбердәп явып, сабантуйларны таратсаң да,
туй күлмәген манма су итсәң дә,
тузан туен бастырмыйча китсәң дә,
яратам мин сине, яңгыр.

Көндез яусаң, көмеш төсле коеласың...
Төнлә яусаң, моңсу буласың,
әйтерсең лә күкнең кара ятагында
син, суккач та тәкәббер яшеннең яңагына,
елыйсың кебек хисләреңә буыла-буыла...
Уйсулыкка сулар тула...
Миңа уйлар тула, уйлар тула...

Тамчыларың кайчак тотам телем белән —
хуш исе сүз, җимеше дә сүз гөлем белән.
Шул гөлләрдән тезәм гөләп...
Ә гөләптән керосин исе килә башлый кинәт.
«Замана!» дим, сине һәрчак пакькә юрыйм.
Үпкәләргә һич юк урын —
болытыңны мин бит ертам самолетта,
боз яудырыр диеп куркып, тотам утка.

Җирнең барлык бөек шагыйрьләрен беләм —
шигырьләреннән күңелемдәге иләм!
Ә син, яңгыр, күк шагыйре, яу, яу тынмый,
аңласам да, аңламасам да тыңлыйм
һәр тамчыңның бөек тавышын
һәм күк белән кавышам.

Яратам мин сине, яңгыр, яратам,
үләннәрне өскә тарткан өчен дә,
су сипкәнгә янгыннарның үченә,
чистартканга Җир сулыйсы һаваны,
булган өчен йолдыз нурының дәвамы,
һавалардан юганга кеше эзен,
тамызганга кеше теленә күк сүзен...
Йөгереп чыгам мин каршыңа яңгырап,
әвереләсем килеп синдәй яңгырга!

* * *

Җәен урманнарда кеше арта, арта —
кемгә җиләк, кемнәргәдер гөмбә кирәк...

Мин наратлар белән сөйләшергә килдем.
Алар белән сөйләшүче кеше сирәк...

Сүзем сеңә... Җепселләргә үтеп керә.
Күккә таба агып китә... Торам сизеп...

Әйләнә дә ябалдашка, рәхәтләнеп,
мине чакыра, ылысларын изи-изи...

Кешеләрнең күктән биек аңнарында
күпме сүзләр минем урын тапмадылар,

кире кайтып, назлы кайнар йөрәгемне
ярсый-ярсый ничә тапкыр таптадылар...

Күзгә карап күп сөйләштем гомеремдә,
кайчакларда чаткы чәчеп, кайчак — сайрап.

Рәхәтләнеп сөйләшәмен нарат белән —
күптән килә сөйләшәсем күккә карап...

* * *

Шатлык белән эшлә икән һәрбер эшне:
шатланып ач икән күзең уянгач та —
һәм күрерсең: яшәү дәрте чәчрәп тора
ботакларын күккә сузган һәр агачтан.

Шатлык белән авызың ач, сүз әйт, тыңла,
өйлән, йорт сал, бала үрчет куанычта —
юкса гомер кичерерсең менә-менә
шартлыйм дигән йөрәгеңне кысып учка.

Куанычсыз адымнарың искә төшсә,
болары да югалмаган! диеп куан...
Хәзер беләм: бәхетсезләр — куанычсыз,
бәхетлеләр олы куанычта туган...

## *Көз гөлләре*

Көз гөлләре чәчәк аткан саен,
яз яңадан кайта күңелгә.
Иң кадерле истәлекләр булып,
чәчәкләрдән чыклар түгелә.

Кайберләре тама салкын җиргә,
кайберләре тама йөрәккә...
Кайсылары икән, кайсылары
сагынырга безне өйрәтә?!

Кайберләре әнә елый сыман,
кайберләре җырлый — тыңласаң.
Кошсыз тирәк булыр иде йөрәк,
сагынулар әгәр булмаса!

Сүрән дөнья буйлап җилләр исә...
Көз гөлләре чәчрәп яналар —
«Син бит, тормыш, һәрчак җылы!» — диеп,
җырлаталар безне яңадан.

## *Төнге урман. Кыш*

1

Кышкы төнге урман...
Юкә... Чыршы... Нарат...
Барысы да башсыз...
Күк төнлә бит — карак,

урлый ераклыкны,
урлый биеклекне.
Төннең хәзинәсе
күзләр өчен бикле.

Күзләр өчен бикле,
уйлар өчен ачык —
әлбәт, кала алсаң
көндез төнгә качып.

2

Бездәге сукырлык
иң күзле әгъзадыр.
Ул күрә һәр эшнең
иң гүзәл азагын.

Ул шунда юнәлтә
йөрәкне, аякны...
Өч адым — һәм чокыр...
һәм дә без — таяклы,

баш — тишек, кул сынган,
кан ага борыннан...
Без илләр рәтенең
иң соңгы урнында...

3

Урмандагы төннең
караңгысы куе,
була кебек аңа
хәтта тишек уеп.

Әгәр шул тишеккә
үткер күзең куйсаң,
якты киләчәкне
күреп булыр сыман.

Төнне тишәр өчен
ләкин нинди көрәк,
ләкин нинди борау,
нинди кәйлә кирәк?

4

Ботаклар һәм болыт
тоташкан, укмашкан,
якты уй, кара уй
чуалгандай башта.

Җил исеп куя да,
болытлар ботактан
аерыла... Бер йолдыз
җемелди шул чакта.

Исеме бар микән?
Юк микән исеме?..
Без яшисе йолдыз
түгел ул, дисеңме?..

5

Яшибезме? Әллә
асрыйбызмы җанны?
Акылымны баса
шул сораулар чаңы.

Кача алмыйм чаңнан —
таба алмыйм җавап...
Гомер әллә бәхет,
гомер әллә җәза.

Төнге кышкы урман
мине биләп алган.
Белмим: төнме, кышмы
йә урманмы ялган?..

6

Әлегә Җир һәм Күк
Кара төс эчендә,
урманда тоташкан
илаһи көч белән.

Аларга укмашкан
кар, нарат һәм мин дә.
Кара төн күземдә...
Карурман миемдә...

Таң атар... Карга да
кайтарыр үз төсен...
Мин дә кар шикелле...
Тик җылы бер җисем...

## *Ак карлар арасында*

Гомердә беренче тапкыр
мин ак карлар арасында
җил кебек максатсыз йөрим...
Гаҗәп — кереп барам сыман
рәсем дәфтәре битенә,
бер кирәкмәс сызык булып,
чөнки дәфтәр бите күптән
матур сурәт белән тулы.
Буйсынам ниндидер көчкә —
һәм, дәфтәр эченә узып,
куз-күз эзем белән сызам
аяк аңламаган сызык —
беркая да илтми торган,
китми торган, кайтмый торган
бу эзләр буп-буштыр дисәм,
аларны шәүлә тутырган,
бераз дымлы, бераз тозлы —
күзләрдә күз яше сыман...
Монда кояш нуры сынган,
астына сагыш сыенган,
көчсезлеген яшерергә
тырышкан күз карашыдай...
Гомердә беренче тапкыр
мин ак карлар арасында
япа-ялгыз...

# *Урман*

1

Тәрәзәмдә Шишкин урманы...
Чабуына баскан буранның...
Талган инде буран тартышып —
канатына баскан аккошны
хәтерләтә... Нинди кызганыч!
Гүзәл урман биргән куаныч
әверелде кинәт ачуга...
Кайда балта? Хәзер үк чыгам,
тапап ташлыйм явыз урманны
һәм коткарам ап-ак буранны...
Урман калын.
Балта кечкенә...
Әрәм булыр
хәләл көч кенә...

2

Урман ябалдашы һәм болыт
арасында буран туй кылып,
бөтерелеп, очып, сызгырып
йөри минем канны кыздырып.
Ә мин монда, җылы пулатта,
урын тапмыйм җанга, дулатам
аны айгыр кебек, камчылыйм
һәм кызганмыйм аны тамчы мин.
Әверелсен әле буранга
һәм кирәген бирсен урманга!..
Урман калын.
Камчы кечкенә...
Әрәм булмас микән
Көч кенә?..

## *Салкын кардан җылы сүз*

Миңа кышлар да кадерле!
Көз генә түгел икән...
Кар яуганда,
бөртекләре
җанга кагылып үтә,
булдыклы ирнең чабуы
сусаган хатын-кызга
тиеп киткәндәй... һәм сизәм —
җаным балага уза.
Аннары
шул салкын кардан
туа миндә җылы сүз...
Өстәлдәге ак кәгазем
аңа биләү,
аңа бүз.

## *Кар киткәндә*

Юллар алып китәр мине
Бик ерак.
Эзем карда батып калыр —
Җир бит ак.
Кабарынкы карлар эрер —
Кыш үтсен.
Иңгән эзем, бәлки, калкыр —
Яз җитсен.
Эреми яткан эземә
Күз атып,
Сөйләрсезме: «Тора кышны
Озайтып...»
Хуш күрсәм дә чуар гөлле
Яз ямен,
Аклык гомерен озайтмакчы
Җирдә мин.
Ни кылсак та, ярылып ятсын
Аклыкта.
Бәлки, аклык алып килер
Пакьлеккә...

* * *

Җәймә-җәймә калган ак кар
Тора инде боегып...
Аланнарны тишеп чыккан
Җирнең яшел мыегы.
Ул кытыклый зәңгәр күкне,
Күк елый-елый көлә.
Ул белә:
Җирнең баласы туганда,
Күкнең баласы үлә...
Йә киресенчә...
Тик җиңелү
Була икән ярасыз...
Карасана, нинди камил
Җир белән Күк арасы!..
Кар җәймәсе калкан булып
Ныгый һәм ката иртән...
Карның, кешедән күрмәкче,
Китәсе килми җирдән...

* * *

Мин сарыдан сине киендерәм.
Көзге яфракларны берәм-берәм
үзем агачлардан чыгам өзеп,
һәм гәүдәңә куям җайлап тезеп —
алтынлансын әле, бер балкысын,
Ходайдан һәм миннән бүләк булсын!

Мин яратам көзне гашыйкларча
һәм кочасым килә аны һәрчак,
чал чәчләрен күкрәгемә куеп,
кан тибешен каным белән тоеп...
Көзне ничек коча алсын кеше?! —
бу йә Ходай, йә шагыйрьләр эше...

## *Бәсле ботаклар*

— Кем күккә таш орды?
Челпәрәмә килгән ич күк,
челпәрәмә!—
Текәлеп тәрәзәгә,
түшәгемнән сикереп тордым:
— Кем күккә таш орды?
Ныклап карасам —
күк йөзендә бары
шәрә калган алмагачның
чәчрәп торган ботаклары...

## *Нинди сүзләр?*

— Нинди сүз куәтле була?
— Уйга дәрман салганы.
— Ә нинди сүз үткер була?
— Җанны телеп алганы.

— Нинди сүзләр авыр була?
— Күзьяшь булып тамганы.
— Нинди сүзләр батыр була?
— Фаш иткәне ялганны.

— Нинди сүзләр салкын була?
— Дөреслекне танганы.
— Нинди сүзләр җылы була?
— Сиңа багышланганы.

— Ул сүзләрне кемнәр таба?
— Шагыйрь таба... Янганы:
бер саф сөю, мең хыянәт
татып исән калганы!..

* * *

Бу сүзләргә минем Идел шаһит.
Бу сүзләргә шаһит дулкыннар...
Шушы сүзләр йөрәк дулкыннарын
озак яшәтерлек булсыннар.

Һич тә бетмәс озын давыл булып
йөрсен сүзләр йөрәк эчендә.
Еллар үткәчтен дә калсын алар
нәкъ бүгенге ихлас көчендә.

Хисебезгә тынгы бирмәсеннәр,
чайкалсын ла гомер көймәсе...
Җилне җилкән сөя белгән кебек,
бер сөясем килә, сөясем!

Бер кайтасым килә малай чакка,
үткән юлны тагын үтәсем...
Һәр төнбоек саен туктый-туктый,
күзләреңне синең үбәсем
килә минем...

Ләкин көймә,
ахры, артык каты чайкала —
шик-шөбһәне хистән өскә куеп,
йөрәк упкыннарым айкала.

Бер сөясем килә!
Бу сүзләргә
Идел шаһит, шаһит күз яшең...
Аһ, мин инде җәйдән көзгә таба
дулкын куган җилләр тиңдәше...

## *Өч канатлы кош*

Каз канатларын санама —
ничә санасаң да пар...
Ә кешенең йөрәгендә
өч канатлы кош та бар.

Бер канаты сына калса,
тиеп кара болытка,
хәтта бөркет җансыз ташка
әйләнә шул минутта,

акчарлакны дулкын уба,
һәлак була сандугач, —
яшәвеңнең бар терәге
пар канат кына булгач.

Ә безнең йөрәк кошының
канаты иртә сына —
иң беренче мәхәббәтнең
бер суык иртәсендә.

Ә кош яши, ә кош оча...
Ул — мәңгелек юлдашың.
Ул — Мәхәббәт, ул өзлексез
йөрәккә бәхет ташый.

## *Әй, мәхәббәт...*

Бии алмый
агач җилсез,
җырлый алмый
фикер телсез.
Бии алмый
су дулкынсыз,
җырлый алмый
ут ялкынсыз...
Һәрберсенең
үз кубызы,
һәрберсенең
үз гармуны.
Яши алмыйм
биемичә,
яши алмыйм
җырламыйча...
Тик мин биим
тугарылып,
тик мин җырлыйм
онытылып
иң бөек көч
кубызына,
иң матур көч
гармунына...
Әй, мәхәббәт,
мин бит синсез —
җилсез агач,
сусыз дулкын,
гөлсез тәрәз,
тынсыз тавыш,
телсез фикер,
илсез бәхет,
җирсез тирәк...
Әй, мәхәббәт,
мин соң синсез
кемгә кирәк,
кемгә кирәк?..

## *Кар башына кар җитә*

Кар башына кар җитә —
яңасы явып эри дә
искесен алып китә.

Сөюнең сүнмәслегенә
ышанычны сүтә-өтә,
яр башына яр җитә —

кар башына җиткән кардай,
әүвәл бар дөньяңны бизи,
аннары — эри... үтә...

Кар башына кар җитә...
Яр башына яр җитә...

* * *

Сагынулар саргайтса,
күке саргаер иде —
ул кош гомере буе
балаларын эзлидер.

Сагыну сагышыннан
әгәр кеше саргайса,
Җирне тутырыр иде
тик зәгъфран йөзлеләр.

Сагынулар саргайтса,
мин ул саргаер идем —
бит хәлләрем тиңләрлек
язга гашыйк күз белән...

* * *

Кырыкны узгач,
мин яшьлеккә кабат кайттым —
тормыш нәрсә икәнлеген белгән ир булып.
Мәхәббәтнең мин барлык назларын татыдым,
йөрәгемдә —
хыянәтләрдән калган тозлы эзләр,
күз төбемә
шатлыклар да, хәсрәтләр дә сырын салды,
ләкин барысы да артта калды,
артта калды,
калды...
Менә мин кабат кайттым яшьлегемә.
Ялгышмыйча,
калдырмыйча утлы үкенечләр,
таныш юлны кабат үтәргә мөмкинлек бар.
Тукта!
Нәрсә алып кайтты соң әле яшьлегемә?
Мәхәббәт ич!
Күзге шашкын мәхәббәт!
Менә ул, илаһи ташкын булып,
бөтергәләп агызып бара мине язмыш буйлап.
Таныш бер генә нәрсә дә юк — барысы яңа:
яңача янам,
яңача туңам,
яңача сагынам,
яңача көнләшәм,
иске сүзләр белән яңача сөйләшәм,
яңача үпкәлим,
яңача үпкәләтәм һәм кичерәм...
Мин яшьлеккә кабат кайттым —
барысы да минем яңача,
ләкин үкенечләр,
үкенечләр генә элекке.

## *Сүз*

Сүзгә урманны, кырны тутырып була,
сыйдырып була зур шәһәрне,
бөтен бер илне,
тотып ябып була
Җир шарын иңләп әйләнгән олы җилне,
Ай, Кояшны,
йолдызлы күкне
тутырып куеп була чәчми-түкми...
Ә сөюне,
бөтен ихласлыгын,
кайнарлыгын иясенә җиткерерлек итеп,
сыйдырулар авыр икән лә сүзгә...
Ләкин моны эшләрлек көч тә
гомергә бер-ике генә тапкыр булса да
табыла бездә.

## *Чал сандугач*

Яфрагына сары төшкәч
чәчәк аткан гөл ич син!—
Сиңа кем сандугач булсын?
Ширбәтеңне кем эчсен?..
Мин!
Мин — давылдан, утлардан
канатын талаттырып,
назлардан, үкенечләрдән
йөрәген канаттырып,
сине күргәч,
китә торган
кошларга кушылмаучы
чал сандугач!
Миңа дигән
соңгы илһамчы тамчы
синдә икәнен күрүче
һәм көзләрдә калучы,
сары көзләрдә дә язгы
җырлар җырлый алучы!

## *Дигән идем*

Каләмемдә кара күптән кипкән,
сиңа диеп җыеп торган назлы сүзләр
яргаланып беткән дигән идем,
исән икән,
барысы исән икән.

Диңгез дулкыннары эзне безнең бозган,
яңгыр тамчылары бүгенге һәм үткән
арасына чаршау сузган дигән идем,
вакыт безгә кагылмыйча узган,
кагылмыйча узган!

Тау кояшы хисләребез төсен ялап алган,
дала җиле учларыбыз арасындагы
җылылыкны талап калган дигән идем,
барысы да йөрәк кайнарлыгында калган,
йөрәк кайнарлыгында калган.

* * *

Мин ярлыкыйм барлык гөнаһыңны —
миңа чаклы булган барысы...
Тик әйт: нигә синең күзләреңдә
була кайчак курку ярысы?

Зәңгәр көннәр, кара төнне ертып,
ни күрала синең күзләрдән?
Кем куллары тиеп кашларыңа,
карашыңның нурын үзгәрткән?

...Былбыл кунмый, әгәр оясында
сизсә исен ят кош эзенең...
Керфегең яп, тешлә зәңгәр көнне —
каный-каный синнән өзелим,

кояш булып батыйм сагышыма...
Синсез бераз яшәп карыйм соң...
Кабат калкып, янә ярлыкарга
булган гөнаһларың... барысын!

## *Көзге мәхәббәт*

Җәйдән дә җылырак көне
була икән ич көзнең!
Шундый көн алтын аланга
китерде безне.

Җылы якларга юл тоткан
кошлар канат кагынгач,
ботакларын канат итеп
тоя һәр агач.

Бөтерелә һаваларда
әллә кош, әллә яфрак.
Хушлашулар моңы тора
һавада яңрап.

Ә безнең китәсебез юк,
безгә биредә рәхәт —
моңаерга ирек бирми
көзге мәхәббәт.

* * *

Наз татыйсым шундый килде бүген!..
Ирешер өчен моңа ничек тә,
күзем йомып, кармаланып киттем
кар эчендә туган көчектәй.

Җылылыкның кайдалыгын сизәм,
тоям аның назлы яктысын,
тын юлымнан татлы хуш ис ага...
Эзләгәнем нигә тапмыйм соң?!

Әллә инде бик күп өмет итеп,
көтеп-көтеп арып беткәнгә,
саташтыммы, тәмам адаштыммы —
барып чыгам һаман үткәнгә —

карлы кырлар, сары яфраклардан
хасил келәм, җылы яңгырлар
арасына. Ул дөньяда кемдер
маяк итеп учак яндыра.

* * *

Түбәнсеткән,
горурлыкны сыткан
газаплар да йөрттем йөрәктә...
Шул газаплар минем күзләремне
күккә карамаска өйрәткән.

Керфекләрем, туфрак сөрә-сөрә,
бетә язган чакта ашалып,
йөрәгемнән теге газапларны
беравыкка алып ташладың
һәм тутырдың аңа яңа газап —
һәрчак сине күрү теләге...
Ә бу теләк күз нурымны минем
йолдызларга илтеп терәде:
утлы йолдызларга,
бозлыларга...
Яндым-көйдем, туңдым-өшедем...
Һәм мин хәзер
чын бәхетнең газап
икәнлеген белгән кешемен...

Котылырга телим мин аңардан —
риза, риза бөтен түләккә...
Ә ул миннән
сиңа багышланган
шигырьләтә генә түләтә.

* * *

Кояш бата зәңгәр тау артына...
Яшел алан моңга күмелә...
Сагынудан шашам бугай инде —
Син кайларда хәзер?
Кем белән?
Күзләреңнең төпсез карасына
кемнәр бата?
Алар чыгамы?..
Кулда каләм.
Телдә каргыш... Язмыйм...
Нигә әле шулай чыдам мин?!
Күңелемне кара шөбһә булып
талый, талый изге көнләшү.
Мин чынлап та үлеп гашыйк, ахры,
юктыр бугай җирдә тиңдәшем...
Мин шулай да
яңа Фәрһад түгел,
яңа Мәҗнүн, Йосыф түгелмен...
Каләм очындагы кара бит мин —
утлы шигырь булып түгелим...
Кояш батты зәңгәр тау артына...
Яшел алан моңга күмелде...
Күзаллагыз: сөеклесез калып,
төнгә әверелгән күңелне.

* * *

Миңа көн җитми...
Яңадан
кояш диңгезгә тия.
Дулкын кубарып, кояшны
яңадан күккә чөям —
яктыртсын тагын йөзеңне
һәм эресен күзеңдә.
Кояштан
тик синең аша
җылы алам сүземә,
илһам алам җырларыма,
куәт алам хисемә!
Очраштык та хушлашабыз...
Барысы да киселә...
Йөрәкнең утлы кырыен
тагын сагыш чылата...
Кояш бата...
Мин югалтам...
Дулкын гына юата...

* * *

Сәер, гаҗәп! Бик тә гаҗәп —
бер фасылы елның килми калды,
ел бер фасылга кими алды:
кыш булмады күңелемдә,
кыш булмады,
көзем язларга тоташты,
сиңа кинәт гашыйк булгач.

Сәер, гаҗәп! Бик тә гаҗәп —
тагын бер фасыл килми калды,
ел бер фасылга кими алды:
җәй булмады күңелемдә,
җәй булмады,
язым көзләргә тоташты,
сиңа бик соң гашыйк булгач...

* * *

Нәкъ үзедәй бер хис эзләп
хисем чапты,
нәкъ үзедәй тойгы эзләп
тойгым акты...
Очрагандыр, табылгандыр,
ничек күрим —
дулкынга дулкын бәрелсә,
чыкмый чаткы...

Миндәге хис — ул минеке...
Баета алмый...
Ике кайнар берсен берсе
суыта алмый.
Очратканмын, янганмындыр,
ничек белим —
ике шәраб берсен берсе
айныта алмый...

* * *

Берүзем күзәттем Айның
дулкынга чумган чагын...
Минем дә шул Ай шикелле
буласым килде тагын —
рәхәтләнеп чайкаласым
мәхәббәт дулкынында,
һушсыз калып югаласым
назларың упкынында.
Ниләр булса да әзер мин
егетләрчә чыдарга,
Ай булып чумып, таң аткач
Кояш булып чыгарга!

* * *

Мин кабат кадерле җылыда...
Көз сеңгән яфраклар келәме...
Ә гөлләр — чәчәктә... Нигәдер
язны да, җәйне дә теләмим —
мин кабат кадерле җылыда.

Мин кабат кадерле үткәндә...
Кулларым кулыңа кагылган...
Җылы төн шикелле күзеңдә
мин моңлы Ай булып чагылам.
Мин кабат кадерле үткәндә.

Мин кабат кадерле давылда...
Дөньяңда җил булып очамын.
Бер узган гомерләр кайтмый, дип
әйтсәләр, мин ничек ышаныйм?!
Мин кабат кадерле давылда.

Мин кабат кадерле җылыда...
Көз сеңгән яфраклар келәме...
Ә гөлләр — чәчәктә... Мин һич тә
яңа яз, яңа җәй теләмим.
Мин кабат кадерле җылыда...

## *Тәрәзәдә бәргәләнгән кар бөртеге*

Сизенүем минем хактыр —
тәрәзәдә бәргәләнгән кар бөртеге —
синнән килгән сәлам-хаттыр...

Пышылдадым тәрәз аша:
— Тәрәзәдә бәргәләнгән кар бөртеге,
хәзер чыгам, бераз яшә!..

Чыккан гына идем, шундук
тәрәзәдә бәргәләнгән кар бөртеге
кайнар иренемә кунды.

...Еремәде кышның гөле...
Тәрәзәдә бәргәләнгән кар бөртеге —
хатларымның ап-ак көле...

* * *

Утка ташлыйм юрау гөлләреңне —
һәр саргайган яфрак белән син
саргаясың, ә яшеле тугач
яшәрмисең инде, беләмсең?

Син яшәгән урам коеларын
бикләтәм мин — һәрбер буш чиләк
кысыр мәшәкатьләр юрамасын...
Юраганга һәрчак юш килә...

Кара мәчеләрнең барысын да
манып чыгам кардай акка мин —
юлым уңмас дигән кара шөбһә
күңел ишегеңә какмасын!

Юрау өчен сиңа ике нәрсә
үзгәрешсез калыр — онытма:
таң җиттеме — якты куанычка,
кич җиттеме — төнге тынлыкка.

* * *

Бүгенге көн елның, шәт, иң ак көнедер —
кояш нуры энинең ак кулы кебек.
Ак күктән дә төште энә кар бөртеге,
иреннәрне тетрәндереп алды үбеп.

Ә кырларда бүген һич тә көртләр түгел,
ак канәфер, ап-ак сирень, шомырт кына.
Беләсеңме, алларыңа кем җәйде? — дип,
ап-ак юллар җырлашалар шыпырт кына.

Ничек белмим? Беләм, беләм... Күзем йомып,
онытылып ап-ак дулкыннарны ярам.
Шундый рәхәт — әллә җәннәт ишегенә,
әллә синең кочагыңа кереп барам.

* * *

Син Кояшны хәтта аяз көндә
ят күзләрдән яшерә аласың.
Мондый көчкә ия буламыни,
әйтче, гади адәм баласы?

Ничә кеше сиңа үлеп гашыйк!!!
Барысының көне караңгы...
Миңа июнь чәчәк сузган чакта,
алар йөрәгендә кар яуды.

Көн кояшлы иде... Күрмәделәр.
Тоймадылар җылы барлыгын...
Без гаепсез идек — гаепмени
бер-береңә тугры яр булу?!

Син кояшны хәтта аяз көндә
ят күзләрдән яшерә аласың.
Моңа ия була ала бары
өзелеп сөйгән адәм баласы.

## *Фал итмә*

Китабымны, зинһар өчен,
беркайчан да фал итмә —
шигырьләремдә күңелем
давылдан соң ял итә.

Кузгата күрмә кошларын,
көч җыйсыннар сайрарга!
Нигә соң күпне белергә,
белми торыр җай барда...

Нигә кисәтәм дисеңме?
Белгәнгә һәр җөмләсен! —
шигырьләр дөресен әйтсә,
күңелең рәнҗемәсме?..

* * *

Якында булсаң да — еракта...
Еракта булсаң да — йөрәктә.
Йөрәктә булганга, ахры,
сузылсам да җитмим кирәктә.
Якында булсаң да — еракта...

Еракта булсаң да — йөрәктә,
һәрдаим ишетәм тавышың,
һәрдаим үзем дә ялварам...
Сак-Соклар без — булмый кавышып.
Еракта булсаң да — йөрәктә...

Йөрәктә буганга, ахры,
табалмыйм, табалмыйм, табалмыйм
яныңа илтүче сукмакны...
Бары тик исемең кабатлыйм...
Йөрәктә булганга, ахры...

## *Аерса*

Көн аерса, түзеп була,
төн аерса, бик читен —
иң түзем хатын-кыздан да
тешләтә мендәр читен;
салкын акыллы ирне дә
йолдызлар санаттыра —
исемле йолдызлар санын
тагын бергә арттыра.
Йөрәк тибеше чаң булып
тутыра авыр төнне;
дәрт утыннан күзьяшь яна —
буылдыра төтене.
Айны көтеп аласың да
сүз катасың... Эндәшми...
Таба алмый аптырыйсың
сөйләшерлек төндәшне.
Иң назлы сүзләр эчендә
ярала каргыш төше.
Җылы сүз әйтмәслек булып
җан туңа һәм тел өши.
Тугрылык антларының да,
йа Ходай, чите китек...
Көн аерса, түзеп була,
төн аерса, бик читен.

* * *

Агачларның
рәхәт көннәр өчен
алтын түләр вакытлары җитте...
Яфрак ява...
Мин беренче тапкыр
көзге агач булып газап чиктем...

Алладан да,
Иблистән дә качып,
яшәп калдык соң без күпме генә?!
Җирдә булган назны алуын алдык,
үрелсәк тә гәрчә күкнекенә.

Бары үтте...
Бары артта калды...
Алда тора чиксез авыр түләм...
Агачларга — алтын гына биреп,
менә безгә — сүнмәс сагыш белән.

## *Элегия*

Бүлмәмдә күк төтен.
Урамда сары көз.

Көз көне китмә син,
кышкача, зинһар, түз.

Мин имән түгел ич,
түгел ич мин каен —

кышыма керергә
яфрагым саргаеп.

Бу көзгә көз өстәп
өзелсәң күңелдән,

мин, шәрә агачтай,
ак карга күмеләм...

## *Мин сине һаман да яратам*

Мин сине көненә мең каргыйм:
яфраклар саргайган өчен дә,
кергәнгә дә ялгыз кичемә,
мин сине көненә мең каргыйм.

Мин сине барыбер кичерәм —
мең каргыш шунда ук юк була,
караңгы күкрәккә ут тула...
Мин сине барыбер кичерәм.

Мин сине һаман да яратам,
иң зәһәр газапка салсаң да,
ялварсам — җавапсыз калсаң да,
мин сине һаман да яратам!

* * *

Алтын көзне сиңа бүләк итәм —
төс байлыгын, алтын нурларын.
Мин бит сине төссез рәхәтлектән
матурайтыйм диеп урладым.

Алтын алан тулы абагалар
безне көткән монда күптәннән,
бәхет чәчәкләре аталмыйча,
аптырашып-йөдәп беткәннәр.

Алар әнә көндез чәчәк ата.
Кирәк түгел инде серле төн.
Чәчәкләрне астан эзләмәче, —
ул чәчәкләр, бәгърем, син дә мин.

Кискән имән төбе — сиңа тәхет.
Патшасы бул алтын көземнең,
мәгънәсе бул алтын язмышымның,
алтыны бул язган сүземнең.

* * *

Мин күтәрдем сине үзәннәрдән
кошлар оясына кадәрле...
Мин иңдердем сиңа йолдызларга
кадәр оча алу хәбәрен.

Кочагыма җәеп киңәйттем мин
бөгәрләнә язган канатны.
Менә талпындың да, кискен сугып,
йөрәгемне минем канаттың.

Тамчы-тамчы җылы акты аннан —
җәй киткән җир кебек суындым.
Туңып үлмәс өчен, хәтәр тулы
куеныңа кабат сыендым.

Без күптәннән йолдызларда идек.
Кочагыңда ачсам күземне,
мин яңадан кошлар оясында
гына итеп күрдем үземне.

Түбәндәрәк кырмыскалар чаба,
суалчаннар яши шуышып...
Сынган үлән, черек яфракларның
уфтанулы салкын сулышы.

Мин күтәрдем сине үзәннәрдән.
Күтәрелдем сиңа ябышып.
Сине мин югалтсам, ә син мине —
кем төзәтер безнең ялгышны?

* * *

Иң алдан:
күзләр дә коры,
әйткән сүзләр дә коры...
Башлана ләкин йөрәктә
сихерле көчләр җыры.

Биләп ала ул җиһанны,
кочаклап ала тәнне,
һәр күзәнәк тоя башлый
шул җырның ямен-тәмен.

Аннары —
һәрбер күзәнәк
әверелә җырчыга,
җырлый башлый...
Җыр урынына
иң мөкатдәс сер чыга.

Күзләр күзләргә чумалар...
Күзләрдә серләр җыры...
Килеп җитә бөек мизгел —
сүзсез сөйләшү чоры.

* * *

Эчләремдә җылы тормый.
Күз караларым туңа.
Бернинди аңлату тапмыйм,
бернинди сәбәп — шуңа.

Нәрсә тишеп үтте мине?
Нәрсә ярды бәгырьне? —
җылы дөнья гына түгел,
җылы сүз дә кадерле.

Анысын да мин күптәннән
ишеткәнем юк бугай...
Күңелемдә кояш батты
һәм калыкты салкын Ай.

Җылытучым!
Яктыртучым!
Юатучым, табибым!
Кеше булып яшәтергә
берәр чара тап инде!

Яма бәгырем ярыгын,
күз нурың белән типчеп...
Бу бәндә яшәсен дисәң,
яңадан шагыйрь итче!

* * *

Буем белән түгел —
уем белән,
йөзем белән түгел —
сүзем белән,
кашым белән түгел —
башым белән,
телем белән түгел —
түлем белән,
өем белән түгел —
көем белән,
гөлем белән түгел —
көлем белән
яулап алачакмын —
үзем беләм!..

* * *

*Лилия Харисовага*

Син юк өйгә кайтасым да килми минем.
Тәрәзәсе саран күзе төсле тонык.
Ишеге ят... Ачу — газап... Ачтың исә,
өскә ава таштай авыр салкын тынлык.

Мин күнеккән: ишек ачсам — синең күзләр.
Мәшәкатьләр тәмугында кайткач пешеп,
чумамын да күзләреңнең чоңгылына,
әкиятмени — мин яңадан сап-сау кеше!

Син юк өйдә яшисем дә килми минем —
җанга кирәк хуш исләр юк һавасында,
Сулыйм-сулыйм, ләкин авырая барам,
тамырларга кургаш болыт ага сыман.

Син юк өйдән... озатыласым да килми —
өй ишеген ябарлар да саксызланып,
шигырьләргә һәм җырларга күчкән җаным,
аһ, сызланыр, аһ, сызланыр, аһ, сызланыр...

## *Сөеп туймаган йөрәк*

Синең тулы бәхетең бар...
Балкысын кояш булып...
Ә мин якты язмышыңда
күз тулы моңлы болыт.

Кояшыңны томаласам,
җаныңны суык өтәр...
Ләкин беркем дә моңарга
сызланмас миннән битәр.

Нигә мине газаплыйсың?
Сиңа тагын ни кирәк?
Беләсең ич, бар байлыгым —
сөеп туймаган йөрәк...

* * *

Көне буе сагындым мин
йолдызлар кабынуны,
бәхеткә әйләнер, диеп,
шул чакта сагынуым.
Һәм йолдызлар кабындылар.
Сагынуым да яна,
сөюнең чиксез давылы
көч өстәп тора аңа.
Яна йөрәк,
яна уйлар —
җанымда көл һәм сөрем...
Синең утсыз тәрәзәңнән
күз ала алмый йөрим...

* * *

Яхшылыгыңа — яманлык...
Мин сине мәхрүм итәм
җаның күнгән тынычлыктан,
өеңдәге бәхеттән.

Мин татлы сер булып керәм
йөрәгеңнең түренә...
Син ятлардан күзең яшер —
күзеңнән мин күренәм.

Телең яшер... Мин сөйләгән
сүзләр тәртибен оныт —
үзең дә сизми калырсың,
чыгармын шигырь булып.

Булдыралсаң, язга чыкма,
яшә кышка камалып...
Бозбармаклардан Яз тама —
йөрәк өзгеч яңалык...

Учың куйсаң, кулың пешәр,
җаның көяр — куймасаң...
Яманлыгым яхшыгадыр,
бәлки, ныклап уйласаң...

## Җиргә төшермә

Төшермәче мине җиргә син...
Аяк очымны да тидертмә —
сөюемнең биек очышы
аһ, тилертә мине, тилертә.

Төшеп килгән аккош мамыгын
сулышыңа салып этәр син,
күзләреңнән аккан җылылык
йолдызларга мине күтәрсен.

Йолдыз нурларыннан сүз эрләп,
Җир белмәгән җырлар чигәрмен...
«Бар, оч!» — дидең... Ачтың кочагың...
Ә кулларым синнән җибәрми.

Очырмачы мине күккә син...
Ирек биреп, мине тилмертмә...
Җырның җиргә тамыр җәюе
нирванәгә салып тилертә!

* * *

Төренеп тә җылынып булмый,
никтер үзәгем өши...
Тизрәк кайт инде яныма,
минем кадерле кешем.

Тизрәк кил дә керфегемә
керфегең белән кагыл,
күземнең авыр нурларын,
зинһар, төшерче кагып.

Эресеннәр бозлылары
назыңда җепши-җепши...
Тизрәк кил, үзәгемә кер,
минем кояшлы кешем!

## *Суга баткан ут*

Пышылдап әйткән сүзләрең
уйларны адаштырды...
Ят дөньяга барып чыктым...
Ә күрдем таныш кырны.

Зәңгәр кар...
Таныш йолдызлар...
Син дә мин...
Яна учак...
Утка этәсең... Мин сине
«Бергә керик!» дип кочам.

Безгә җылы...
Безгә рәхәт...
Өметләребез якты...
Зәңгәр кар ереп су булды,
учак шул суга батты...

Кара күккә күтәрелде
уттан калган яктылык,
очып китте бүгенгемә
иң сагышлы хат булып...

Пышылдап әйткән сүзләрең
китерде шушы хатны...
Укырга дип алган идем —
йөрәгемә ут капты.

* * *

Эрерләр карлар, эрерләр
кырларга ятканнары,
умырзаялар шытасы
аланны япканнары,
урманның шаулы башына
уй булып кунганнары,
язны көтеп, ерымнарга
шым гына тулганнары...
Җылылык тантана итәр,
җирдән аерып тезен...
Һәм ачылыр умырзая —
язның зәп-зәңгәр күзе!
Дымлы күзләре белән яз
күрер, аңлар барын да:
яшәү бит ул — суыклыкның
җылына баруында.
Эрерләр карлар, эрерләр
хәтта безнең арада...
Тик шытармы умырзая
кардан калган ярада?

* * *

Аруның да була төрлесе:
була сафы, була керлесе,
аркада тоз булып катканы,
шәүлә кебек җиргә ятканы,
сынган сука кебек тынганы,
хәлсез дулкын булып туңганы,
керфекләргә герләр элгәне,
каргыш булып канга сеңгәне,
кискән имән кебек ауганы,
сулыштан дым савып алганы...
Аруларның була төрлесе...

Аруларның була төрлесе...
Арада бар берсе — серлесе:
изге гөнаһлысы, яктысы,
гүя сүнгән назның чаткысы,
талган елмаюда калганы,
бәхет булып йөздә янганы,
йөрәккә аһ булып кергәне,
җырга тәмле сүзләр биргәне,
әйләнгәне олы табышка —
«Кабатлансын!..» дигән сагышка...
Аруның да була төрлесе...

## *Поездлар үтә тора*

Поездлар үтә торалар...
Кемнәрдер китә тора.
Берәүләр елый... Берәүләр
чак посып читтә тора,
кулларын изәргә куркып,
тик керфек кенә изәп...
Йа Ходай! Бу вокзалларда
ничаклы гүзәл бизәк!

Поездлар үтә торалар...
Кемнәрдер китә тора.
Берәү каршылый... Кочаклаш...
Ә берәү китә тора.
Һәр вагонның тәрәзәсе
сөйләп калдыра кыйсса.
Поезд китә... Кыйсса, калып,
йөрәкне тотып кыса...

Поездлар үтә торалар...
Кемнәрдер китә тора.
Корыч рельслар тавышы
көчәя-бетә тора.
Мин китмим, көтмим, озатмыйм,
шаккатып читтә торам,
һәр поездны шигыремнең
бер юлы итә торам...

## Гүзәл ялгызлык

Кышкы урман уртасында
тылсымлы ак ялгызлык...
Бирегә әле беркем дә
кермәгән миннән узып.
Бирелә мин өмет иткән,
күптәннән көткән тынлык.
Бирелә мин күзем йомып
эчке дөньямны тыңлыйм.
Бирелә мин иң яшерен
хыялларга юл бирәм —
синең бикле йозагыңа
ачкычы булып керәм...
Бирелә мин телсез-сүзсез
наратлардай акыллы,
бер-берсенә ак кар сузган
ботаклар күк ак куллы.
Бирелә мин бернидән дә
тартынмыймын, оялмыйм...
Бирелә — кеше төсенә
кергән синең хыял мин!

* * *

Бик кирәксәң, сине ничек табыйм эзләп?
Кирәк булу очраклары булыр йөзләп.
Мин галим дә, бухгалтер да түгел кана,
шуның өчен барысын да тормыйм санап —
синең алда һич тә килми хур буласым,
бары әйтәм... әйтәм шигъри формуласын
сәбәпләрнең... Ул формула шактый-шактый
катлаулыдыр, чөнки аның җаен тапмый
газаплана җиргә килгән һәрбер кеше,
ләкин таба ахыр чиктә... Таба ишен...
Ул формула сыя бары алты сүзгә:
бик күрәсем килә сине сәбәпсез дә...

## *Татлы серләр карагы*

...Карак, имеш, — урлаган ич
Су анасы тарагын!..
Менә мин, ичмаса, угры —
татлы серләр карагы.

Күпмегезнең серен урлап,
хисем белән тарадым,
җеп эрләдем, шул җепләрдән
шигырь үреп карадым.

Ярыйсы килеп чыктылар,
һәм китапларым аша
аларны сезгә тапшырдым,
ханымнар һәм туташлар.

Серегезне таныйсыз да
«сер бирмисез» юри сез —
серегезне ят сер итеп
шигырь сөйләп йөрисез.

* * *

Кагылмасам — хәлем бетә,
кагылсам — суга яшен...
Җир белән Күк арасында:
тәмам әлсерәп яшим.

Кеше кыяфәтендәге
җебегән бер болытмын.
Тамчы-тамчы гомер кими —
шуны никтер онытмыйм,

сузыламын бөек назга,
һәм, ирешәм дигәндә,
йөрәгемә яшен суга...
Хискә акыл тигәнгә...

## *Шул чагында*

Хисләр туздЫ...
Сүзләр бетте инде...
Давылларда озак яшәлде...
Күңелемнең талгын бәйрәменә
беркемне дә хәзер дәшәлмим.

Ә шулай да арган күзләремдә
сабый чактан калган яшь аша
мин дөньяга багам...
Күз нурларым
үтенечле нурга тоташа.

Шул чагында күңел төпкелендә
хис давылы куба...
Котыра...
Яңа туган баллы яфрак кебек,
сүзләр белән
телне тутыра...

* * *

Минем хәлем хәзер шундый:
бата калсаң — бары салам!..
Синең тапкан бәхетеңне
югалтыша гына алам...

Белә торып тотынасың...
Абау, мин бер каек икән!
Алып китәм дә диңгезгә,
дулкыннарга патша итәм.

Чөеликче күкләргә бер!
Убылыйкчы упкыннарга!
Якын гына килә күрмик
бәхетең саклanган ярга.

Каек бәрелер кыяга...
Син айнырсың аман гына...
Кочагыңда калган булыр
теткәләнгән салам гына...

* * *

Бу кадәр бай чагын йөзеңнең,
бу кадәр җай чагын сүзеңнең,
бу кадәр май чагын күзеңнең
беркайчан булмады күргәнем.

Йөзеңдә мең тойгы эзе бар,
сүзеңдә һәр хиснең төсе бар,
күзеңдә тылсымлы көзге бар —
мондыйны беркайчан күрмәдем.

Син нәрсә уйладың шул чакта,
кысылдың син нинди кочакта
һәм яндың син нинди учакта? —
сорыйсым килсә дә тын тордым.

...Актардың син минем үткәнне —
кайчандыр илһамлы иткәнне,
ни өчендер сине өткәнне...
Арбалдым... Сокландым... Тын тордым...

## *Көнләшүләр*

Күзләремә чумасың да
күңелемне буйлыйсың —
йөрәгемнең иң түрендә
көндәш бар дип уйлыйсың.

Әллә ниләр сорашасың,
төпченәсең, туймыйсың —
юлларымда синнән башка
ярым бар дип уйлыйсың.

Син үзең бит иң авырткан
кылларында уйныйсың —
язмышыңны башка берәү
бозар диеп уйлыйсың.

Көнләшүсез булмый сөю,
көнләшмәүчеләр сирәк.
Чамасын белми көнләшсәң,
ут була икән йөрәк.

Тәмле көнләшү йөрәккә
матур эз салып уза.
Бер чын көнләшү хакына
мин мең газапка риза...

## *Кисәтү*

Җанымның, сиңа тартылып,
артык нечкәргән чагы...
Акланырга мәҗбүр итеп,
кимсетә күрмә тагы!

Күз нурларым сөйләгәнне,
зинһар, телдән әйттермә —
акланып ачкан авыздан
җаныма ялкын керсә,

нечкәргән җаным кызышыр,
кайнарланыр да эрер...
Язмышың буйлап, өрәктәй,
утлы үкенеч йөрер...

## *Мәхәббәт ярасы*

Язларым ялгыз үттеләр,
җәйләрем узып бара.
Бигрәк татлы сызлый икән
мәхәббәт салган яра.

Мин бит гел сине уйлыйм,
якынлашырга кыймыйм.
Күзләребез очрашса да,
эчемә шатлык сыймый.

Җәйләр юаныч бирмәде,
гөлләрне сары сара...
Һаман тирәнәя генә
мәхәббәт салган яра.

Мин бит гел сине уйлыйм,
якынлашырга кыймыйм.
Күзләребез очрашса да,
эчемә шатлык сыймый.

Кышыма ялгыз керимме —
син шуны уйлап кара.
Әҗәлдән дә яман икән
мәхәббәт салган яра.

## *Мин ул көнне...*

Беркемгә дә сине бирмәмен мин...
Ташлап китсәң, нишлим, китәрсең...
Күзем йомык булыр... Күзем ачып
башлармын мин бушлык иртәсен...

Йөзләремә ул көн кояш чыкмас,
эңгер-меңгер генә яктырыр,
болытларның дымлы ялтыравын
күзләремә кертеп яптырыр.

Чигәләрдә ул көн күбрәк булыр
нурсызлыктан иңгән ак кырау.
Күңелемнең сайрар кошлары да
оясында ятар аптырап.

Җылы тавыш, тәмле сүзләр белән
беркемгә дә ул көн эндәшмәм...
Мин ул көнне бары сокланырмын
сине миннән алган көндәшкә.

Мин ул көнне ләкин ямьсез булмам —
сине сөю биргән горурлык
шундый бизәр мине... Киткәндә син
карый күрмә ялгыш борылып —

киталмассың... Ләкин яңабаштан
үз булмассың инде, онытма!..
Менә нинди шыксыз уйлар килде
сине артык сөйгән минутта...

* * *

Күңелемдә ямьле бәйрәм бара иде,
яңгырый иде табынымда матур сүзләр.
Йөрәгемнең ишекләрен шакыдылар —
нәрсә эзләп, нәрсә эзләп, нәрсә эзләп?

Мин онытакан идем инде барлык гамьне,
тугарылган идем сөю дөньясында,
йөрәгемнең ишекләрен шакыдылар —
бур эзләүче милиционерлар сыман.

Гөмбәземдә миллион йолдыз яна иде,
тик бер йолдыз балкый иде җылы бирeп.
Йөрәгемнең ишекләрен шакыдылар —
шуны күреп, шуны күреп, шуны күреп.

Йөрәгемнең ишекләрен шакыдылар —
каердылар аның талган тупсаларын
һәм исемә төшерделәр гөмбәземдә
башка кеше исмен йөрткән йолдыз барын...

* * *

Туктатырга җилле бу яңгырны!..
Йөрәгемә хәтле чыландым,
күз нурыма хәтле суык үтте,
иң зур хисем хәзер чуанлы...

Сөю хисе җанлы тәндә генә
яши диеп йөрдем алданып —
сызланам ич бөтен галәм тулып,
әйтерсең лә чирле алла мин.

Йолдыз йолдыз түгел — теш сызлавы,
кояш кояш түгел — кызышу...
Иң зур хисем бүген чирле минем,
хәтәр бүген миңа сүз кушу...

Ә җил исә, яңгыр һаман ява,
якты карлар белән ялганып...
Хисем чирле, ләкин үзем исән,
үлә алмый торган алла мин...

* * *

Күзләреңә синең бүген
туры карыйсым килми,
чөнки үземнең күзләрдә
бүген елмаю көлми...
Чөнки үземнең күзләрдә
бүген сагыш томаны,
чөнки үзем бу иртәнең
аңламыйм ник туганын,
чөнки ул мине беркая
өндәми һәм этәрми,
әле миндә йокысыз төн
дәвам итә, битәрли
сиңа давыл керткән өчен,
утлы, бозлы зилзилә...
Бүген синең йөрәгеңдә
янып үләсем килә...
Күзләреңә синең бүген
туры карыйсым килми,
үземә үзем алдашып,
сиңа ярыйсым килми...

* * *

Еллар үтә... Еллар үтә икән, бәгърем.
Үткән саен арта бара гомер кадере.
Арка куеп аттан чанага искән җилгә
артка карап алга җилдерәсе килә.
Үткән юлда сагынычлы көннәр күпкә
түгел — инде алар күптән киткән-беткән.
Алдагыларын ерактан ук күрәсем
килми минем... йөрәгемә ял бирәсем
килгән өчен шулай телим — аңлыйсыңдыр.
Син дә шулай үз-үзеңне алдыйсыңдыр.

* * *

Сагынганда кемдер җырлый, кемдер елый...
Икесе дә, ни гаҗәеп! бер газаптан.
Һәм җыр тына... Һәм яшь кибә... Һәм кешегә
мәгънәсез бер халәт иңә иң азактан...

Шундый чакта мин исүдән туктаган җил,
онытылып оеп киткән дулкын кебек —
хәлсез, эшсез, ямьсез, тәмсез буш сыеклык,
ә өстемдә тиле күзе төсле күбек...

## *Өченче фәрештә*

Ике иңдә көн дә, төн дә,
бәя биреп һәр эшкә,
бар нәрсәне язып бара
ике гадел фәрештә.
Ләкин өченче фәрештә
яши минем йөрәктә.
Мине ул шашып сөяргә,
сөелергә өйрәтә.

Ятларны сөю гөнаһмы,
яшерене савапмы,
тугрылык анты дөресме? —
беркем белми җавапны.
Ләкин өченче фәрештә
мине һаман аздыра —
мәхәббәт шәрабы биреп,
акылымнан яздыра.

Фәрештәләр язып бара
өннәремне, төшләрне.
Кайсы теркәп барды икән
минем сөю эшләрен?
Ләкин өченче фәрештә
әйтә карап күземә:
мәхәббәтне һәр фәрештә
язып куя үзенә...

## Адашудыр

Нигә син күз яшерәсең,
күрмәмешкә салышып?
Керфекләрең тоялар ич
күз нурым кагылышын.

Иреннәрең ник тыясың —
елмайсыннар йөгәнсез,
тоткарлама — иренеңдә
бар ич миңа дигән сүз.

Адымнарың да тышаулы,
тигездә абынасың;
адашудан куркасыңдыр —
маяктай кабынасың.

Бәлки, дөрес эшлисеңдер...
Уйда ни — алда шулдыр...
Бәлки, адашмыйча яшәү
үзе бер адашудыр...

Иреннәрең ник тыясың —
елмайсыннар йөгәнсез,
тоткарлама — менә тамар
«...ләкин куркам!» дигән сүз.

## *Языклы мин*

Җанымны тоттырдым ураза —
онытып тордым мин беразга

йөрәктә мәхәббәт барлыгын!
Һәм бетте дөньяның тарлыгы,

күз нурым арынды рәшәдән...
Моңарчы, ипидер, яшәлгән

зинданда!.. Шахталар төбендә!..
Ут йотып агулы төтендә,

бернәрсә күрмичә, белмичә,
очраклы рәвештә үлмичә!..

Әйтерсең мин фәкать төш күрдем!
Ул үзен исемә төшерде.

Һәм өзде ураза агымын...
Йөрәктә куерды сагыну,

әйләнде ул авыр җимешкә,
тулышып һәм пешеп җитешкә

ул сеңә башлады тәнемә!
Һәм тойдым — ул җимеш тәменә

торырлык җиһанда җимеш юк!
Дәртле бал, назлы сөт, утлы сут,

Җирдәге барлык гөл хуш исе,
кешенең ләззәттә яшисе

килүе тудырган бөек тәм
аңарга тупланган, береккән.

Мин теләп каптым шул азыкны...
Бәхетле мин, чөнки — языклы.

* * *

Кеше арасына поса-поса,
кулны түгел, керфек кенә изәп,
калган чакның кыска минутлары
йөрәгемдә гомер булып үсә...

Ул гомердә күпме вакыйгалар:
ачу, көнләү, елау, аһлар, зарлар
күңелемнең ак, пакь китабына
үкенечләр булып язылалар —

һәрбер хәреф — кызган келәймәдәй...
Нигә әле миңа мондый язмыш?!
Бу дөньяда әллә яшермичә
сөеп була торган кеше азмы?!

Син китәсең, мин каламын ялгыз...
Кем дә белми шулчак, әй, хәлемне —
халык уртасында басып торам,
«Яшерен сөю» дигән һәйкәлмени!..

## *Сәрләүхәсез*

*Лилиягә*

I

«Мин сине сөйгәндә,
син кемне яраттың?..»
Бу сорау өстенә
ничәмә кар ятты,
ничәмә эреде,
әйләнде ул парга...
Без һаман элекке —
һаман да без ярлар.

II

Безнең өй, мин беләм,
һич җәннәт түгелдер —
бөрешкән мендәргә
күпме яшь түгелде,
кандагы кайнарлык
назларны киптерде.
Нишлисең? Тормыш бу!
Син — тере. Мин — тере...

III

Үпкәләр, үпкәләр!
Кемнәрне өтмәгән!
Чүмечләп эчтек без,
чамалыйм — бетмәгән,
бетәчәк тә түгел,
бетмәсен, үтмәсен —
җансызлар гына тик
булалар үпкәсез.

IV

Син хаклы. Мин хаклы.
Икебез дә хаксыз.
Була ул еш кына:
Җөп уйлар, ә так сүз.
Шуңадыр, мөгаен,
җаннарны аралап,
ярыкка чөй сугып,
шик-шөбһә ярала.

V

Йөрәкләр авырта...
Сәбәпләр төрледер.
Кайчакта гади сүз
куркыныч серледер.
Кайчакта гайбәтнең
агулы энәсе
хисләргә яман чир
чигәдер, күрәсең...

VI

Кешедә иң бөек
хис нәрсә дигәндә,
«Көнләшү!» дип әйтә
курыкмый бу бәндә.
Мин аны татыймын...
Син аны татыйсың...
Күнеккән чәчәкнең
тату ул ят исен...

VII

Ә бәхет дигәнең
һәркемдә үзенчә.
«Ә безнең — безнеңчә!»
дип әйттем мин ничә.

«Ә безнең — безнеңчә»
нәрсә ул дисеңме?
Ул — синең җисемең
һәм минем исемем...

VIII

Артта юл озынрак...
Алда юл — кыскарак.
Җан, шуны күрептер,
яшәүдә остара.
Ә яшәү ул — сөю!
Мәңгелек формула!
Һәм моны оныткан
соң чиктә хур була.

IX

Син мине сөйгәндә,
мин кемне яраттым?
Мин җанны бүлгәләп
галәмгә тараттым.
Иң матур кисәген
кем алган? Бу сорау
канымны кайната,
җелекне суыра...

## Үпкәләмәсәнә

Гомер ага, ага!..
Кайчак юлдан сабам,
кайчак сукмак табам.
Гомер ага, ага...
  Үпкәләмәсәнә, үпкәләмәсәнә —
  өзелгән сәдәп тә
  әйләнә сәбәпкә.
  Үпкәләмәсәнә, үпкәләмәсәнә!

Утлар сүнә, яна!..
Бу фани дөньяда
һәр мизгел өр-яңа.
Утлар сүнә, яна...
  Үпкәләмәсәнә, үпкәләмәсәнә —
  ярылган кашык та
  хисләрне ташыта.
  Үпкәләмәсәнә, үпкәләмәсәнә.

Көннәр килә, китә,
йә бәхетле итә,
йә бәхетсез итә.
Көннәр килә, китә...
  Үпкәләмәсәнә, үпкәләмәсәнә —
  сүтелгән бер җөй дә
  чыгарадыр көйдән.
  Үпкәләмәсәнә, үпкәләмәсәнә...

## *Сагыну*

1

«Инде сагындым» белән «Сагындым инде»
арасында аерманы сизәсеңдер...
Арабызда әле безнең берничә көн —
әнә кояш, сүндер, кабыз, янә сүндер...
Булдыралсаң... якынайт кавышуларның
озаерга гына хирыс минутларын...
Ләкин кояш һаман балкый... Ул яктырта
сине миннән аеры тоткан юллар карын.

2

«Инде сагындым» белән «Сагындым инде»
арасында аерма бар... Күп тә түгел.
«Күп тә түгел»нең эчендә, читлектә кук,
бәргәләнә никтер бүген минем күңел...
Кавышкач та, муеныма асылынып,
нинди сүзләр әйтеп миңа сыенырсың?
Синең сүзләр күзләремнән нинди нурлар
койса, бәгърем, шул нурларда коенырсың.

3

«Инде сагындым» белән «Сагындым инде» —
түземсезлек булыр берсе, берсе — түзем.
Кайсы моның яхшырак та, кайсы яман?
Кем билгели алыр икән хәзер үзеп...
Арабызда әле безнең берничә көн
озыная, әйтерсең лә җылы сагыз...
Булдыралсаң, кавышуларны якынайт —
әнә кояш, сүндер, кабыз, сүндер, кабыз...

## Табыла

Буран бураганда юлга чыгам —
йөрәгемдә давыл улый ла...
Күңелемә дару итеп тоткан
хәзинәмне табып урлыйлар,

тәмен татып аның исерәләр,
хуш исеннән аның айныйлар,
ап-ак кырлар уртасына кереп,
тиленәр күк ятып ауныйлар-
дыр, мөгаен, диеп шаша йөрәк —
чак-чак чыдыйм мондый кагуга.
Әверелә инде, әверелә
ул даруым чып-чын агуга!..

Буран бураганда юлга чыгам...
Адашасым килә давылда...
Дөнья кырыс — ачы дөреслеккә
илтәчәк юл һәрчак табыла...

* * *

Гаҗәпкә калып торасың,
җиталмыйсың төшенеп —
язмышымны тоттырырлык
ние бар бу кешенең?!

Йөрәгемә шырпы сыза,
җанымда су кайната,
каннарыма таш тоз сала,
әйләнеп кайта-кайта.

Сүзе белән телеп ала,
күзе белән бораулый...
Елына бер елмайса да
эрим, каршы торалмыйм...

Ничек аны Җир күтәрә,
ничек өреп төшерми?!
Синең, әйе, күргәнең юк
миндәй авыр кешене...

Ә шулай да бардыр миндә
бер яшерен матурлык,
Җир дә, син дә, кешеләр дә
тартылырлык, татырлык...

* * *

Бер исеңә төшерерсең әле мине...
Чал чәчеңнең бер бөртеге кубып җилдә
үз күзеңә кереп чәнчер, яшь чыгартыр...
Мин булырмын ул чакта бер ерак илдә

йә дөньяда... Кояш нуры үтми торган...
Һәм күрмәмен күзләреңә чәч кергәнен...
Шул чагында үз төшенә чишелеп китәр
хатирәләреңнең тыгыз бер төргәге...

Чал чәчләрең тузгыгандай тузгып китәр
безнең ачы-төче-татлы вакыйгалар...
Күзләреңә түгел инде, йөрәгеңә
кадар алар, кадар алар, кадар алар.

Сызланырсың үкенечтән... Чарасызлык
үкенечне тапкырлатыр йөзгә, меңгә...
Бер исеңә төшерерсең әле мине
бүгенгедән мильон тапкыр авыр көндә...

* * *

Бәхетлерәк була алмас идем...
Минем җырым, ахры, тумыштан
бармак күрсәткәч тә ихахайлап
көлгән такмак белән сугышкан.

Мин көлгәндә матур була алмыйм,
уйланганда гына ярыйсы.
Минем җаным күке тавышында,
былбыл булып килми сайрыйсым.

Җан агачым мәгъруур имән түгел,
елак тал да, ахры, тар аңа.
Минем агач — бернинди балта да
яра алмый торган карама!

Минем суым — океан, диңгез түгел...
Минем суым — шуңа сөямдер —
Идел ягасында аңа каршы
ага алган гади Зөядер!

Йолдызым да Казык йолдыз түгел —
артык якты, артык үзәктә.
Балкышы да тыйнак — миннән башка
беркем алмас аны бизәккә.

Бәхетсезрәк, бәлки, булыр идем,
очрамаган булсаң әгәр син...
Картлыгымның үкенечсезлеген
искәртүче керсез хәбәр син.

* * *

Синсез чагым хәтеремә килә...
Газапланып искә төшерәм:
булды микән ул вакытта юллар,
ай-йолдызлар, күзләр, кешеләр?

Булды микән телдә җанлы сүзләр?
Әллә чукрак-телсез килеш мин
өнсез яшәдемме юлсыз-нисез
сине, сине эзләп килешли?

Булды микән күзнең карасында
бу кадәрле төпсез комсызлык —
көне-төне хәзер нурың эчәм,
туя алмый күңел... Ул сызлый...

Булды микән йөрәк үзәгендә
бу кадәрле олы матурлык?!
Табылдың да, сүземне җыр иттең,
язмышымны чәчәк аттырдың...

* * *

Сөю — газап...
Сагынулар
ашкынуны ук итә,
хәтта үлем янаганда,
калканыңны юк итә.

Ашкынудан шашынасың,
очасың күзең тонып...
Җитәсең... Йөрәк — яралы,
канатта — каурый сынык...

Ә сөелү —
татлы ләззәт —
җылыта кояш булып,
тирбәтә тынлык эчендә,
әйтерсең баллы болыт.

Чайкаласың... Исерәсең,
айныйсың рәхәтлектә,
аермыйсың — әллә Җирдә
яшисең, әллә Күктә...

Син генә, бары син генә,
бер этәреп, бер кочып,
сөю белән сөелүне
миндә тоташтыручы!

* * *

Яз тәрәздән керә алмый,
керә алмый ишектән дә,
каен каерысы астында
җырлаганын ишетсәм дә.

Тәрәзәмә ботак очы
каләм булып нидер яза.
Әй тырышам — укый алмыйм...
Әллә нинди сәер газап!

Пыяласын бармак белән
капшап карыйм язу эзләп...
Таба алмыйм— әллә язу,
әллә инде үзем үзгә?!

Күзне йомам... Җанны тыңлыйм.
Каным җырлый тамырларда.
Мин соң ничек тоташ икән
эреп яткан язгы карга?

* * *

Минем
синең белән күптән
төнгә керәсем килә.
Минем караңгылык белән
безне
төрәсем килә.

Аяк бармагы очында
өзелсен барлык юллар,
эресеннәр — тоташсыннар
керфекләр, чәчләр, куллар.

Аңдагы барлык сакчылар
тән эчендә адашсын.
Сүзләр чыгарга курыксын,
тыннар гына аңлашсын,

хисләр генә йөрәкләрнең
тибешен шаулы итсен...
Мине
инде ничә гасыр
көндә тотасың бит син...

## Адашасым килә

Буран бураганда юлга чыгам,
йөрәгемдә буран булганга,
хисләремдә күкләр суыклыгы,
җирләр җылылыгы болгана.

Адашасым килә минем никтер,
саташасым, юлдан сабасым,
йолдызларга барып бәреләсем,
янартауга төшеп янасым,

күк гөмбәзен тишеп, баш тыгасым,
ташлар ярыгына керәсем —
бу дөньядан тәмам югаласым...
Тегесен дә килми күрәсем.

«Ялгышканмын, ялгышканмын», — дидең,
карамыйча гына күземә,
һәм бастырдың мине өермәнең
шайтан уйган утлы эзенә...

Адашасым килә бураннарда
кар бөртеге белән беррәттән...
Табыласым килә яңабаштан,
исән килеш,
синең йөрәктә.

* * *

Вәсвәсәләр бик күп булды...
Мин үземне сакладым.
Иблис шөһрәт тәкъдим итте.
Юк! Җанымны сатмадым.

Гүзәллек миңа сарылды.
Ул моңы! Ул буявы!..
Күзләрем алгысалар да,
мин кире кактым ауны.

Алтынлаган машинада
байлык та җитте килеп,
алтынга каршы торалмас,
сатылыр диеп белеп...

Килде Вакыт... Гомереңне
озайтам дип тотынды.
Сатылмадым! Чәчләремнең
төсен биреп котылдым.

Фәрештәләр җәннәткә юл
күрсәтмәкчеләр сызып,
аларча гына яшәсәм,
йөрмәсәм азып-тузып...

Вәсвәсәләр иксез-чиксез...
Җаным һаман яу кыры.
Мин саклandым — мин көрәштем,
җиңүче була тордым,

җиңүче булып яшәдем,
яшәп тирләдем, пештем...
Мәхәббәт кагылган иде —
шатланып әсир төштем.

* * *

Син миңа үпкәләп калма...
Алай итмә... Кирәкми...
Сандугачлар ташлап китә
йөрәктәге тирәкне.

Куна каргалар өере
тирәгем толымына...
Моңа түзә ала бары
мәхәббәт колы гына.

Ә түзү ул яшәү түгел,
ул — сызлауга әйләнү,
ул — җанның мәйданнарында
шик-шөбһәләр бәйрәме.

Ә бәйрәмнәр аздыручан...
Котырынса кол җаны,
болгатыр җирең-күгеңне,
эчке, тышкы дөньяңны,

һәм әйләнер мәхәббәтнең
хуҗасына, шаһына...
Мондый бәла сала күрмә
йөрәгемә, башыма.

Сандугачларны өркетмә —
ятим итмә тирәкне...
Син миңа үпкәләп калма...
Алай итмә... Кирәкми...

## *Бәсле түгел җаным*

Салкын карга карап күзләр туңды.
Керфекләрем сынып төшмәсме?
Сүрән кояш болыт артларында.
Болытларның түше гел бәсле.
Күләгәдә, көлсу карда торам,
тездән батып,
сулап сорылык.
Бусы—тыштан...
Ә эчкәре якта,
кайнар йөрәгемә орынып,
бу сорылык кайнап кибә, бетә.
Күңел күгем һәрчак кояшлы.
Кояш нурларында, җылылыкта
уй-хисемнең якты юл башы.
Елмаюым сирәк балкыса да,
еш батсам да моңга-сагышка,
җаны
бәсле
кешедер бу, диеп,
уйлый күрмә, зинһар, ялгышма!
Сүрән кояш посып яткан мәлдә
болыт түше шулай гел бәсле.
Мин күтәреп торам һәм җылытам
авыр болыт тулы гөмбәзне.

* * *

Күңел ишекләрем тоткасыз.
Ләкин биксез.
Хәтта келәсез.
Һәр кешегә анда—ачык йөз —
хуш киләсез... керә белсәгез.

Ачылмыйлар төртеп,
тартып та,
тәмле сүзләргә дә алданып...
Ләкин анда кеше шундый күп!
Ничек кергәннәрдер — аңламыйм.

# *Гомер турында җиде элегия*

## I элегия

I

Ай калка.
Йолдызлар
сүнәләр
тын гына...

II

Киек Каз
Юлыннан
агыла
моң гына...

III

Өметле
күзләрдә
йолдызлы
дым гына...

## II элегия

I

Караңгы
гөмбәздә
яктыра
ап-ак эз...

II

Ак эздән,
тилмереп,
без нәрсә
эзлибез?..

III

Сүнәләр
йолдызлар...
Бернәрсә
сизмибез...

**III элегия**

I

Һәр кеше
җанында
бәхетле
уй ята...

II

Һәр йолдыз
күңелдә
өметләр
уята...

III

Ай бата...
Алланып
таң ата,
таң ата...

## IV элегия

I

Галәмдә
кемнәрдер
сөйләшә
үзара:

II

«Киек Каз
Юлында
каурыйлар
кызара...

III

Гомерләр
узалар...
Чигәләр
бузара...»

## V элегия

I

Боз кебек
көмеш нур
йолдыздан,
Айдандыр...

II

Алтын нур —
Кояштан,
шуңа да
кайнардыр...

III

Чәчләргә
кунган кар
кайдандыр,
кайдандыр?..

**VI элегия**

I

Таш яна
һавада —
йолдыздан
төшкән таш...

II

Нур кала
сызылып —
галәмгә
ул тоташ...

III

Күз нурым
ни эзли?
Ул нурга
кем юлдаш?!

**VII элегия**

I

Фәрештә
юк дию
галәми
ялгандыр...

II

Фәрештә
йолдызга
кунган да
калгандыр.

III

Фәрештә
йөрәккә
һич кунмас —
янадыр...

* * *

Бер нәрсә дә соңгы тапкыр булмый...
Бөтен нәрсә бары чиратта...
Инде бетте, инде булмас, диеп,
этеп куйма мине еракка.

Бер нәрсә дә тәүге тапкыр булмый,
Һәрбер яңа — бары кабатлау.
Очраттыңмы мине — тагын бер сүз
җырга кайтты, диеп канатлан...

* * *

Мин йолдызга, юк, юк, әверелмәм...
Инде беләм: җаным балкышы
үз язмышым аша үткән чакта,
заманага карап ялгышты.

Мин бер тамчы... Зөя дулкыныннан!
Беркемнән дә инде яшермим —
Зөя суын яшен суккан чакта
йоткан идем әкрен яшен мин.

* * *

Күз онытa кайбер йөзне,
колак — кайбер тавышны.
Ләкин син һаман да матур,
тик чак кына сагышлы.

Чәч оныта туган төсен,
ә битләр — шомалыкны.
Моңа беркем дә шаккатмый —
син һаман чибәр, ныклы.

Тел оныта назлы сүзне,
ә кочаклар — җылысын.
Моны бик тә азлар сизә —
тыштан олпат, олысың.

Акыллы сүзләр сөйлисең,
майтарасың зур эшләр...
Ә беркөнне йөрәгеңне
шик-шөбһә ала тешләп.

Барып көзгегә карыйсың —
бер үзгәреш чагылмый!
Һәм сизәсең — оныткансың
син елмайган чагыңны.

Һәм көчәнеп елмаясың...
Кирәкмәс иде юкса.
Кеше ай-һай ямьсез икән,
елмаюын онытса.

## *Туя алмыйм*

Кешеләргә карап туя алмыйм,
һич басылмый ләззәт сусыны.
Куанычлар булып тула җанга
һәрберсенең төсе, буй-сыны.

Гарип-горабалар Җирдә юктыр,
матурлыкта без бит игезләр —
җитешмәгән яклар булса, Ходай
башка сыйфат биреп тигезләр.

Картлык ямьсез, диләр... Ялган! Ялган!
Маңгай сырларына керәм дә,
адәми зат түгел, кеше булып,
яшәү серләренә өйрәнәм.

Яшьлек тиле, диләр... Булсын! Булсын!
Шунда аның бөек акылы.
Йөрәк әзер тагын мең кичәргә
яшьлек тилелеге аркылы.

Сабыйларны күреп яктырам мин —
балкый, балкый күңел күкләрем.
Ике кояш итеп кабул кылам
Ыштан кия торган «битләрен»!

Кешеләргә карап туя алмыйм.
һич басылмый ләззәт теләгем.
Басылмасын мәңге... Шуның өчен,
гомер биреп, ясак түләдем.

* * *

Мин чыгарга диеп ачкан ишектән
кемне керттең?
Күрмәдем, ләкин тойдым,
аучы исен сизгән зирәк бүредәй.
Шомрайдым да йодрык эченә сыйдым.
Чыгып киттем салкын җилле төнгә мин.
Кемгә сугыйм?
Кемне ташлыйм бугазлап?!
Бәп-бәләкәй шикләнүдән йөрәккә
тагын тулды үпкәләүле бу газап.
Кем калды ул синең җылы өеңдә,
йота-йота хисләремнең хуш исен?
Аучы исен сизгән усал бүредәй,
шул тәмсезне килде тотып ашыйсым.
Мин ташландым аңа шашып-тилмереп,
хисләремнең тырнакларын киереп...
Авыртудан айнып киттем...
Карасам,
Йөрәгемне торам икән кимереп.
Бикләнеп тә өлгермәгән ишекнең
тоткасына мин яңадан ябыштым...
Тартып ачтым...
Һәм аңладым — бүген дә
аучы эзләп йөргән бүре
ял-гыш-ты...

* * *

«Яши алсаң яшә миннән башка...»
«Җырлый алсаң җырла тавышсыз...»
Менә нинди кайтавазлар булып
кайтты миңа минем саксыз сүз.

Кайтты да ул йөрәгемә сукты...
Еладыммы, белмим, көлдемме?!
Әллә нәрсә булды шулчак кинәт—
җаным чыкмый гына үлдем мин.

Һәм терелдем... теләмичә генә,
ләгънәт укый-укый үземә.
Күзләремә кайнар терек суы
тама иде синең күзеңнән.

## *Мәдхияләр*

1

Мәхәббәттән тудым.
Дөнья буйлап киләм...

Җаным — төп байлыгым.
Беркайчан да бөлмәм!

Мин хурлыкта үлмәм,
чөнки сөя беләм!

2

Яшә, Мәхәббәтем!
Синсез йөрәк ятим.

3

Син китсәң дә тиеп,
мин матур һәм бөек!

4

Сөенечтә яшим —
бәхеткә тиңдәш мин!

* * *

Еллар аша гизгән өермәдә
арыганлык бераз сизелә.
Һәм сине дә үзгә хисләр били,
үзгә нурлар керә сүзеңә.

Йолдызларга инде күтәрелми
хыялларның изге бураны —
аяк астындагы мәшәкатьләр
итәгеңә кала уралып.

Ә очасы килә, чөнки җанда
сөю хисе һаман канатлы.
Ул тулпарны, ялларыннан тотып,
канатлары белән яңаклый.

Тулпар ярсый, тулпар бөтерелә,
йолдызларга үзен чөерә.
Сине данлап, кабат Җир өстенә
шигырь яза нурлы өермә.

* * *

«Сагындым — сагыш орды,
сырхауга сабыштырды...»
Женева җилен җиңеп,
колакта тавыш торды.

Былбыл сайрап котырды —
гүзәл бормалар борды.
Күз ачык, үзем уяу...
Төш безне кавыштырды.

Тезләремә утырдың,
кызыл шәраб йоттырдың —
үзеңнең сагышыңны
йөрәгемә йоктырдың.

Йөрәкне сагыш орды —
тибешен алыштырды.
Син мине оҗмахта да
сырхауга сабыштырдың.

## *Тамга*

Шаклар катып тотып торам
борынгылар чакматашын:
гүзәл дәһшәткә әйләнгән
ике атның горур башы!

Яу атлары булганнармы?
Әллә сабан атларымы?
Алардан соң җир калганмы,
җан калганмы актарылып?

Танауны танауга терәп,
сөйләшәме, тешләшәме?..
Әллә бия белән айгыр
дәрт ташудан кешнәшәме?

Минем хыял шул атларда
ияр менеп чапты, чапты...
Йолдызларга әверелде
тояклары чаккан чаткы.

Нинди учаклар кабынган
алар пәйда иткән уттан?
Нинди тимерләр эрегән,
нинди илләр чыккан юкка?

Нинди туйлар гөрләгәннәр?
Пешкәннәр нинди азыклар?
Кемнәр тәнен тишеп үткән
очлары утлы казыклар?

Ни-нәрсәне белгерткәннәр
учакларның төтеннәре —
кемнәргә алар шом салган,
шатландырганнар кемнәрне?

Җаным әллә нишләп китте —
аңым дөрләп яна сыман...
Әйләнде борынгы чакма
уй-хисләрем тамгасына.

## *Хәл-әхвәл*

Хәл-әхвәлләр сорашудан
башлана һәр күрешү...
Канга сеңгән гадәтләрнең
бу — иң матур өлеше!

Әйбәт, дибез, яхшы, дибез...
Бик сирәк зарланабыз,
җелекне киптерә, диеп,
Хәл-әхвәл дигән явыз.

Җанга рәхәт булып китә
хәл-әхвәл сорашудан —
барыбыз да тумыштан ук
күнегеп беткән шуңа.

Сер бирмәскә тырышабыз.
«Аллага шөкер!» дибез:
тән — җан белән, җан — аң белән,
аң заман белән игез...

## *Сәер матурлык*

Ямanлыйбыз якты көнне
очраганы беренә —
яктылыгы аның безгә
артык сәер күренә.

Ямanлыйбыз кара төнне:
артык кара тоела,
җанга фәкать кара төннән
кара корым коела...

Ә үзебез көндез — төнне,
төнлә көнне көтәбез.
Кояш Айны алыштыра...
Икесен дә тетәбез.

Менә шундый кешеләр без —
җаныбызда ят орлык
тамыр җәйгән, чәчәк ата
үтә сәер матурлык...

Хурлый-хурлый сокланабыз,
елый-елый көләбез...
Шайтан алгыры, шулай да
матур яши беләбез!

## Аллаһ кулында

«Әниең Аллаһ кулында...
Өзелә җан җепләре —
аерылабыз, ахры!..» — диеп,
әти үксеп җибәрде.

Сиксән яшьлек карт күзеннән
түгелде сабый яше...
Яшәрә хисе кешенең,
кайгыда яши-яши.

Сафлана аның күз яше,
гөнаһлар күрә-күрә...
Ахыр чиктә ул саф килеш
туфракка барып керә.

«Әниеңне Аллаһка да
бирмәс идем, улым, — ди, —
ләкин кочаклап тотарлык
көчләре юк кулымның!..»

* * *

Картайгачтың, кызык итеп
сөйләр өчен кемгәдер,
акыллылар күп мизгелгә
сер орлыгы күмәдер.

Картайгач, шактый турайгач
гомер юлы сызыгы,
акыллылар сер чишәләр —
кайта яшәү кызыгы.

## *Чиксез кодрәт*

Караңгыдан котылып була
шырпы сызып;
төнгә кереп котылып була
кояштан;
суга салып сүндереп була
утларны;
кисеп, ватып арынып була
тоташтан;
ярга чыгып котылып була
диңгездән;
туктап торып котылып була
тизлектән;
учак ягып котылып була
суыктан;
дару белән чигереп була
үлемне...
Берсенең дә кодрәте
чиксез түгел.
Чиксез кодрәткә ия тик
бер Куәт —
Вакыт! Бары тик Вакыт!

## *Сорц*

Тамырны өскә чыгарып,
күмделәр үләннәрне —
тамырда яфраклар тизрәк
үсәр дип белгәннәрдер...

Сабаклар тамыр булмады...
Чәчәк атмады тамыр...
Шушы хәлдән акыллылар
гыйбрәтле сабак алыр...

## Без калабыз

Мәңгегә хуш, чынбарлык ел!
Тыелгысыз китәсең,
һәм син безне шактый моңлы
озатучы итәсең.
Син башландың буп-буш һәм саф
сизелмәс мизгел булып.
Бакчы, бүген син нинди бай!
Нинди саллы һәм тулы!
Һәр исән кеше җанында
син гомер булып актың.
Без таптык та, югалттык та,
син таптың, таптың, таптың!
Без еладык та, көлдек тә,
башыбыз түнә-түнә,
кимедек тә, ишәйдек тә,
ә син кимедең генә.
Өч йөз алтмыш биш көн идең!
Хәзер алдыңа кара:
Ходай биргән вакытыңнан
сәгатьләр калып бара.
Шатланабыз! Үпкәләмә,
туйганнар миннән, диеп...
Синең белән гомер китә...
Моңны басабыз биеп.
Һәм без синнән бәхетлерәк
(дип уйлыйбыз, һәрхәлдә) —
син китәсең, без калабыз,
без калабыз гамәлдә.

## *Арка сөяп...*

Карурманнар уртасында,
черек наратка сөялеп,
мин гомер турында уйлыйм...
Уйларым инде сөялле.

Яшәгәнмен! Яшәгәнмен...
Үкенечләр юк та сыман,
ләкин нидер күзгә кереп,
арчый суган, арчый суган...

Килер мизгел, һәм миндә дә
вакыт агышы тукталыр...
Исемемә арка сөяп,
оныкларым уйга талыр.

## *Оста җиңелүче*

Мин һәрвакыт оста җиңелүче!
Кайчак акыл җиңә,
кайчак — хисләр...
Ләкин никтер үзем өстә калам!..
Ничек алай?
Шуңа китә исләр...

## *Бер үк тамырдан*

Җырлап башланган сүзләр дә
кайчагында җылата.
Җыр һәм җылауның тамыры
бер үк, ахры, чынлап та!
Җылыйсы килгәндә җырлыйм.
Нинди буладыр күзләр?!
Күзләрдә мөлдерәп тора
язып-язып та аңлатып
булмаслык җылы сүзләр...

## Дирижер Фуад Мансуровка

Гаскәрләр бар — кулларында
кеше үтергеч корал...
Ул кораллар күңелемә
кара нур сибеп тора...

Һәм гаскәр бар — кулларында
шатлык китергеч корал:
труба, скрипка, альт, флейта...
бәллүр нур сирпеп тора!

Кул изи дә гаскәр башы,
кораллар керә яуга.
Ә яу кыры — минем күңел,
анда шик, кайгы, гауга,

көнләшү, өметсезлекне
болгата заман җиле...
... Мәхлук була язган идем,
ярый, музыка җиңде —

юк итте төшенкелекне,
сагыштан кул күтәртте,
күңелемә урнаштырды
матур хисләр тәртибен,

кабат кайтарды җаныма
кешечә яшәү көчен!
Рәхмәт сиңа, Фуад* Мәнсур** —
моң-зарларны җиңүче!

---

* Фуад — йөрәк, күңел (гар.).
** Мәнсур — җиңүче (гар.).

* * *

*Ф-ка*

Замананы ул бит күрми —
өйдә ятып тыңлый гына.
Көннең шау-шуыннан өркеп,
чума тарих тынлыгына.
Колагында калган тормыш
тынгы бирми ләкин аңа...
Чыга көнгә... Һәм караса,
ул искергән, дөнья — яңа...

## *Ватылды*

Эчәсе шәрабым шешәсе
уңайсыз ауды да ватылды —
агылды, дөньяга аңкыды
шәрабның күңелле акылы.
Югыйсә уйлардан-моңнардан
арыган йөрәккә, башыма
дәрт өстәп булмасмы диеп, мин
тырыштым ашыга-ашыга...
Эчмәкче идем мин акылны,
киткәнче башларым әйләнеп,
беразга булса да онытып
барлыгын мәкернең, хәйләнең.
Булмады. Шәрабым шешәсе
уңайсыз ауды да ватылды...
Сихәтен сарыфка сеңдереп,
акылы туфракка агылды.

## *Яшерә алмыйм*

Сыйпа, сыйпа, кояш нуры,
җылыт әле, җылыт әле.
Миннән башка кешегә дә
кирәк әле җылы тәнем.
Кагыл, кагыл, Айның нуры,
чәчемне, әйдә, көмешлә.
Җаны җып-җылы кешегә
бәсләнгән баш та килешә.
Сибел, сибел, йолдыз нуры,
тул күземә, балкыт дымын —
мин хәзер яшерә алмыйм
көзнең якты, җылы моңын.

## *Борчылма!*

Син кайгыра беләсең шул
һәрбер кыйшык адымыма.
Күзеңдәге нурлар, әнә,
бөртенгәннәр салкын дымнан.
Иреннәрең тартышалар
ябылалмый интегүдән.
Син борчылма!
Миңа бары
замана салкыны тигән...
Әгәр дә борын тыгылса,
шырпы керсә бармагыма,
кайгыр — эләкмәдеме дип
берәр дәһшәт кармагына.
Әйе, бераз йөзем чытык,
күзем боек, баш иелгән...
Син борчылма!
Миңа бары
замана салкыны тигән...

## *Көмеш туйлар аръягында*

Көмеш туйлар аръягында
дәртле хисләр юктыр дип
уйланулар ничә еллар
безне утлар йоттырды.
Йөрәктәге янгын көле
чәчләрне көмешләгән.
Баш агарса да кар кебек,
хискә кырау төшмәгән.
Ә төшкәннәре эрегән
һәм әйләнгән дәрьяга...
Дулкыннары һаман җанга
кайнар моң булып кага.

* * *

Язасым килсә дә язмыйм...
Ачмыйм әле серемне...
Гомер уза... Йөрәгемдә
янган серләр сөреме.
...Яна тәмәке. Төтендә
куәте аның исән —
аңыңны әллә нишләтә,
каныңа сеңсә-тисә.
Серләремнең сөременә
кем җитәр дә, кем тияр?!
Әгәр тисә, сокланудан
алдымда башын ияр...

## *Көтмәгәндә җылытты*

Сизенәм дә, сизенмим дә...
Аңлыйм кебек... Аңламыйм —
әллә йөрәк каты тора,
әллә акыл алдалый...
Күңел бикле. Үтми давыл.
Суык та юк, эссе дә.
Ләкин язгы яңгыр ява
күзгә сүрән хисемдә.
Сәбәбе дә һич юк кебек —
туфрак тартмый болытны.
Ләкин дөнья шундый матур —
көтмәгәндә җылытты.

## *Мине чакыр*

Мине бик тә сагынганда,
мине шашып сагынганда,
түзалмаслык сагынганда
җырла әле бер матур җыр.

Матур җырны җырлаганда,
моңлы җырны җырлаганда,
яшьле җырны җырлаганда
күз алдыңа килер чатыр.

Күз алдыңа килгәч чатыр,
зәңгәр чатыр, иркен чатыр,
аулак чатыр, серле чатыр,
шул чатырга мине чакыр.

Мине бик тә сагынганда,
мине шашып сагынганда,
түзалмаслык сагынганда
җырлар өчен бу моңлы җыр...

## *Җиләс җил вальсы*

Каядыр очып китәргә
җыена таллар —
Толымнарын канат итеп
җилпиләр алар.

Чайкала кырлар-болыннар
ефәк итәктәй —
биюгә чыга җиләс җил,
мине җитәкләп.

Әйләнәбез-тулганабыз,
зилзилә булып —
аста кала яшел урман,
аста ак болыт.

Йолдызларга кагылабыз
биеп барышлый,
шуларның берсендә безне
бәхет каршылый.

Әй җиләс җил, әй дәртле җил,
нишләттең мине?
Кабат искә төшердең бит
иң гүзәл көнне —

бар дөньябызны онытып,
шундый биедек —
җанга керде Сөю дигән
изге бөеклек!

## *Көмеш тотка*

Казан тәрәзләре гөл-чәчәк.
Бу тәрәзгә кемдер киләчәк.
Көмеш тотка,
җиз келә —
шакып карыйсы килә!

Казан ишекләре бизәкле,
күгәннәре бакыр үзәкле.
Көмеш тотка,
җиз келә —
ачып карыйсы килә.

Казан тәрәзләре бизәкле,
ишекләре корыч йозаклы.
Көмеш тотка,
җиз келә —
бәхеткәдер, кем белә...

## *Ак теләк*

Алтын-алтын яфраклар
төште, төште учыма.
Алтын-алтын теләкләр
килделәр тел очыма:

Һәр агачны һәр язда
яшь яфраклар төрсеннәр.
Кешеләр дә алардан
гыйбрәт ала күрсеннәр.

Каурый-каурый ак карлар
кунды, кунды учыма.
Ап-ак, ап-ак теләкләр
килделәр тел очыма:

бетмәс-төкәнмәс юллар
Җир тирәли китсеннәр.
Без барасы ак юллар
ак бәхеткә илтсеннәр.

Сәйлән-сәйлән тамчылар
тамды, тамды учыма.
Матур-матур теләкләр
килделәр тел очыма:

гөлләр чәчәк атсыннар,
сәйләннәрдән төс алып;
чәчәк атсын кешеләр,
мәхәббәттән көч алып.

## *Сөен!*

Җаның барда — сөен,
тыңла яшәү көен.
Авыз йомып торма,
кушыл да бер җырла.
Җырла үз җырыңны:
урманың, кырыңны,
авылың, калаңны,
диңгезең, далаңны,
миләшне, баланны
җырла!

Җаның барда — сөен,
тыңла яшәү көен.
Колак сал җилләргә —
кем сәлам җибәргән,
кем сине чакыра,
нинди ярдәм сорап...
Нинди шау дулкында,
нинди тынлык комда,
ни яна ялкында,
тыңла!

Җаның барда — сөен,
тыңла яшәү көен.
Моңлыларга эндәш,
ялгызларга сүз дәш,
көйләш картлар көен,
көйләш яшьләр көен,
баеп китсәң, азма,
назың барда назла —
Ходай шулай язган!
Назла!
Күк астында өең,
Җир өстендә сыең.
Дөнья — тәнгә кием,
ә тән җанга кием.
Яшәгәндә — сөен!
Сөен!

## *Себер тракты*

Синең буйлап күпме язмыш
ерак Себергә акты...
Хәзер таңга ашкынасың,
Себер тракты.

Үзәк урам булмасаң да,
син киң урам, син якты.
Син тормышым үзәгендә,
Себер тракты.

Онытмамын, чөнки синдә
сөйгән ярымны таптым.
Безне бәхеткә алып бар,
Себер тракты.

## *Кызыл шәфәкъ*

Тәрәзәмдә һәр кич кояш байый...
Кызыл шәфәкъ тула өемә,
куера да, җылы болыт булып,
өстәлемә минем өелә.

Шуны сулыйм... Кичке куе уйлар
ага башлый җанда елгалап...
Киләчәктә киртә... Үтеп булмый...
Китеп барам үткән елларга...

Сагынаммы? Юк, сагынмыйм бугай —
ни мәгънә соң: сагын, сагынма...
Уйлар каршы бара алсалар да,
еллар ага мәгълүм агымда...

Үкенмим дә... Үкенечләр белән
кыерсытыйм нигә өметне?!
Барыбер бит алар язмыштагы
көек тәмен һич тә киметми...

Барлыйм гына салкын акыл белән...
Бәһаләмим, юк, юк, үлчәмим...
Вак-вак йотып, кызыл шәраб итеп,
кызыл шәфәкъ кенә эчәм мин...

## Төсләр алмашыну

Яшел, яшел, яшел, яшел, сары.
Җәйнең кулы барлый яфракларны,
онытмаска билге куя-куя...
Ләкин бик тиз яфрак санын җуя
һәм яңадан саный-саный барлый:
яшел, яшел, яшел, сары, сары...

Яшел, яшел, яшел, сары, сары...
Болай түгел иде кичә... Ярый,
ялгышканмын икән — төзәтермен.
Төзек сыман иде бит хәтерем...
Җәйнең кулы ябалдашны тарый —
яшел, яшел, сары, сары, сары...

Яшел, яшел, сары, сары, сары...
Уйларымда туган яшен шары
күңелемне кинәт өтеп алды —
Миндә ничә яшел яфрак калды —
кояш нурын эчә алганнары?!
Яшел, яшел... Санарбыз аннары...

* * *

Сары яфрак. Яшел камыш.
Тирән күл. Ап-ак томан.
Зәңгәр чәчәк. Күк тузганак...
Исерек рәссам сыман,
табигать хискә бирелгән,
югалткан ул мантыйгын...
Әй, Табигать, кер йөрәккә,
сине тагы да сыйлыйм
исерткечрәк хисләр белән,
гүзәлрәк мираж белән...
Чәчем сирәк.
Күзләр куе.
Йөрәк күп серләр белә.

## *Ак шом*

Ак каеннар ап-ак карда.
Ак урманда ак томан...
Җанны ак шом биләп ала
мондый сүрән яктыдан.

Артта — ак эз...
Алда — аклык...
Ничек алга барасы?
Ярый әле каеннарның
кара калган карасы!

Кышкы урман — аннан-моннан
сөртелгән кара такта.
Кем ни язып сөртте икән,
җилләр йоклаган чакта?

Бәлки, язмыш китабының
ул трагик битедер...
Ихтимал, кышны аклыгы
ахыр чиктә үтерер...

* * *

Алтын көзне Канадада күрдем...
Россиядә кара көз иде —
шартлаулардан, сары яфрак кебек,
күпме-күпме гомер өзелде!..

Йа чуарлык! Җирнең җитмеш төсе!
Күз күрмәгән җете купшылык!
Әллә ничек җаным-тәнем белән
купшылыкка киттем кушылып.

Тыйнаклыкта бәхет диләр иде!
Бер дә алай түгел икән ич!
Күпме гомер ак та кара булды.
Күзләремне кыра үкенеч.

Чум икән ул төсләр байлыгына,
тирбәл икән көйләр эчендә.
Җан ул шундый — төссезлектән башлый,
хиссезлеккә таба күченә...

## *Күз тимәсен*

Син сокланып карап торган чакта
ерганаклар тулы йөземә,
күңел бакчамдагы куакларда
сары яфрак шаулап өзелә.
Ул кушыла кошлар төркеменә —
алар канатында китә көз...
Табигатьтә ап-ак кышлар килә,
ә күңелдә җәйне котәбез.
Күңел бакчамдагы куакларда
барлык яфрак җете яшелдән.
Күз тимәсен әле — күзем йомам,
күзләреңнән җанны яшерәм.

## *Зәңгәр моң*

Гел зәңгәр күз,
гел зәңгәр күз иде...
Балачактан миндә зәңгәр моң.
Зәңгәр булып төсмерләнә иде
кичен яңгыраган һәр гармун.
Гөлләр исе миңа зәңгәр иде,
зәңгәр иде тамчы чыңы да,
күк гөмбәзе зәңгәр кыңгырау иде,
ә мин аның теле — чынында.
Кайда гына барып бәрелсәм дә,
зәңгәр булып күктән моң яуды,
зәңгәрләтте бөтен нәрсәне ул,
зәңгәрләтте бөтен дөньяны.
Зәңгәрләнде язгы, көзге җилләр,
зәңгәрләнде аһлар, күз яше.
Әллә инде һәрбер зәңгәр күздә
зәңгәр чаткы булып мин яшим?!

## *Аклык вальсы*

Ап-ак кашкарый
кояшка карый.
Аңарга рәхмәт укый
гөлнең күзләре.
Гөл җанын аңлыйм:
кояшны данлый —
җырга әйләнеп китә
чәчәк сүзләре.

Ап-ак ромашка
карый кояшка...
Ул да кояштан ала
назлы яктылык.
Ромашка гынам!
Сиңа кагылсам,
йөрәгемдә җыр туа
ак дулкын булып.

Ап-ак гөлләрдән
ал гыйбрәт-ярдәм —
алар кояштан ала
гүзәллек көче.
Җыр булып гөрлик,
җил булып биик,
санап биргән гомерне
матурлар өчен!

* * *

Көннең елмайганы юк бик күптән...
Елак төннәр түгә кара су...
Өзеп-өзеп йөрәк куя сызып,
дәвалыйсы килми ярасын...

Җан күшегә...
Хисләр сүсәрәләр...
Ерагая уйлар чынлыктан...
Ярый әле юл буенда үскән
Сары чәчәк очрап җылыта.
Шәмәхәсен, күген, алын, агын
сүрелдерә соры сүрәнлек...
Без шуларны шатлык төсләре дип,
җырлар чыгарырга өйрәндек!..

Әй, кояшның чыклы кыйпылчыгы,
юл буена сине кем сипкән?..
Сары төсне моннан болай һич тә
сагыш төсе диеп кимсетмәм.
Кайнар иреннәрем үбә сине —
яктылыгың кала ягылып...
Вакыт җиткәч, салкын кулларымны
син дә җылытырсың кагылып...

## Автопортрет-90

Күзгә-күз калган чакларда үзем белән
тугарылып мин үземнән үзем көләм,
бармак төртеп... Исәрләнеп... Шаша-шаша.
Һәм көзгенең салкын пыяласы аша
бәреп чыга күзләремнең зәңгәр нуры,
ялкынсынган горурлыгыма тоташа.

Айнып китәм... Искә киләм... Тетрәп куям.
Ике дөньям йомган күзләремә сыйган...
Күңел күзем кылганнарымны актара —
ак та кара, ак та кара. Ә арттарак
кирәк сүзләр ятып калган әйтелмичә,
фәрман көтеп, минем күзләремә карап...

Азмыни ул безнең күздә сүзгә киртә?!
Яшәдек ич шәүләбездә өркә-өркә.
Шушы курку күздә калган яры булып.
Үз-үзеңнән көлү генә дары булып
шартлатала киртәләрне. Шуңа күрә
үз-үземә карыйм яшен шары булып.

* * *

Төннең шомы тиеп уянып,
мин тын гына ятам уйланып...

Моңа кадәр ничек яшәдем?
Ник сүз әйттем? Нигә дәшмәдем?

Авызына нигә сукмадым?
Баскан килеш нигә йокладым?

Кочагында нигә калмадым?
Аласыны нигә алмадым?

Бирәсене нигә бирмәдем?..
Сорауларның утлы төргәге

сүтелә дә төнне тутыра.
Төн давыллый, йолкый, котыра...

Инде җавап бирер урында
һаман сорау... Гомер турында...

## *Сурәтемә 93 нче ел сызыгы*

Бизәми мине буй-сыным,
ак йөзем, авыр башым,
яктырта тик җаным нуры,
дәртле тәнемнән ташып.

Тимер кебек тыгыз түгел,
түгел судай сыек мин,
кояш төсле дә булалмыйм,
Ай төсле дә боекмыйм.

Эретми мине җылы сүз,
җылы караш — эретә...
Ир итми мине көч-куәт,
мине сөю ир итә!

## *Минем җаным*

Төнге яктылык
һәм көндезге караңгылык
арасында ара булып
очып йөргән куе болыт —
минем җаным.
Асты Җиргә якын — асты ал кан.
Өсте Күккә якын — төссез томан.
Тәнем, сер сөйләргә әзер балбал сыман,
җаны кайтканны көтеп тора.
Һәм ул кайта, сеңә минем тәнгә...
Һәм мин
төнге яктылык
һәм көндезге караңгылык
арасындагы сергә тәңгәл.

## *Миңнәр*

Миңле кеше бәхетле була.

*Халык юравы*

Аркам миңле булгангадыр —
авырны
күп күтәрдем. Белмим кайчан
авармын...

Беләк миңле — эшлим, эшлим
туктамый,
үзем табып киям җитмеш
нукта мин.

Авыз миңле — бусы да рас,
ач түгел,
бик тук булсам, бетәр иде
ачы тел.

Колагым миңле дә түгел.
Ни файда? —
күпме нахак сүз ишетәм
шулай да...

Ике күзгә бер генә дә
миңем юк,
ә күз тулы утлы дым һәм
дымлы ут.

## Әниемә

Син элек тә матур идең...
Син хәзер дә бик матур...
Күзем тагын кемгә карап
бу хәтле ләззәт татыр?!

Чәчләреңне җил таратса,
җем-җем итә кояшта,
әйтерсең җәяүле буран
агып ята юл аша,

скрипка кылларыннан
салмак кереш узгандай.
Безнең күзләр арасында
моң давылы кузгала...

Бозлы тынлык күз карасын
чәнчи дә яшь чыгара...
Һәм син елап җибәрәсең,
мин тырышам чыдарга,

түкмәскә күздән яшемне —
күзьяшь аша карап мин,
һәр сабый күк, сине, әни,
мәңгелеккә яраттым...

## *Тормыш алда гына*

Адым атлап узган юлларымны
уем белән узып утырам.
Гомер җиле эзләремә минем
төрле-төрле хисләр тутырган.
Кайчакларда тетрәп-тетрәп куям —
ничек шулай атлый алганмын?!
Упкын кыры буйлап йөргәнмен дә —
искитмәле — исән калганмын.
Килә кайчак кайбер эзләремә
кабат басып шунда каласы...
Олы мизгел өчен бар үткәнен
бирә ала адәм баласы.
Кайберләре йөзне кызартырлык.
Андыйларын килә күмәсе —
тузанының хәтта бөртеге дә
килер буыннарга тимәсен.
Әмма ешрак бер елыйсы килә
кайбер эзләремә капланып —
бәхет эзе бераз читтә булган,
мин үткәнмен шунда атламый.
...Хисләремне хисләр алыштыра...
Үз-үземә туа үтенеч:
алга кара — тормыш алда гына,
ян-як — гыйбрәт, артта — үкенеч...

* * *

Җилләрдә җилфердәдем,
яңгырларда коендым...
Кем ышыкта утырды,
шуңа бүген кыендыр...

Кояшларда көйдем мин,
суыкларда өшедем...
Хәле хәлдер гомергә
посып яткан кешенең...

Күзләрендә саргайдым,
язларында яшәрдем...
Җирем белән тоташып,
кеше булып яшәдем!

Тормыш белән сугыштым.
Үлемгә каршы — әзер.
Хәтта җәннәт ямендә
чыдый алам мин хәзер!

* * *

Бизәксез чорда яшибез
диеп һич тә санамам —
хәзер төрле ахмаклыклар
чәчәк аткан замана.

Чәчәк булгач, җимеше дә
аның, һичшиксез, пешәр,
уйланып ятканда бермәл
өзелеп башка төшәр.

Шул баш, бәлки, ачыш ясар —
чорны бизәячәкне...
Ләкин дәвер Ньютоны
күрәме ул чәчәкне,

вакытында ятыр өчен
җимеш төшәсе төшкә?..
Күрәдер... Ләкин уйлыйдыр:
«Төшеп башымны тишсә?..»

* * *

Кемне кысып маташасыз,
әй, сез, мескен ваклыклар?!
Йөрәгемдә — кыскан саен —
көче арткан хаклык бар!
Мин бирешмәм төрткәләүгә,
кызмамын ышкулардан...
Вакытлыча гына көчле
һәртөрле эшкуарлар.

Алга карап туры барам,
атлыйм атлый белгәнчә.
Үкчәмдә сез сытыласыз,
исән кала гөл-чәчәк.
Сезнең өчен мин һай авыр —
чөнки миндә хаклык бар.
Кайчан, кайда күтәралган
хаклыкларны ваклыклар?!

Мин нинедер ватам, имеш!..
Нәрсәнедер җимерәм!..
Авасыны аударырга,
әйе, давыллап өрәм.
Ныгыйсыны ныгытырга
кызганмыймын һичнәрсә!
Сөембикә манарасы
тураер, мин терәсәм.

* * *

Уең белән аякларың тизлеген уз,
бераз алга таба кит тә барып тукта,
рухым минем! Фәрештәчә яшәп карыйк
комсыз күзең, туймас тәнең, телең юкта.

Тәнне вакыт көннән төнгә, төннән көнгә
Җир әйләнгән тизлек белән генә йөртә
кибетләргә, конторларга, бардакларга,
әбрәкәйгә, ресторанга кертә-кертә...

Тән керләнә. Мунча кирәк... Чабынасың...
Күз көнләшә... Җан таплана... Яшерәсең...
Фаш итәләр... Оялталар... Тез чүгәсең...
Тел тешлисең, сыгыласың... Баш бирәсең...

Вәсвәсә күп. Өстен калу мөмкин түгел.
Мең теләдем... Тырышлык та хәттин ашкан.
Хәзер беләм — рух ул бөтен түгел икән
күлмәк, ыштан, башмак кигән тәннән башка.

Вәсвәсә күп. Һәм аларга кереп поскан
даһи шайтан ымсындыра тәнне, алдый
һәм кол итә! Ә тән колы булган бәндә
рухы җиткән офыкларга җитә алмый.

## *Кәшә авылы-1*

Кәшә белән Васильевка арасында
шундый күлләр иде!
Шундый таллык!
Шул таллыкта, шул күлләрдә
без Тарзан да, Робинзон да
була алдык.

Кәшә күленең суы шундый җылы иде,
шундый тоныкь, шундый серле!
Шул суларда без капитан Грант булып
йә капитан Немо булып йөрдек.

Кәшә сабан туе кебек зур сабантуй
Казанда да хәтта юктыр.
Егылганга беренче тапкыр шунда еладым мин,
беренче тапкыр шунда ектым.

Кәшә урамында
шәһәрдән кайткан кунак кызы
күргән идем ерак язда,
гомер буе шуңа, адресын, исемен белмичә,
хат кебек нәрсә язам,

язам, язам, язам, язам —
һаман бетми... Ә гомер үтә тора...
Язганымны, әрәм булмасын дип,
бер барып ирешер әле дип,
китап итә торам.

## *Кәшә авылы-2*

Кибеп барган күлкәеңнең
дулкыны белән, Кәшә,
картаеп барган канымның
дулкыннары сөйләшә.

Сулары кипсә дә, күлең
яшәү өчен көрәшә.
Күз яшьләрем бирер идем,
файдасы тисә, Кәшәм.

Арабызны еш аерды
кар, яңгыр, томан, рәшә,
ә җаным тамыры синнән
һич өзелмәде, Кәшәм.

Кайтам, китәм... Сирәкләдем —
гафу итә күр, Кәшә.
Мин бит сиңа уйларымда
җәннәтем дип эндәшәм.

Ә җәннәткә бер керәләр,
нинди булса да яшәү.
Син, димәк, хәтта җәннәттән
көчлерәк, минем Кәшәм!

Бер очың — алма бакчасы,
бер очыңда берләшә
татарың белән чувашың —
син дуслык багы, Кәшә.

Киләчәккә туры карап,
тарихың барлап яшә.
И Кәшә — якты юл башы,
бәхет бишеге, Кәшә!

## *Буа җыры*

Һәркайдагы кебек Кояш,
Йолдызларың һәм Аең —
ә шулай да син күпләрдән
яктырак, Буакаем.

Әй, Буам-Буакаем!
Җаннарыма җылы алам,
кайтып бер күргән саен.

Һәркайдагы кебек таллар,
наратлар, юкә, каен —
ә шулай да син күпләрдән
ямьлерәк, Буакаем.

Әй, Буам-Буакаем!
Җаннарыма җылы алам,
кайтып бер күргән саен.

Һәркайдагы кебек кышлар,
моңлы көз, көләч маең —
ә шулай да син күпләрдән
серлерәк, Буакаем.

Әй, Буам-Буакаем!
Җаннарыма җылы алам,
кайтып бер күргән саен.

## *Казма*

Лашчы үрләреннән, Казма,
син бик матур күренәсең —
Зөя суы тукып биргән
өрфиягә төренәсең.

Суыкларда иңнәреңә
ябынасың көмеш парча...
Яши беләсең син, Казма,
җәен — гөлчә, кышын — карча.

Елларның һәр фасылында
син үзеңчә якты, күркәм...
Шигыремнең һәр хәрефен
Зөяң суы белән сөртәм,

гөл яфрагын сөрткән кебек...
Иркен сулап куя сүзләр.
Җыр юллары булып бүртер
минем синдә калган эзләр...

Син Казмамы, Казылмамы?
Исемеңнең бар бит сере.
Серне ачарлык биеклек
булса икән Лашчы үре!..

## *Авыл мунчасы*

Эссе ләүкә. Каен исе. Тәнем буйлап
«Оҗмах, мөгаен, шушыдыр!» дигән уйлар

биешәләр лепер-лепер, ачкүзләнеп...
Әмма мондый рәхәткә мин күп түзмәдем,

очып чыктым бәсәреп киткән чоланга,
йөрәгемне ачулана-ачулана...

Шул мизгелдә әверелдем болытка мин...
Күтәрелдем әллә кая... Онытканмын

бар дөньямны һәм вакытны... Җем-җем итә
ак болытта утлы тәрәз... Үләм-бетәм —

бу бит Бик-Үти мунчасы! Яттым карга
һәм мунчада ни булганны торам карап...

Күптән түгел алар өйләнешкән иде,
төшкән килен җиләк кебек пешкән иде...

«Ах, оятсыз, син нишлисең?» — диеп кемдер
шулчак таяк белән сыртка бирде берне,

һәм өзелде иң шәп кино... Торып чаптым...
Исемә төшсә, оялудан аркам чатный

әле булса... Озакладым... Туңдым, керим —
җанны кабат оҗмах җылысына төрим...

## *Уйланабыз*

...Уйланабыз,
уйланабыз...
Төштә, өндә уйланабыз:
хөр яшәгән кебек идек —
уйнаганбыз, уйнаганбыз!
...Ләкин уйнап туймаганбыз,
нәфсебезне тыймаганбыз...
Хөрлек безгә капка ачкан,
без капкага сыймаганбыз,
этешкәнбез, төртешкәнбез...
Сизмәгәнбез, тоймаганбыз —
хөрлекнең капкасы ватык,
ә үзебез кыйналганбыз.
Уйнаганбыз,
уйнаганбыз...
Эштә, төштә уйнаганбыз.
Азарттан ничек чыгыйк, дип
уйланабыз, уйланабыз...

## *Ике гаскәр*

Күңелемдә минем ак гаскәр бар...
һәм бар анда кара гаскәр дә.
Бер-берсенә алар гомер буе
торды төрле ызгыш хәстәрләп.

Көн дә алар ярсып сугыштылар.
Кара ота йә ак мат куя.
Ә мин гадел, имеш, җиңүчегә
чын күңелдән җырлыйм мәдхия.

Җиңүчегә, имеш, хаклык юлдаш!
Җиңү китермәде җиңеллек...
Хәзер генә мин аңладым бугай:
«җиңә-җиңә» яшәп җиңелдек,

«җиңә-җиңә» яшәп сукырайдык,
һәм күрмәдек юлда хәтәрне,
вак-төяккә генә абындык та
йөрәк ярыгына мәтәлдек...

таш тоз булып, ачу ташы булып.
Әрни-әрни хәзер айныйбыз,
һәм күрәбез куык җиңүләрдән
туган мәдхияләр кайгысын.

Күңелемдә минем ике гаскәр...
Көн дә алар ярсып сугыша.
Орышлары ихласланган саен,
иркенәер кебек сулышлар.

## *Акылсызлык билгесе*

Акыллы булмак буласың —
белмибезме әллә без?!
Иң кирәк минутларда да
әйтми кала алдың сүз.

Уңга борылып әйтергә —
ышанмадың уңыңа.
Сул якка карап әйтергә —
ышанмадың сулыңа.

Турыга йөрәк җитмәсә,
йә чиген, йә чүгәлә —
тарихыбыз юлы тулы
синдәй сүзсез чүмәлә.

Кыюларга киртә булма
сүз атырга, шуны бел:
сүзләрен уктай атмыйча
ныгый алмый һичбер тел —

заман шундый! Көткән идек
синнән утлы, җилле сүз...
Акыллы булып кылану —
акылсызлык билгесе.

* * *

Килеп җитте менә тагы сабантуйлар...
Көрәшәләр җанда төрле-төрле уйлар,

белеп булмый әле кайсы кайсын егар —
яңасымы, искесеме өстен чыгар?..

Яңа — кыю! Иске — җайлы! Кайсысына
хәсрәт азрак, бәхет бераз күбрәк сыйган?

Һәм быел да, үҗәт марафончы кебек,
йөгерешкә чыкты җитмеш яшьлек өмет,

сәерлеге артты аның елдан-елга:
әллә кая китә иде ярты юлда,

беркайчан да җитми иде финишына...
Бигрәкләр дә җан борчыла менә шуңа!

Ләкин хыял һаман матур булып кала,
баганага менеп ел да әтәч ала...

* * *

Болытларның бүген агы ага,
каралары кая киткәндер?..
Ак болытлар белән аралашып,
агып кайтты зәңгәр үткәнем.

Күкләр сыйган күлдәвекләр кайтты.
Әй, тавыклар, зинһар, кермәгез,
иң беренче күргән диңгеземнең
тиңсезлеген вата күрмәгез!

Кәгазь самолетлар кайтты җанга,
кабат канатланды хыяллар —
кәгазь самолетта очып менеп,
йолдызларга исем уялам.

Тарзан урманнары шавы яңрый...
Табигатьнең кыргый баласы
бик буласым килә минем бүген —
ирек бирми Казан каласы...

Таяк аргамаклар көтүенең
күзгә керде җылы тузаны,
һәм йөрәктә янә иярләнгән,
юлга әзер атлар кузгалды.

Якты Кәшә кайтты, җылы Казма,
кыю Зөя, моңлы Бола-су.
Күзгә яшьләр килде... Юк, түзәбез!
Әйдә, әнә каләм еласын...

Җан талпына, үреләүрелә болытка —
туктатырга, ахры, ашыга.
Ә болытлар шундый якын ага,
хәтта кагылалар башыма.

## *Ветеран*

Кичәге көнен алдылар
йөрәгеннән суырып...
Калды ул саңгырауланып,
калды ул сукыр булып...
Ишеткәнен аңлый алмый,
ул танымый күргәнен...
Юлын капшый да уйлана:
бу үргәме, гүргәме?
Шик-шөбһәсен әйтеп карый,
игътибар юк беркемнән...
Ә яшьләрнең керфегеннән
мыскыллы нур бөркелә.
Елый алмый карт ветеран,
бик елыйсы килсә дә...
Йөрәк даруы эзли ул
гүр тирәнлек кесәдән.
Таба алмый... Кабалана...
Оныта шул, оныта!..
Валидол киләсе көндәй
аңа шушы минутта...

## Әгәр

һәр уемны әгәр
әйләндерсәм сүзгә,
һәр серемне әгәр
мин калдырсам эздә,
һәр ачудан әгәр
йодрык төенләсәм,
тузынып та әгәр
кабат өелмәсәм,
һәр үпкәне әгәр
куенда таш итсәм,
һәр нәфрәтне әгәр
күземнән ташытсам,
һәр үчемне әгәр
кабындырсам уттай,
һәр хурлауны әгәр
сүзсез генә йотсам,
һәр шакуга әгәр
йөрәгемне ачсам,
һәр мактауга әгәр
бөркет булып очсам,
бәлки, яшәү җиңел
булыр иде миңа,
тик тирәмдә дуслар
калыр иде микән?..

## *Сарут*

Үсә сарут төндә, карлы якта,
үсә сарут дымга ярлы якта,

үсә сарут тау-таш ярыгында,
үсә сарут кайнар сары комда...

Таптала да сарут, утала да,
су астында сөрси, утта яна.

Инде беткән, күптән кипкән, дисәң,
җаны һаман аман, үзе исән,

нәкъ милли хис кебек, авыр чакта
җанын әллә кайда кала саклап.

Кызганудан аңа тама яшең —
сарут сөңге төртә, ул ямь-яшел.

* * *

Мин августныкы, ахрысы,
август аеның улы —
һәр төшем, һәр күзәнәгем
купшылык, байлык тулы.

Язның сыек төсмерләре —
төс булып куерган чак!
Җәйнең тотәгән чырасы —
ялкынлап торган учак!

Күңелемнең кырларында
өлгерә арыш, бодай...
Бер айны да җаным болай
олы булалмый бугай.

Бер айны да хис-тойгылар
булмыйдыр болай сизгер,
ә үзем бу айдагы күк
һәм гөнаһлы, һәм изге!..

Мин тәгаен августныкы,
август ае баласы...
Килә дуслар хәтерендә
август булып каласым...

## Бирәү

Гомер буе мин бирәүгә
өйдем тау-тау яхшылык...
Яхшылыклар кайта торды
миңа очлы таш булып.

Шул тауга ышыкланып ул
яшәде киерелеп.
Ләкин аның да бәгырен
нәрсәдер торган телеп —

яхшылык кылучы, димәк,
көчлерәк алучыдан!
Ә бәләкәй көнче йөрәк
торамы моңа чыдап?!

Түзәме соң, күзен йомгач,
үзен Аполлон диеп
хис итүче бер кәкрүшкә,
җанына төшсә көек?!

Синнән алган яхшылыкны
ташка әверелдерә...
Йа Хода! Һәрбер кешедә
бардыр ул шундый «бирәү»...

* * *

Ни яз түгел...
Ни көз түгел...
Кары да... Яңгыры да...
Җир җиләге чәчәкләре
һаман маңгай сырында.

Алар йөрәккә төшәләр
хуш исләр булып агып...
Яшьлек хисен уяталар,
ак дулкыннарын кагып.

Хатирәдә йөзә-йөзә
тукталам шушы ярга...
Җир җиләге чәчәкләре
әйләнгән инде карга.

Ни яз түгел, ни көз түгел
хис дәрьясы ярында...
Җир җиләкләре өлгерә
истәлекләр карында.

## *Меланхолия*

Кәгазьләрем һаман чиста килеш...
Бәлки, инде сүзем беткәндер —
мәхәббәтем элеккечә тозлы,
нәфрәтем дә инде күптәнге.

Гомернең дә, август аша узып,
сентябрьгә кереп барышы.
Бусына да җаным күптән күнгән —
уенда да юктыр карышу...

Нарат ябалдашы аша үтеп,
кояш нуры кергән тәрәзгә,
кәгазьләргә төшкән... Янып ята,
янып ята ласа кәгазьләр!

Янып ята ласа!.. Мин аларны
күләгәле җиргә этәрдем...
Һәм ничә көн, сискәндерде, диеп,
кояш нурын әрлим-битәрлим...

## *Ключарев*

Көйләренә аркау җебе итте
Оренбурның дала җилләрен.
Урал тавы итәгендә үскән
якты, гади, горур гөлләрнең
таҗларыннан тамган чыклар чыңын
кушып үрде аркау җепләргә,
Кырлай урманнары пышылдавын
аккорд итеп кушып җибәрде
һәм өстәде халык моңнарыннан
берәмтекләп җыйган табышын —
Идел агышының татар җире
белән сөйләшүе тавышын!
Илгә нинди көйләр бүләк итте!
Һәрбер көйдә гөлле көләч рух.
Ул Казанның җырлы бер символы,
Александр ага Ключарев!

## *Сәйдәш*

Халык күңеленең мәгърур моңы,
Әверелеп кеше сынына,
Казан урамнары буйлап йөргән,
Уйчан гына йөргән, тын гына.

Күрүчеләр аны — бәхетлеләр...
Күрмәсәм дә, миңа ул таныш —
Балачактан бирле куаныч бирде
Зәңгәр күзле сихри бу тавыш.

Сүзләр, төсләр ярдәм итмәгәндә,
Кичергәндә рухым буталыш,
Һәрвакытта миңа ярдәм итте
Киң күңелле, дәртле бу тавыш.

Зәңгәр күзле, якты йөзле Сәйдәш,
Әверелеп халык моңына,
Күңелләрдән күңелләргә үрли,
Уйчан гына үрли, тын гына.

# *Рәссам Харис Якупов*

Мизгел, туктал, син гүзәл!..

*В.Гете. «Фауст»*

Шатлыкның, сугышның, хезмәтнең
төсләрен беркеттең киндергә.
Һәр кеше тукталган мизгелгә
үзенчә тел һәм җан иңдерә,
үзенчә сөйләшә андагы
кешеләр, әйберләр белән дә...
Таң кала: нихәтле гыйбрәт бар
болытта... мылтыкта... үләндә!..
...Мин алтын көз белән сөйләштем —
күчердем күземә бар нурын,
әйләнеп Фаустка, кычкырдым:
«Кузгалчы, мизгелнең матуры!
Бизәче һәр кеше күңелен —
кызганма алтының, якутың...»
Син әллә нишләттең лә мине,
әй төсләр шагыйре Якупов!

## *Исеңдәдер...*

## *Цикл*

**Бакый Урманче**

Исеңдәдер, исеңдәдер, Бакый ага,
кыш көне дә кайткан идек без Казмага,
болай гына, иснәргә авыл һавасы —
калада авылдан килгән кем табалсын
сулагач та җан исерә, акыл айный
торган һава!.. Хәзер моны мин дә аңлыйм.

Син ул чакта бик яшь идең — җитмешеңә
бер чакрым иде әле... Чит кешегә
сөйләсәң дә ышанмастыр — җегәреңнең
утыз яшьлек ун хатынга җитәрлеген
син яшерми идең миннән, якын күреп:
«сокланып яши белүдә, — диеп, — сере...»

...Иртәгәсен җил котырды, китте буран —
көн яктысын ак кар сибеп урлый торган...
Күк белән Җир тоташтылар, Ходай кушып.
«Минем күккә аша торган чагым шушы,
тулпар кирәк, тулпар, — дидең, — артлы чана —
буран саен никтер йөрәк канатлана...»

Дилбегәне үзең тоттың. Айгыр оча
киртләч кырлар буйлап... Юк, юк, бозваткычтай
ерып бара әллә карны, әллә күкне...
Ахры, Киек Каз Юлына менеп җиттек
дисәм, дөнья әйләнәсен бер уратып,
каршыбызда калыкты Черкен зираты.

Син чанадан карга чумдың, чумдың билдән...
«Әткәй, әнкәй! Ишетәсезме — сезгә килдем», —
дип кычкырдың... Беравыкка буран тынды,
әйтерсең карга өере арып кунды
каберләрне саклап торган тирәкләргә...
Мөмкинме соң моны сүздә сурәтләргә —

зиратларда агач түгел, җаннар шавы
ега икән кешеләрне, өскә авып.
Бакый ага, син булып син дә түзмәдең —
толыбыңны көрткә яптың да тезләндең...
Балбал кебек... Дога кылдың онытылып...
Яңа өйгән көрт астында калды толып...

Торып бастың... Син — Кол Гали, тере «Сагыш».
Мин сорадым: «Шушымыни күккә ашу?»
Һәм син әйттең: «Хәтереңә биклә берүк:
күккә ашу ул, асылда, җиргә, керү,
аннан чыгу... Һәм мин чыктым. Басып торам...
Күңелемдә күк тынлыгы, монда буран

фәрештәләрен тузгыта — сыный мине...
Ишетегез! Мин буранга сыймыйм инде»,—
дип кычкырдың... Айгыр, өркеп, чапты дулап
ак мәрмәргә әверелгән кырлар буйлап...
Ә син калдың... Килсәм яныңа әйләнеп,
урыныңда бары пәйгамбәр һәйкәле...

## Гомәр Бәширов

Исеңдәдер, шәп хәтерле Гомәр ага,
иске журналлардан тузан кага-кага,
язучылар китапханәсендә генә
«урыс башлы татар» белән бер әңгәмә
үткәрүең, Җир шары күк эчтән көеп,
тәре юкмы йөрәгендә моның, диеп.

Йөрәгемә кертә алдың син кулыңны.
Капшап таптың аркылыны-торкылыны!..
Күзләреңдә тантана итте шул чакны
Мефистофель күзендәге зәһәр чаткы.
Ышанычың сынды синең, өметең дә
күзне кисте, әйләнеп ачы төтенгә.

«Йә, нәрсә бу?» — дияр өчен бәреп йөзгә,
бәгырьдәге кылларымны өзә-өзә,
аркылыны-торкылыны кырыс кына
суырып алдың күкрәктәге кынысыннан.
Алтын түгел, ялтырап торган корыч ласа!
Идегәйләр кулындагы кылыч ласа!

Әйе, бер чир бар татарда, Гомәр ага —
бер-берсенә ул кушамат, ярлык тага,
җайлый белә чыпчык, чумар һәм песиен,
шаяруга корылганын, сәясиен.
Үзең әйттең: «Безнең татар бик тиз кыза,
кушаматлар шаярудан шуңа уза...»

Исеңдәдер, шәп хәтерле Гомәр ага,
көндәй балкып, иңнәремнән кага-кага,
алып кердең бөек эзләр ишле кырга.
«Кылычың бар... Каләм ит тә җырлар тырна!»
диеп әйттең... Аннан куйдың бераз мактап,
араладың мине шулай кушаматтан.

Һәм мин менә, — яхшыдырмы, ямандырмы, —
ак кәгазьгә үз хәлемчә җырлар тырныйм.
Миндәйләр күп татарның олы кырында,
аларга да син кылыч-каләм турында
сөйләгәнсең... Һәр халыкка сирәк-мирәк
үз туксаны туксан булган намус кирәк.

### Сибгат Хәким

Исеңдәме, Сибгат ага (шулай дисәм,
үпкәләмә — миңа бит син һаман исән),
судан чак-чак юешрәктер — коры шәраб
йота-йота бер утырган идек сайрап,
сорау-җавап, җавап-сорау алыштырып,
һич чагышмас нәрсәләрне чагыштырып.

Ул заманда шәраб арзан, татлы иде.
Аны эчкәч туган сүзләр затлы иде,
кыйммәт иде тарих битләре өчен дә,
кыйммәт иде кантур бетләре өчен дә,
чөнки кайчак шундый әңгәмә бетүгә,
чакырттылар обкомга йә КеГеБегә.

Белдең... Белдек... Ә исеңә төшерүгә,
әйтә идең: «Әбиләрен өшкерим лә...
Муса кайтты, Туфан кайтты... Дәрдемәнд тә...
Ә «Идегәй», ә Гаязлар бары мәрттә —
алар исән... Уянырлар... Ышаныгыз!
Ышансагыз — коры булыр ыштаныгыз...»

Башкаларның белмим ничек, Сибгат ага,
минем — коры, чөнки яла яга-яга
чыныктырып бетерделәр — бу да файда —
дәва алып йөрисе юк әллә кайдан.
Күптән түгел янә бер дус, шактый азып,
хәтта халык дошманы дип атый язды...

Исеңдәдер, Сибгат ага, шәп бер кичтә,
судай коры затлы шәраб эчә-эчә,
сиңа сорау биргән идем туры ярып:
«Бүген татарда ничә зур шагыйрь барын
әйтегезче, кемнәр алар? Без дә белик...»
Йа Хода, син шешә тотып, шәраб бүлеп

бирдең безгә, беравыкка калдың тынып,
күзең түшәмне капшады. Аннан тоник
аккорд алды өстәлемдә бармакларың,
рояльгә баскан шикелле тармакланып.
Әкрен генә әйттең аннан: «Алар... өчәү —
берсе Туфан, берсе — Маннурдыр, минемчә,

ә тагын берсе, егетләр...» Син туктaлдың,
иң аз шәраблы стакан сорап алдың,
аннан әйттең елмайдың да әллә ничек:
«Тагын берсе... Тагын берсе... Әйдә, эчик
салып куйган шәрабларны, айнымасын...»
Һәм без эчтек... Эчтек никтер торып басып.

Һәм без моны күп сөйләдек мәзәк итеп,
янәсе, син бу сораудан шома киттең,
«без үзебез дип торабыз» дип әйтмичә...
Һәм төшендек уйлагачтын әллә ничә:
калдыргансың син безгә, чын хәким кебек,
тагын берсе мин булырмын дигән өмет.

## Мостай Кәрим

Бу дөньяның хаксыз җәзасына
Әллә күнде җаным, әллә сүнде.
Утларына төшеп янар идем,
Мин янарлык утлар да юк инде.

*М. Кәрим*

Исеңдәдер, исеңдәдер, Мостай ага,
күңелеңне канат итеп кага-кага,
син Казанга очып килдең бик җай гына,
элеккечә кукраймыйча, болай гына.
Ни җәй түгел, ни көз түгел иде вакыт,
күк гөмбәзе дә, күңел дә иде ватык...

Күктәге ярыктан Җиргә яңгыр акты,
күңелдәгесеннән, гаҗәп, акты якты —
кеше шундый: күңеленнән ул бит Алла,
Кояш сүнсә, үзе Кояш була ала...
Кояш булу кирәкмәде... Болытларга
төкердек тә китеп бардык без Болгарга.

Болгарда кабер ташлары тигез генә
ята иде авыр чиркәү нигезендә.
Ул көн күкләр никтер җиргә якын иде —
болытларның бозлы түше мигә тиде...
Салкын акыл баса алды утлы үчне —
һәм без әзер чорлар аша үтәр өчен...

...Археолог җирнең җиде кат тиресен
ачып куйган... Шуннан тәтәгән җир исе
килеп китте... Билгеләнгән чиктән генә
төштең, бастың син Болгарның чи тәненә...
Күзеңдә ут... Ул ут бик тә тирән иде...
Астан безгә кычкырдың син: «Көйрәмимме?..»

Алмыш ханнар, Кол Галиләр катламыннан
безнең катка күтәрелдең... Атлавыңнан
күреп алдым уйларыңның авырлыгын,
күз нурыңның Җиргә тигәч авыртуын,
чөнки безнең аяк асты бүген янә
яна, ләкин ул башка утларда яна...

Һәм син әйттең: «Мин сугышта утта йөрдем,
утлы ядрә күкрәгемне тишеп керде,
мин йөз бастым Прометей баскан эзләргә,
мең эләктем уттан утлырак сүзләргә,
бәхетме, бәхетсезлекме миңа тиде —
мин янарлык утлар да юк инде», — дидең.

Исеңдәдер, исеңдәдер, Мостай ага,
аннан килдек мәшһүр Кече манарага...
Ә ул, Җирне тишеп чыгып, бармак булган,
ул бармакка ун гасыр мәгънәсе тулган:
әллә күккә юл күрсәтә, әллә яный,
һәм кисәтә, гөнаһ саный... Аңлый алмый

тора идек яргаланган күккә карап,
Кояш чыкты да җил исте җанны тарап,
һәм син әйттең: «Мин янасы ут — бар, белдем —
ул Кояштыр!.. Ә яшь чакта йолдыз иде,
тылсым булып хисемә ул ялкын өрде...
Хәзер бөек гөнаһ уты — Кояш төрде...»

## Әмирхан Еники

Тып-тып төнге тамчылар тама.
Беркемең дә юк-юк синең, бер-
кемең дә юк-юк синең!..

*Ә.Еники. «Төнге тамчылар»*

Исеңдәдер, Әмирхан ага, беркөнне,
иснәп көзнең хушлашу хисле төтенен,
йөргән идек без Казан урамнарында,
бер сөйләшеп калыйк дип гомер барында,
чөнки гомер, яралганга тирән төндә,
уенда аның ни барын белми кем дә.

Озак йөрдек... Ә аяклар армадылар...
Тумыштан ук сукыр галим бармагыдай
укыдылар алар Казан урамнарын —
вакытның бөтен халәтен: бураннарын,
серле таңын, бозлы җил салган эзләрне,
һәр хәрефе бер өй булган ут сүзләрне...

Барып кайттык киләчәккә... Үткәннәргә...
Бар икән сагынып сөйләп үкенергә
бик күп сәбәп кешедә дә, халыкта да,
әйтерсең лә черек тактадагы кадак,
башмак төбен тишеп, аяк табанына
гына түгел, тия җаныңның канына...

Иске агач урамнарны урап-бурап,
килеп чыктык моңсу Чехов урамына.
Син туктадың. Әйттең: «Шушы өйгә кара!
Бу өй түгел, — йөрәктәге татлы яра...
Яңа өйләрдә тарих юк, алар шома,
хисем өчен оя түгел алар шуңа...

Ә бу өйдә хисләр аңны җиңгән мәлдә,
мин яшь чакта тарыдым бер гаҗәп хәлгә —
мәхәббәткә карадым җанымны сатып,

тукталмасмы икән диеп гүзәл вакыт,
һәм дөресен әйтим сиңа — ул тукталды!
Ә гомерем шул мизгелдә котсыз калды,

югалтты барлык мәгънәсен гүзәл килеш...
Гомер — дулкын, ә дулкын чабарга тиеш
бөтерелеп, шау-гөр килеп, камчыланып,
йолдызларга кадәр чөеп тамчыларын,
һәм ул чапты. Үкенәмме?.. Үкенмимме?..
Ни кызганыч — әле булса үзем белмим!

Ләкин кайчак, язгы төндә, мине арбап,
тып-тып итеп тамчы тама йолдызлардан»,—
дидең дә син, Әмирхан ага, тын гына
кереп киттең серләреңнең тыкрыгына...
Шуннан бирле мин төн саен ятам тыңлап —
йолдызлардан тамчы тама кайчак чыңлап...

## Рөстәм Яхин

Рөстәм ага, исеңдәдер, безнең өйдә
пианино эзләттең син... Әзер көйгә
җайлы шигырь яздырмакчы идең... Бары
гармун гына таба алдым. Әйттең: «Ярый,
болай гына, шыңшып кына көйләп бирәм.
Күз алдыңа китерә күр: су һәм чирәм...»

Син көйләдең. Мин китердем күз алдыма:
кояш тулы яңгыр ява авылымда...
Ләкин никтер язалмадым. Бәлки, ул җыр
бүгенгәчә чәчелмичә калган кырдыр,
көтеп ятадыр орлыгын, яңгыр исен,
һәм киләдер җанга тулып яңгырыйсы.

Исеңдәдер, нәкъ шул көнне, дөрес, кичен,
Йосыф-Зөләйха турында әллә ничек
үзеннән-үзе сүз купты. Бәхәс сүзе!
Ак йөзеңнән алсу болыт үтте йөзеп,
һәм син әйттең: «Бар минем олы хыялым:
гүзәл Йосыф — минем ирлек идеалым,

сәхнәләргә чыгарасым килә аны!..»
Ә мин әйттем: «Йосыфны мескен дип саныйм —
Зөләйхадай асыл аңа йөрәк ача,
сезнең ирлек идеалы куркып кача.
Шул да каһарман булдымы татар өчен?!
Шуңа сарыф итәргәме илһам көчен?!»

Үпкәләттем, кичерә күр, Рөстәм ага.
Чыгып киттең син лоджийга, саф һавага...
Офыкка тигән кояшның нуры сүрән
генә яңрый иде... Һәм ни күрәм —
күзләреңдә кага Идел дулкыннары,
офык төсле кызгылт-сары, кызгылт-сары...

Син башладың сүзләреңне таштан сыгып:
«Кем бар, ата, бу җиһанда гүзәл Йосыф
кебек җанын саф, пакь килеш саклый алган,
җәннәт вәгъдә иткәндә дә сатылмаган?!
Дон-Жуанмы? Йә Фаустмы? Отелломы?..»
Һәм мин әйттем: «Атый алмыйм! Атый алмыйм!..»

Күзем синең ул кичтә яшеңне эчте,
Рөстәм ага! Аннары соң синең өчен
хыялыңа, бәлки, ярдәм булыр, диеп,
«Йосыф-Зөләйха»ны яздым. Яздым сөеп
синең бөек идеалыңны... Һәм хуш калдым...
Син үзең Йосыф икәнсең! Мин ышандым!

## Сара Садыйкова

Исеңдәдер, Сара апа, «Радио»га
алып кергән иде мине Нәҗип ага
тыңлатырга шигыремә язган җырын...
Хисле май ае иде ул... һәм кичкырын.
Ак-кара юлларда йөртеп син кулларың,
әзли иден кеше җанының кылларын.

— Нәҗип үзе монда килгән — гаҗәп хәлләр!
Яшьтәш, персидәтеллектән төштең мәллә? —
диеп каршы алдың безне син кеткелдәп,
тавыш-чәчәкләрдән хасил көләч гөләп...
Нәҗип ага каламы соң бер җавапсыз:
— Син бит шайтан таягыдыр — нык чагасың,

нык чагасың, Сара апа... Дәшмә, дәшмә!..
Синең белән ничек булыйк ди без яшьтәш?!
Исеңдәдер, моннан утыз еллар элек
каты гына бер әрләштек телләр телеп.
Шунда әйттең: «Син ыштансыз малай чакта
мин атказанган идем инде...» Менә — чаксаң!..

Һәм син кинәт карылдадың: — Нәҗип туган,
без сулаган бик күп җилләр онытылган.
Андый хәлләр дә булгандыр... Инкяр итмим.
Хәзер исә мин яшьлеккә таба киттем.
Беравыктан, Нәҗип яшьтәш, һич яшермим,
сиңа әле абый диеп эндәшермен.

Аннан тагын бер сүз әйттең күзгә терәп:
— Күкрәгемдә, Нәҗип, минем ике йөрәк.
Хәзер менә икенчесе канны куа,
шуның өчен миндә һәр көн җырлар туа.
Кара әле, профессор, мине тыңлап:
ага тавыш миннән моңлап, ага чыңлап.

Пианинода югары бер аккорд алдың...
Башладың җыр... Синең тавыш былбылланды,
күчте кинәт нурдай нечкә тетрәнүгә,
очты күккә, бәллүр яңгыр түгә-түгә,
чүт-чүт итте... кунды бәрхет каурый булып,
күңелгә дә, бүлмәгә дә тулып-тулып...

Нәҗип ага Җиһановның китте исе:
— Сара апа, гүзәл шайтан, син нишлисең —
үзең җитмешнең өстендә, ә тавышың...
Ике йөрәк миндә диеп син ялгыштың,
өч йөрәк ич! Өченчесе иң кирәге —
үлемсез татар халкының моң йөрәге...

## Нәҗип Җиһанов

Исеңдәдер, исеңдәдер, Нәҗип абый,
үҗәтләнеп, салкын гыйнвар тәрәз шакый
иде, синең кабинетыңа ашкынып,
кинәт синнән кинаяле сүз ташкыны
ургып чыкты: «Күрәсеңме, татар җиле!
Гаҗәеп җил!.. Гаҗәеп... Тик кайчак тиле...»

Терсәкләнеп ак рояльгә ике яктан
(икебез дә коньяк йотып, йөзем капкан
идек синең туган көнең хөрмәтенә),
төрле-төрле фикерләрдә түнә-түнә
сөйләшкәндә ихласлык кырына ятып,
син әйтмешли, татар җиле тәрәз какты.

— Нәрсә соң ул татар җиле? Һәм аңарда
нинди аермалыклар бар башкалардан?
Аңлый алсам, Нәҗип ага, аңлат әйдә,
йә булмаса уйнап күрсәт ак рояльдә,—
дип әйттем дә ачтым рояль бармакларын —
шаяртсаң, мин дә шаяртам — карап карыйк!..

Күреп тордым, сиңа олы ният иңде—
адәм түгел, адәм төсле илһам идең...
Уң канатың уң яктагы иң еракта
кем кагыласын белмичә көтеп яткан
бармакларга кагылды... һәм... кагылмады...
Сайрау моңы агылды һәм... агылмады...

Сул канатың сул яктагы иң арыда
яткан түбән тавышларны югарыга
таба шаулап шуышырга тотынды да...
Сайрау-моңнар шул шау-шуда йотылдылар.
— Менә ул җил! Аянычлы да, кызык та,
ләкин миндә юк иде мондый музыка,

алдагы симфонияләрнең берсенә
сеңдерергә кирәк булыр. Эзләсеннәр
музыка тәнкыйтьчеләре — мондый кире,
берен бере йоткан моңнар ничек бире
килеп кергән, һәм алар нине аңлата?
Һәр әсәрдә минем шундый бер сер ята...

Ак рояльгә терсәкләнеп, ак кәгазьгә
яздың, яздың ашыга-ашыга... Тик беразга
тукталгач, мин, яныңа синең килеп,
сорап куйдым: — Йә, нәрсә соң татар җиле?
Һәм син әйттең:
— Кичтем еллар, кичтем илләр,
бөекләрен өскә чөя башка җилләр...

### Илгиз Мәҗитов

Исеңдәдер, Илгиз Мәҗит, без Мәскәүдә
чүпрәк-чапрак эзләп йөрдек олы сәүдә
урамнары буйлап, эттәй арып-талып.
Ул заманда әйбер эзләп бөтен халык
килә иде башкалага, чөнки Мәскәү
тиеш иде Парижларга сер бирмәскә.

Бара идек портмонелар ташкынында
кибеттән кибеткә агып... Һәм син шунда
туктап калдың. Әйттең миңа:
— Шагыйрь, кара,
алдыбызда итәкле җыр йөзеп бара!
Хәзер аны мин туктатам. Бүген кичкә
очрашырга сүз куешам! Ул киләчәк!

Итәкле җыр, әкияттәге сылу сыман,
күзеңдәге зәңгәр нурлар тылсымының
тәэсиренә биреште... Тәмам арбалып,
безгә таба борылды да калды катып.
Ышанмаслык чибәр иде! Мин аңыма
килеп баксам — син идең аның янында.

Өч-дүрт минут булды микән әңгәмәгез —
ханым нидер язып алды. Аннары без,
кибетләрдән кибетләргә күчә-күчә,
дәвам иттек... Һәм син әйттең: — Ул киләчәк!
Ышаныгыз! Йөрәгемдә юк шик-борчу.
Ул киләчәк! Чөнки ул — Җыр, ә мин — Җырчы!

Килдеме ул, килмәдеме — мин дә, син дә
һич белмибез. «Москва» кунакханәсендә
ул кичне икәү утырдык табын корып...
Ә телефон чырылдады тамак кырып...
Кагылмадык... Бүлмәбезгә тынлык иңде...
Исеңдәдер, сиңа шунда бер җыр килде.

Син җырладың. Тавышыңдагы булган көрлек
көзге дымнар тигән җил булып йөткерде.
Ләкин моңың язгы иде — җылы, якты.
Һәм мин, «Озын су өсте»нә чалкан ятып,
бер язгы боз кисәгедәй, агып киттем,
җитеп шигырь диңгеземә, эреп беттем,

булар булдым, болыт булдым, күтәрелдем,
яңгыр булып кыя-тауларга бәрелдем.
Бөтен җирдә синең карлыккан тавышың.
— Ник үзеңә калдырмадың?— дип ябыштым.
Һәм син әйттең, яшьләреңне сыга-сыга:
— Бүләк иттем, сорагачтын, җилгә, суга...

## Идрис Газиев

Исеңдәдер, исеңдәдер, Идрис Гази,
тавыш белән серле сурәт ясый-ясый,
син җырладың Рөстәм Яхинның җырларын —
ачып бирдең өченче дөнья да барын
теге дөнья һәм бу дөнья арасында —
шул араның «тормыш» дигән ярасында.

Ул дөньяда башка кояш һәм башка Ай,
пәйгамбәрләр башка анда, башка Ходай —
шуның өчен гомер агышы да үзгә:
уй-фикерләр оча анда күренеп күзгә,
һәм юк анда капма-каршы булган яклар:
суык—кайнар, галим — тиле, кара — аклар.

Ул дөньяда юк кырый да, чат та, оч та,
анда аң да, җан да чиксезлектә оча —
бәрдермичә, канатмыйча канатларын,
һәр йөрәктә кайтаваздай кабатланып.
Шуңа анда уйлар хисле, хисләр төсле,
төсләр исә Җәннәт багыдай хуш исле.

Ул дөньяда кеше тәнле дә, тәнсез дә,
һәм бүленми ул матурга йә ямьсезгә,
аңлаша да кеше белән сүзсез-нисез,
ул дөньяда кеше җаны һәм җыр — игез.
Ул дөньяда яшәү татлы, тормыш назлы...
Менә нәрсә ачтың безгә, Идрис Гази.

Син җырладың: «Бер генә сүз, бер генә сүз
әйтә алмый калдым...» — диеп. Аңладык без
нинди сүзне син кадерләп йөреткәнне.
Мин дә әйтмим, китмәсен дип, аның тәме.
Ләкин бер сүз әйтми кала алмыйм бүген,
әйтми калсам, ватылыр күк күңел күгем.

Син тудырган дөнья чынлап гүзәл иде,
ул дөньяда һәрберебез бизәк иде.
Сокланудан һәркем бармак шартлатырлык,
күктә Аллаһ, Җирдә Иблис шаккатырлык.
Нәкъ шуларга, башкаларга да дәшәбез,
көнләшмәгез!

## Резедә Әхиярова

Исәндәдер, Әхиярова Резедә,
нинди эзгә басканлыгыңны үзең дә
аңлый алмаган нәни бер кызчык чакта
миңа килдең, нота кәгазе кочаклап.
Мин ул чакта шактый зур нәчәлник идем —
«Яшь ленинчы» гәзитенең сәркәтибе!

Кыю бушап әниеңнең җитәгеннән,
ә ул торды көлемсерәп, читтә генә,
суздың миңа кәгазеңне, башың чөеп:
— Бик яхшы җыр алып килдем сезгә, — диеп.
Ул чакта да, һәм хәзер дә, нотаның мин
койрыклысын койрыксыздан аера белмим.

Уйлап куйдым шунда үзем: «Әрсезлектән
иза чикмәс бу чытлы кыз», — диеп... Тиздән
килеп керде редакциябезгә, балкып,
Мирсәет дустым Яруллин... Күреп алды
син калдырган ноталарны... Күзе белән
җырлап чыкты... Һәм шыңшыды сүзе белән.

— Монда, — диде, — нидер бар бит, — әйдә, бастыр —
авыл моңлы шәһәр кызы бездә аздыр...
Һәм басылып чыкты җырың... Шул җырчыктан,
син, Резедә, очып чыктың сыерчыктай
һәм әйләндең сандугачка, шаккатырып
барча кошның һәм остасын, һәм матурын!..

Син еш кундың минем шигырьләремә дә,
төрле шагыйрь яфрак ярган әрәмәдә.
Синең моңың сайратты минем сүзләрне —
кырыс сүзем хисләнде минем, үзгәрде...
...Һәм шул әрсез кызчык бик еш искә төшә,
уем йөргән сукмакларга чәчәк түшәп.

Һәм исертә уйларымны чәчәк исе,
килә минем Җирдә җыр булып яшисем.
Бер мизгелгә әверелсәм җырга — рәхәт!
Моның өчен кемгә, кемгә әйтим рәхмәт?
Алам кәгазь, алам каләм, манам чыкка —
сәлам язам теге әрсез, шук кызчыкка...

### Илдар Юзеев

Исеңдәдер, Илдар абый, әллә ничек
очраштык та ЦДЛ*да, төтен эчеп
утырганда безнең шактый мул табынга
(ә татарга Мәскәүдә кунак табыла!)
Виктор Иваныч Кочетков** үзе килде.
Язучылар парткомында ул баш иде.

Куе төтенгә кушылгач бераз сыек
кайнарлык та, киттек, ахры, шактый кыеп —
бу тарихи бина буйлап сәяхәткә
чыгып кердек... Йөри-йөри күрдек хәтта
иң зур түрә язучылар бүлмәләрен.
Гид Кочетков сөйләп йөрде белгәннәрен.

Төгәлләдек сәяхәтне парткомда без.
Күн диванда рәхәтләнеп утырабыз.
Партсерләр сейфын ачты Виктор Иваныч,
алды аннан «Арарат» дигән юаныч,
салып чыкты Кубачи*** көмешләренә...
Менә-менә көмешләр тешкә бәрелә

дип торганда, хуҗаң әйтеп салмасынмы:
— Кайсыгызның нормаль түгел кан басымы?
Нормаль булса, минутларны итмик әрәм,
чираттагы эксперимент үткәрәм:
сез утырган шушы диван хәтәр тулы —
Александр Фадеев үлгән атылып...

Корт чаккандай, Илдар абый, син диваннан
сикереп тордың... Күз нурларың чеп-чи канга
манчылган кебек иделәр... Кубачиның
рюмкасын паркетка бәрдең һәм, ачынып,
әйттең йомшак тавыш белән каты итеп:
— Кан белән үртәү татарны хватит, җитте —

* ЦДЛ — Центральный Дом Литераторов.
** В.И. Кочетков — рус шагыйре.
*** Кубачи — Дагыстанда көмешчеләр авылы.

кипкәне дә, тамганы да, катканы да
гаеп ташлау тамырларда акканына...
... Агарынды, кабаланды хуҗа шулчак —
синең сүзләр, Илдар абый, булып пычак,
кадалды экспериментчы күзенә...
Аның хәлен аңлата алмас сүз генә,

төгәл итеп күрсәтә алмас кино да —
рус йөрәге татар җанында кыйнала,
сүз табалмый... Икесе дә сызланалар,
әйтерсең лә бүген солых бозган алар...
Һәм син әйттең: — Әйдә, ресторанга күчик,
берәр бокал иң кыйммәтле дуслык эчик...

## Фәридә Хәсьянова

Исеңдәдер, Фәридә ханым, берзаман
күргәзмәдә, аптырашка калып яман,
үз сурәтемә карап торган чагында,
көтмәгәндә пәйда булдың да янымда,
әйтә куйдың: — Кара чәчле, коңгырт күзле
сезнең чалымлы бу сурәт әллә сезме?

Һәм мин әйттем, текәп зәңгәр күзләремне:
— Бәлки, вакыт күзләрне дә үзгәрткәндер —
күрмисеңме, сары чәчем көлсу инде,
гомер җәем сүнеп бара, көн суынды...
— Үзем ясыйм бер портрет — шагыйрь итеп,
маңгаегыз сырлары серенә җитеп, —

диеп әйттең, генерал адъютантына
әйткән кебек, ләкин чак җылымса тонда, —
хатын-кызлар бәйрәмен генә үткәрик,
эшегезгә киләм мольбертым күтәреп —
атказанган рәссам белән ярышыймчы!..
...Честь бирергә туры килде карышмыйча.

Сигезенче мартта дөнья куйды әни...
Иртәгәсен аны күмдек әрни-әрни...
Эшкә килдем, иңнәремә кайгы асып...
Кабул итү бүлмәсендә син торасың,
этюдлигыңны җилкәңә элгән килеш...
Мине йотты минем эш, сине — синең эш...

Кичен күрдем сурәтемне. Аклы-кара...
Күзләр — күзләремә охшаш аңлы яра,
иреннәрем ыңгырашу өнен кыскан,
битемдәге күләгәгә нидер поскан.
Маңгаемны чатнатканнар авыр уйлар,
кыяфәттә чарасызлык салкыны бар...

— Мин шундыймы?— дидем, гәрчә күзем-кашым,
авыз-борын нәкъ минеке, һәм дә башым... —
Шагыйрь кайда?— дидем мин, тәмам аптырап...
— Дөрестән дә, бу — сез түгел, сез яктырак,
ягымлырак, җылырак, катлаулырак ир,
сурәтемдә — кайгы уты йоткан шагыйрь,

ул тырыша кабынмаска кайгы булып,
күрәсезме, күзләрендә лычма болыт —
яңгыр булып явачак та чәчрәп-чәчрәп,
кайгының караңгы утын сүндерәчәк,
чөнки шагыйрьнең хакы юк әйләнергә
дөнья ямен кимсетүче хәл-әйбергә!..

## Мирсәет Яруллин

Исәндәдер, дустым Мирсәет Яруллин,
мең дә бергә теш кысып кына ярылмый
йөргән чакта өй-эш-иҗат сукмагында,
очраттың да, барына өстәп, тагын да
бер эш бирдең. Мин килештем һич карусыз —
ул елларда кыюлык булган ярыйсы!..

— Бәлки, — дидең, — шаккатризм дип атарлар,
ну шулай да язып күрсәтик татарга
оратория дигән бер яңа әсәр,
әлегәчә татарда юк андый нәрсә...
Һәм аңлаттың оратория нилекне.
Андый «җырны» һич белми идем элек мин...

Һәм тотындым мин язарга сиңа кирәк
либреттоны... Чынын әйтим — бик тә сирәк
газаплана идем мин шигырь язганда...
Шигырьлек тә, ташка үлчим, бик аз анда...
Язамын да сиңа китәм — син хуплыйсың,
тик сорыйсың сүзләрнең утлы уклысын...

Исәндәдер, шаккатризм тыңларга дип,
Актерга[1] халык җыелды күптин дә күп...
Тыңладылар... Һәм китте фикер алышу:
мактадылар берсеннән-берсе калышмый
Нәҗип[2] ага, Гомәр[3] ага, Заһид[4] ага,
тагын күпләр, безнең иңнән кага-кага...

Әмирхан ага Еники дә сүз алды:
— Сәйдәш увертюраларыннан кузгалды
безнең музыкабызның бу юнәлеше...

---

[1] Хәзерге Актерлар йорты.
[2] Композитор Нәҗип Җиһанов.
[3] Язучы Гомәр Бәширов.
[4] Композитор Заһид Хәбибуллин.

«Кеше»[1] дигән бу әсәрнең дә өлеше
сизелерлек булыр әле киләчәктә —
татар музыкасы бүген шау чәчәктә...

Трибунага менде Мирсәй ага Әмир:
— Музыка да, либретто да — шәп, ләкин бер
нюанс бар... Сез уйлагыз әле шунсын:
«Кешенең иң зур нәрсәсе...» дигәннән соң
сузыла да сүзсез музыкаль пауза,
күз алдыннан шулчак төрле нәрсә уза...

Халык көлде... Мин кызардым. Син юаттың...
Тынычландым һәм башка сүз уйлап таптым,
җырлап карап, либреттога шундук керттек:
«Кешенең иң зур байлыгы..!» — дип үзгәрттек.
Һәм бу байлык, Мирсәет дус, исән, яши,
кеше җанын кешелеккә таба дәшеп...

---

[1] «Кеше» ораториясе. Аны беренче тапкыр Н.Джураева җитәкчелегендәге хор башкарды.

**Лия Закировна Шакирова**

Исегездә микән Сезнең, Лия апа:
мин — студент, Сез нибары доцент чакта
(Орденнарның, төрле олы исемнәрнең,
Сезне эзләп, юлга җыенган көннәре),
тоттыгыз бит мине олы алдашуда,
әйләндегез утлы-борычлы ташуга:

— Нинди тырыш студент, дип уйлап торам —
лекциямнең һәр сүзен язып утыра!
Ә ул шигырь яза икән көн дә, көн дә,
иң беренче өстәлдә — борын төбендә,
бөтен дөньясын онытып, нахаллашып.
Имтиханда сине көтә коры кашык...

Килеп җитте имтиханнар чоры шулай...
Әйтмәсәм дә, минем хәлләр аңлашыла —
моңа чаклы «отлично»га гына барган
бер бәхетсез якынлаша хәтәр ярга,
анда аны көтеп тора, сабын кашып,
авызларны ерта торган коры кашык...

Юк, мин әйтәм, — үлеме без, тереме без? —
болай гына, яусыз гына бирелмибез.
Сезнең фәнне чарладым мин көн-төн, көн-төн —
хәтта мидән чыга язды кайнар төтен.
Имтиханга тәүге тапкыр куркып кердем,
беркемнән дә күрмәгәнне Сездән күрдем.

Әй кудыгыз фән кырлары буйлап мине!..
Анда — тозак, тегендә — баз, монда — мина...
Берсенә дә килеп капмыйм, исән торам,
миналарны җиңел зарарсызландырам.
Сездән алган фәнни цитаталар белән —
мин аларны тик бер көнгә яттан беләм!..

— Ну, Харисов, — дидегез Сез, — майлы каеш!
Ну, Харисов, син бит мине... вынуждаешь...
Бу юлы кала бурычым түләнмичә —
куямын сиңа... биш баллны... теләмичә...
Шуннан бирле, Укытучым — Сезгә гашыйк!
Исемегез минем өчен баллы кашык.

Һәм, әлбәттә, без дуслаштык... Тора-бара
гомер буе Сез уздырган чараларда
кунак булдым йә катнаштым бик тә теләп...
Әле булса исән миндә Сезнең бүләк —
кызыл дипломымда минем Сезнең имза,
һәм шул имза миңа якты уйлар суза...

## Шамил Анак

Исендәдәр, Шамил абый, исендәдер:
син ул чакта Анак түгел, ә гади бер
шагыйрь идең Казан өчен. Ә чынында —
Мәскәвендә, Прагада, Истанбулда
исемеңнең матур аты чыккан иде:
«верлибрчы» дигән ярлык йоккан иде.

Без таныштык иске Матбугат йортында
һәм сөйләшеп киттек шундук бер үк тында,
бер үк тонда миңа тансык темаларга,
барып җиттек чиксезлек төкәнгән ярга...
Онытылдык... Кич тә җиткән беленми дә...
Барып кердек Пушкиндагы* блинныйга.

Дәвам иттек... Антик чорны айкап йөрдек...
Этрускларга, Бабилунга барып кердек...
Күрдек Җирнеке булмаган, күктән иңгән
цивилизацияләрне... Шуннан сеңгән
дымда үскән халыкларны барладың син —
әкрен генә блинныйны арбадың син:

унлап кеше җыелды безнең өстәлгә.
Кафе бикләп, пешекчеләр дә өстәлде.
Син сөйләдең... Юк, син гиздең гыйлемеңдә —
Күлтәгиннәр һәм Чыңгыз ханнар илендә
татар тамырларының эзенә аяк бастык.
Һәм алмашты тарихларның өсте-асты...

Шигырьләрең — белемеңнең тән-бәдәне
чигеп барды синең затлы фәлсәфәңне
әңгәмәнең күңелдәй ак тасмасына:
кеше тора космик тылсым басмасында!..
Дәлилләрең — Библиядән һәм Коръәннән
һәм бүгенге иң алдынгы космик фәннән.

---

* Казанда 1961—1962 елларда Пушкин һәм Университет урамнары чатында «Блинная» дигән кафе бар иде.

Төрле телдән төрле сүзләр чагыштырдың...
Безнең уйны Заман белән чабыштырдың...
Мин ул чакта тик студент кына идем,
йөрәгемә ярыш җене шунда тиде —
әй тырыштым Заманага баш бирмәскә,
гел яңарып тормасам да — искермәскә!..

Аһ, ул көнне, Шамил абый, син гаҗәеп
биек идең... Сәмруг коштай канат җәеп,
ас дөньядан өс дөньяга безне ташып,
син үзең дә, абруй булып, өскә аштың.
Мин әле дә сиңа карыйм ияк чөеп,
китәм шулчак теге асыл көнгә тиеп.

## Биш Ренат

Исегездәдер дип уйлыйм, адашларым,
күрсәтергә теләп бездә дә баш барын,
җыелдык та, коры шәраб эчә-эчә,
ниятләдек үткәрергә күмәк кичә
Актер йорты* диеп аталган подвалда —
подвал булса да, бик якты иде анда.

Бармакларын Шүрәле кебек селкетеп,
композитор һәм пианист Р.Еники
уйнады Шопен «Ноктюрн»ын, сонатина:
пианино сыкрый, гөрли, көлә, тына
һәм пышылдый көйдән генә хасил сүзләр:
затлы музыкага бирел, татар — үзгәр!..

Чыкты Таҗи. Ул — Геракл, Былтыр, атлет —
һәр адымын король Лирдай горур атлый.
Учы белән, шау китереп, һава телеп,
монологлар сөйләде ул елап, көлеп...
Күңелләргә уелдылар нурлы эзләр:
сәхнә кебек иркенлеккә омтыл — үзгәр!..

Әле бары консерваториядә генә
укыса да, Ибраһимов менә дигән
затлы җырчы булачагын шәп күрсәтте —
арияләр, шлягерлар бүләк итте.
Колаклардан күңелләргә кучте сүзләр:
артта калма җырдан, татар — үзгәр, үзгәр!..

Ибәтуллин — игезәкләрнең сыңары —
аякларда көй дә, сүз дә, җыр да барын
тар сәхнәдә очып биеп исбат итте...
Һәм миңа да шигырь сөйләр чират җитте.
Бик модада иде шигырь ул елларда —
йөри иде кыю, авангард юлларда.

---

* Үткән гасырның җитмешенче елларында Актерлар йорты К.Нәҗми урамында В.И.Качалов исемендәге театр гомумторагының цоколь этажында урнашкан иде.

Ил буйлата искән җылы җилләр дәрте
күңлебезне, күзебезне нык үзгәртте.
Исемебез* татарныкы булмаса да,
рухыбызны чын татарча — туры, садә,
горур итеп саклап кала алган килеш,
без өндәдек: татар үзгәрергә тиеш!

Исегездәдер дип уйлыйм, адашларым,
җанны кыйган куркаклыкның бозы-кары
тизрәк эрергә кереште безнең утта —
телгә кайта башладылар тарих йоткан
күп шәхесләр, батырлыклар һәм рух эше...
Бу эштә бар биш Ренатның да өлеше!..

* Renatus — латинчадан, яңадан яшәүгә әйләнеп кайтуны аңлата.

# Эчтәлек

Төзүчедән .................... 7

**Шигырьләр. 1995–2005**

Мәңгелек мөһер .................... 10
«Барысы да сиңа бәйле...» .................... 11
«Дөнья сүрәнләнеп китеп...» .................... 11
Адюк Сыркыдысы .................... 12
Яшермә .................... 13
Без калабыз .................... 14
«Яңа елга катгый теләгем...» .................... 15
Терек суы .................... 16
Югары дөнья .................... 17
Үзем турында .................... 18
Нигә? .................... 19
Кутузовтай... .................... 20
Чиксез ышаныч .................... 21
Тагын юллар .................... 22
Яшьләрчә, картларча .................... 23
Беренче көндә уйлану .................... 24
Калсаң иде... .................... 25
Туган йорт капкасы .................... 26
Туган җир .................... 27
Җаны тәнгә сыймаганда .................... 28
Хәбәр эзләп... .................... 29
Назыңда эреп .................... 30
Ун кадак .................... 31
Кече тирән күлдә .................... 32
Сабантуй байрагы .................... 33
Югалтмый .................... 34
Күрмичә калган .................... 35
Ухсай кабере .................... 36
Шагыйрьнең йөрәге кайда? .................... 37
Казан буйлап .................... 38
Сабантуйлы татар халкы .................... 39
«Мәхәббәтсез беркем яши алмый...» .................... 40
«Мәхәббәт, мәхәббәт!..» .................... 41
«Убылып төшеп имәннәр...» .................... 42
Сембер .................... 43

Кычкырырбыз әле... 44
Тагын бер «Мин» 45
Яньчелгәнгә 46
Котәм намус кушканны 47
Мактаулы исем турында 48
«Озын гомердән курыкмыйм...» 49
«Таба алмыйм көннәр мазасын...» 50
«Кояш күрде һәм Ай алды...» 51
Таҗ 52
Хәнҗәр 52
Камчы 52
Кышның матур көннәре 53
Зәвык бүлмәсе 54
Халык урынбасары 55
«Усаллык артты кешедә...» 56
Кыйммәтлерәк! 57
Яз тәме 58
Күтәрердәй кеше юк 59
Хәтәр хатирә 60
Шундый чагы күңелнең 61
Иблис кары 62
Имә башың 63
Зират тузаны 64
Гөлләргә су сибеп кайттым 65
Эпитафия 66
Иң көзге ай 67
Файдасыз 68
Никахлы төс 69
Кышкы бакчада 70
«Кайчак йолдызлар күренми...» 71
Яз шәле 72
Нилектән? 73
Китлар сыман 73
Сан булгач 74
Үкенеч 74
Шаян әңгәмә 75
Тәрҗемәчеләр 75
Киек уйлар 76
Тынлык чоңгылында 77
Эстрада йолдызлары 77
Кыпрыста 78
Шәүлә 79
Вакыт җитте... 80
Бригантина 81
Киләчәкне тотып кара 82

Тоям кебек ........ 82
Татар татар инде... ........ 83
Кауры й каләм үлгән ........ 84
Давыллану ........ 85
Рамазан аеның Ае ........ 86
Үзем исән чакта ........ 87
Бетәсең ........ 88
Кылыч ........ 89
Күңел ........ 89
«Горурлык» ........ 90
Ишетү ........ 91
Биш йөз еллык куркаклык ........ 91
Сәерсенү ........ 92
Яманрак ........ 93
Кунак һәм табын ........ 93
Сый ........ 94
«Көзен көзге язгы уйларымны өзде...» ........ 94
Сандык ........ 95
Күзләр кычкыра ........ 95
Көнләшәм ........ 96
Романс ........ 96
Шигъри ят ........ 97
Иртәгә! ........ 97
Коръән ........ 98
Көчлерәк ........ 98
Татарлык тамгасы ........ 99
Югалттым... Таптым... ........ 99
Тәмсезләнмә! ........ 100
Влач ........ 100
Китәм! ........ 101
Мәкерлек ........ 102
Сәясәт ........ 102
Бәхет ........ 102
Әгерҗегә барганда ........ 103
Ватан ........ 104
Тукай боза ........ 104
Юл сайлаганда ........ 104
Казан кунаклары ........ 105
Ижминсу ........ 106
Юнәлеш ........ 107
Гарьлек ........ 107
Хыянәт ........ 107
Каргыш итеп ........ 108
Алдану ........ 108
Казан манаралары ........ 109

Казанга әманәт ........ 110
Казан хәзинәсе ........ 111
Яфракка шигырь язганмын ........ 112
Язгы мәдхия ........ 113
Сонетлар ........ 114
1. Җавап эзләү сонеты ........ 114
2. Реформаларга карышу сонеты ........ 114
3. Чиксезлеккә ышану сонеты ........ 115
4. Йөрәк фасылы сонеты ........ 115
5. Хата эзләү сонеты ........ 116
6. Тулган ай сонеты ........ 117
7. Тиңләү сонеты ........ 117
8. Язгы көн-төн тигезлеге сонеты ........ 118
Тирән яктылык ........ 119
Сискәндеримче ........ 120
Кояшлы буран ........ 121
Кунак — хуҗасына күрә ........ 121
Алып йоклый... ........ 122
Нефтькә ике сүз ........ 123
Кызганма ........ 124
Юкмы әллә? ........ 124
Исән картлар ........ 125
Баден-Баденда ........ 126
Башка сукты ........ 127
Гади дөнья җимерелде ........ 128
«Күкләр тетрәп, баш түбәмә...» ........ 129
«Гел яктыда озак йөрелдеме...» ........ 130
«Тәрәзәдән кулны сузып...» ........ 131
«Начармыни патша булу?!..» ........ 132
Ясак ........ 133
Тормыш-сыер ........ 134
«Теләсә генә ничек яшерсә дә...» ........ 135
«Газаплар-газапланулар...» ........ 136
«Хыялымда якты беткәч...» ........ 137
Авыз ерып килеше ........ 138
«Замана җиле җанымда...» ........ 139
Аңлап өлгермичә ........ 140
«Яхшысы да китә...» ........ 141
Иң авыр йөк ........ 142
Ике башлы... ........ 143
Атмый калган сүз ........ 144
«Җыр агышы өзелә дә...» ........ 145
«Көн бик сүрән булды...» ........ 146
Дилбегә ........ 146
«...Әйе, каләм кулдан төшәчәк...» ........ 147

Кипр утравында ........ 148
«Әллә кая кояш байый...» ........ 149
Кеше булыйк ........ 150
Нигә кеше күзен йома ........ 151
Авызлык ........ 151
«Карурманнар уртасында...» ........ 152
«— Өйдә ничек?..» ........ 153
Дулкын ........ 154
«Җил исеп куйды да кисеп...» ........ 155
Канәгатьсезлек ........ 155
Кышкы курорт ........ 156
«Барганда чаптардай атылып...» ........ 157
«Ак теплоход...» ........ 158
Су төбе ........ 159
«Җир кабат әйләнеп чыкты...» ........ 160
«Фикер ул — бар...» ........ 161
Кипр эскизлары ........ 162
«Кичерегез, зинһар, кичерегез...» ........ 165
«Өндәме бу, төштәме...» ........ 166
«Нишләтим мин сине, нишләтим?..» ........ 167
Ләкин назлап ........ 168
«Шатлыкның соңгы тамчысы кипкән мәлдә...» ........ 169
Узгынчымы, ярмы?.. ........ 170
Син барында ........ 171
«Кем идек без?..» ........ 172
«Булдылар кояшларым да...» ........ 173
«Ничә йолдыз яктысында...» ........ 174
«Языласы язылган...» ........ 175
«Шәм таягын ут табага...» ........ 176
Киеренке сөйләшү ........ 177
Кем чыдар? ........ 178
«Җиде кат күк...» ........ 179
«Күз төбеңдәге сызыклар...» ........ 180
Сукмак ........ 181
«Үсмер чакның...» ........ 182
Фәрештәне чалкан егып ........ 183
«Күзем йомып сузылсам да...» ........ 184
Чәчәк ........ 185
«Сүзләреңнән сизәм...» ........ 186
Нишләттең? ........ 187
«Нинди озын көн булды бу!..» ........ 188
«Йокысызлык төнгә әйләндерде...» ........ 189
«Соңгысы алдындагысы...» ........ 190
«Әгәр китә калсам якты көннән...» ........ 191
«Күз яшең океанында...» ........ 192

«Мин кояштан һәм чәчәктән...» .... 193
«Мине сагыну сусынын...» .... 194
«Мин табибың була алам...» .... 195
«Бер исеңә төшерерсең әле мине...» .... 196
Бәхет көлмәге .... 197
«Җанымны алып киттеләр...» .... 198
«Мин моңа озак түзмәмен...» .... 199
«Син көчлерәк көнлисеңме?..» .... 200
«Маңгаеңны учларыңа салма...» .... 201
Кагыл... Кагылма... .... 202
Төнге күбәләкләр .... 203
«Иске елның яңа шигыре син...» .... 204
«Мине чиргә сабыштырдың...» .... 205
«Мин сиңа ашкынып кайтам...» .... 206
«Хисләрнең барлык болыты...» .... 207
«Ник үзеңнән этәрәсең?..» .... 208
«Синең язмыш — миңа яңа дөнья...» .... 209
Өченче дөнья .... 210
Синле-синсез... .... 211
«Салкын буранда мин ничә тапкыр...» .... 212
«Күпме елау елгаларым...» .... 213
«Минем дөньям сиңа тылсымлыдыр...» .... 214
«Аһ, ул көнне вакыт тасмасыннан...» .... 215
«Кар сырдырып йөргән көннәр онытылмый...» .... 216
Язмыш .... 217
«Беләсеңме, һәрбер кеше — Җирдер...» .... 218
«Тамырымда каным агар-акмас...» .... 219
«Хөкем ит син мине...» .... 220
«Исерттең син мине шәрабсыз...» .... 221
«Синең ихлас теләкләрең...» .... 222
«Мин төн кичтем...» .... 223
«Тәрәзәңә көне буе...» .... 224
«Яңгыр булыр, ахры...» .... 225
«Күреп булганда күрмичә...» .... 226
«Мин сине бикләп калдырдым...» .... 227
«Уйларыңнан киткәчтен дә...» .... 228
«Качам болыт артларына...» .... 229
«Йомык күз белән яшәүчем...» .... 230
Оялаган... .... 231
«Өзелмәсен, киселмәсен...» .... 232
«Синең терәгең бар...» .... 233
«Күз алдыма китертә күрмә...» .... 234
«...Яңа яр белән бәхетле...» .... 235
«Бөтен дөнья корым гына...» .... 236
Шулай да .... 237

«Нигә авыз иттем бу чишмәдән?..» .......... 238
«Бер тамчы авырлык сиңа...» .......... 239
«Ул баһадирның исемен...» .......... 240
«Пакьләндем мин...» .......... 241
Парикмахерскаяда .......... 242
«Кама өсте — куе болыт...» .......... 243
Яшермәм .......... 244
«Миннән алда үлеп китә күрмә...» .......... 245
«Көннәреңне генә миңа биреп...» .......... 246
«Бары мин генә беләчәк...» .......... 247
«Мин кайчакта...» .......... 248
«Тынычлыгың киметсәм дә...» .......... 249
«Битемдәге ерганаклар буйлап...» .......... 250
Мәхәббәт ярасы .......... 251
«Югалтасым килми, дисең...» .......... 252
«Мин кояштан көнләшмимен...» .......... 253
«Давыл тумыйча ук үлде...» .......... 254
«Көтмәгәндә йөрәгемә...» .......... 255
«Ел агышы миндә туктады...» .......... 256
«Кояшлы булсаң да салкын...» .......... 257
«Мин кичердем бер авыр төн...» .......... 258
«Син анда... Әйе, син анда...» .......... 259
«Бәйрәм!..» .......... 260
Дуамал ялкын .......... 261
«Бүген күктә йолдызлар күп...» .......... 262
Сыгылмалы сылу .......... 263
«Мин күпме сокландым...» .......... 264
«Мин бәхетле итәр идем сине...» .......... 265
«Күзем аша үтте мең буран...» .......... 266
Ятлар белгәч .......... 267
Тузганак .......... 268
«Урам хәлләрен сөйли-сөйли...» .......... 269
Көз инде .......... 270
Өч килендәш, өч баҗа .......... 271
Гармунчы .......... 272
Тамырны саклау .......... 273
Яфрак .......... 274
Карама яру .......... 276
Бакчачы .......... 277
«Коела яшел яфрак...» .......... 278
«Яфракларың — гәрәбә...» .......... 279
«Буылып үлә агачлар...» .......... 280
«Кыздырма атның аягын...» .......... 281
Ат .......... 282
Ярсыган ат .......... 283

Яткан ат ........ 284
Беренче кар ........ 285
«Еллар хәзер никтер ак кар кебек...» ........ 286
Шомырт суыклары ........ 287
Яшел марш ........ 288
Яратам сине, яңгыр ........ 289
«Җәен урманнарда кеше арта, арта...» ........ 291
«Шатлык белән эшлә икән һәрбер эшне...» ........ 292
Көз гөлләре ........ 293
Төнге урман. Кыш ........ 294
Ак карлар арасында ........ 297
Урман ........ 298
Салкын кардан җылы сүз ........ 299
Кар киткәндә ........ 300
«Җәймә-җәймә калган ак кар...» ........ 301
«Мин сарыдан сине киендерәм...» ........ 302
Бәсле ботаклар ........ 303
Нинди сүзләр? ........ 304
«Бу сүзләргә минем Идел шаһит...» ........ 305
Өч канатлы кош ........ 306
Әй, мәхәббәт... ........ 307
Кар башына кар җитә ........ 308
«Сагынулар саргайтса...» ........ 309
«Кырыкны узгач...» ........ 310
Сүз ........ 311
Чал сандугач ........ 312
Дигән идем ........ 313
«Мин ярлыкыйм барлык гөнаһыңны...» ........ 314
Көзге мәхәббәт ........ 315
«Наз татыйсым шундый килде бүген!..» ........ 316
«Түбәнсеткән, горурлыкны сыткан...» ........ 317
«Кояш бата зәңгәр тау артына...» ........ 318
«Миңа көн җитми...» ........ 319
«Сәер, гаҗәп!..» ........ 320
«Нәкъ үзедәй бер хис эзләп...» ........ 321
«Берүзем күзәттем Айның...» ........ 322
«Мин кабат кадерле җылыда...» ........ 323
Тәрәзәдә бәргәләнгән кар бөртеге ........ 324
«Утка ташлыйм юрау гөлләреңне...» ........ 325
«Бүгенге көн елның, шәт, иң ак көнедер...» ........ 326
«Син Кояшны хәтта аяз көндә...» ........ 327
Фал итмә ........ 328
«Якында булсаң да — еракта...» ........ 329
Аерса ........ 330
«Агачларның рәхәт көннәр өчен...» ........ 331

Элегия ........ 332
Мин сине һаман да яратам ........ 333
«Алтын көзне сиңа бүләк итәм...» ........ 334
«Мин күтәрдем сине үзәннәрдән...» ........ 335
«Иң алдан...» ........ 336
«Эчләремдә җылы тормый...» ........ 337
«Буем белән түгел...» ........ 338
«Син юк өйгә кайтасым да килми минем...» ........ 339
Сөеп туймаган йөрәк ........ 340
«Көне буе сагындым мин...» ........ 341
«Яхшылыгыңа — яманлык...» ........ 342
«Җиргә төшермә ........ 343
«Төренеп тә җылынып булмый...» ........ 344
Суга баткан ут ........ 345
«Эрерләр карлар, эрерләр...» ........ 346
«Аруның да була төрлесе...» ........ 347
Поездлар үтә тора ........ 348
Гүзәл ялгызлык ........ 349
«Бик кирәксәң, сине ничек табыйм эзләп?..» ........ 350
Татлы серләр карагы ........ 351
«Кагылмасам — хәлем бетә...» ........ 352
Шул чагында ........ 353
«Минем хәлем хәзер шундый...» ........ 354
«Бу кадәр бай чагын йөзеңнең...» ........ 355
Көнләшүләр ........ 356
Кисәтү ........ 357
Мәхәббәт ярасы ........ 358
Мин ул көнне... ........ 359
«Күңелемдә ямьле бәйрәм бара иде...» ........ 360
«Туктатырга җилле бу яңгырны!..» ........ 361
«Күзләреңә синең бүген...» ........ 362
«Еллар үтә...» ........ 363
«Сагынганда кемдер җырлый...» ........ 364
Өченче фәрештә ........ 365
Адашудыр ........ 366
Языклы мин ........ 367
«Кеше арасына поса-поса...» ........ 368
Сәрләүхәсез ........ 369
Үпкәләмәсәнә ........ 372
Сагыну ........ 373
Табыла ........ 374
«Гаҗәпкә калып торасың...» ........ 375
«Бер исеңә төшерерсең әле мине...» ........ 376
«Бәхетлерәк була алмас идем...» ........ 377
«Синсез чагым хәтеремә килә...» ........ 378

«Сөю — газап...» .......... 379
«Яз тәрәздән керә алмый...» .......... 380
«Минем синең белән күптән...» .......... 381
Адашасым килә .......... 382
«Вәсвәсәләр бик күп булды...» .......... 383
«Син миңа үпкәләп калма...» .......... 384
Бәсле түгел җаным .......... 385
«Күңел ишекләрем тоткасыз...» .......... 386
«Бер нәрсә дә соңгы тапкыр булмый...» .......... 392
«Мин йолдызга, юк, юк, әверелмәм...» .......... 393
«Күз оныта кайбер йөзне...» .......... 394
Туя алмыйм .......... 395
«Мин чыгарга диеп ачкан ишектән...» .......... 396
«Яши алсаң яшә миннән башка гына...» .......... 397
Мәдхияләр .......... 398
«Еллар аша гизгән өермәдә...» .......... 399
«Сагындым — сагыш орды...» .......... 400
Тамга .......... 401
Хәл-әхвәл .......... 402
Сәер матурлык .......... 403
Аллаһ кулында .......... 404
«Картайгачтын, кызык итеп...» .......... 405
Чиксез кодрәт .......... 406
Сөрү .......... 407
Без калабыз .......... 408
Арка сөяп... .......... 409
Оста җиңелүче .......... 410
Бер үк тамырдан .......... 410
Дирижер Фуад Мансуровка .......... 411
«Замананы ул бит күрми...» .......... 412
Ватылды .......... 413
Яшерә алмыйм .......... 414
Борчылма! .......... 415
Көмеш туйлар аръягында .......... 416
«Язасым килсә дә язмыйм...» .......... 417
Көтмәгәндә җылытты .......... 418
Мине чакыр .......... 419
Җиләс җил вальсы .......... 420
Көмеш тотка .......... 421
Ак теләк .......... 422
Сөен! .......... 423
Себер тракты .......... 424
Кызыл шәфәкъ .......... 425
Төсләр алмашыну .......... 426
«Сары яфрак. Яшел камыш...» .......... 427

Ак шом ........ 428
«Алтын көзне Канадада күрдем...» ........ 429
Күз тимәсен ........ 430
Зәңгәр моң ........ 431
Аклык вальсы ........ 432
«Көннең елмайганы юк бик күптән...» ........ 433
Автопортрет-90 ........ 434
«Төннең шомы тиеп уянып...» ........ 435
Сурәтемә 93 нче ел сызыгы ........ 436
Минем җаным ........ 437
Миңнәр ........ 438
Әниемә ........ 439
Тормыш алда гына ........ 440
«Җилләрдә җилфердәдем...» ........ 441
«Бизәксез чорда яшибез...» ........ 442
«Кемне кысып маташасыз...» ........ 443
«Уең белән аякларың тизлеген уз...» ........ 444
Кәшә авылы-1 ........ 445
Кәшә авылы-2 ........ 446
Буа җыры ........ 447
Казма ........ 448
Авыл мунчасы ........ 449
Уйланабыз ........ 450
Ике гаскәр ........ 451
Акылсызлык билгесе ........ 452
«Килеп җитте менә тагы сабантуйлар...» ........ 453
«Болытларның бүген агы ага...» ........ 454
Ветеран ........ 455
Әгәр ........ 456
Сарут ........ 457
«Мин августныкы, ахрысы...» ........ 458
Берәү ........ 459
«Ни яз түгел...» ........ 460
Меланхолия ........ 461
Ключарев ........ 462
Сәйдәш ........ 463
Рәссам Харис Якупов ........ 464

**Исеңдәдер... Цикл**

Бакый Урманче ........ 466
Гомәр Бәширов ........ 468
Сибгат Хәким ........ 470
Мостай Кәрим ........ 472
Әмирхан Еники ........ 474

Рөстәм Яхин .................... 476
Сара Садыйкова .................... 478
Нәҗип Җиһанов .................... 480
Илгиз Мәҗитов .................... 482
Идрис Газиев .................... 484
Резедә Әхиярова .................... 486
Илдар Юзеев .................... 488
Фәридә Хәсьянова .................... 490
Мирсәет Яруллин .................... 492
Лия Закировна Шакирова .................... 494
Шамил Анак .................... 496
Биш Ренат .................... 498

Ёитературно-художественное издание

***Харисов*** *Ренат Магсумович*

*(Ренат Харис)*

Избранные произведения

В семи томах

Том 3

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Харисов*** *Ренат Мәгъсумович*

*(Ренат Харис)*

Сайланма әсәрләр

Җиде томда

3 том

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Ф.Ш.Хәсьянова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.03.2006. Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе.
«Arial» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 26,88 + вкл. 0,84.
Шартлы буяу-оттиск 27,83. Нәшер-хисап табагы 13,53 + вкл.0,88.
Тиражы 3000 д. Заказ 3-61.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru, e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.